Безнең МИРАС

ISSN:2500-011x

10
октябрь 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

ХӨРМӘТЛЕ «БЕЗНЕҢ МИРАС» РЕДАКЦИЯСЕ!

Татар халкының фәнни-популяр, әдәби-нәфис һәм документаль журналы чыга башлавына 25 ел тулу уңаеннан аның барлык авторларын, редакция хезмәткәрләрен һәм укучыларын ихлас күңелдән котлыйм!

Илебез һәм республикабыз күтәрелеш алган чорда татар халкының күпгасырлык мирасын җәмәгатьчелеккә җиткергән журналның бастырылуы зур вакыйгага булды.

Олуг әдипләр һәм галимнәр – Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Миркасыйм Госманов, Әбрар Кәримуллин кебек фидакяр затларыбыз фатихасын алган «Безнең мирас» озын үсеш юлын үтте. Халкыбызга җан азыгы булып, чит илдә яшәүче милләттәшләребезне рухи берләштерүдә, тарихка ихтирамлы объектив караш тәрбияләүдә әһәмиятле роль уйнады.

«Безнең мирас» журналының төп максаты – йөзләрчә еллар буе дөньяның төрле илләренә таралган тарихи-мәдәни, рухи мирасыбызны эзләп, бөртекләп туплап, аны җәмәгатьчелеккә җиткерү. Шул ук вакытта безнең олы уртак бурычыбыз – халкыбызның мирасын, телен һәм мәдәниятен киләчәк буыннар өчен саклап калу.

«Безнең мирас» алга таба да татар халкының рухи байлыгын, тарихтагы тирән эзен күрсәтүче басма булып калыр, дип ышанам. Редакция хезмәткәрләренә, аның авторларына, галим һәм әдипләренә, милли җанлы укучыларына сәламәтлек һәм уңышлар, ә журналга хәерле озын юл телим.

Татарстан Республикасы
Президенты

Рөстәм МИҢНЕХАНОВ
Октябрь, 2016 ел

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең мирас 12 +
10 (274)
октябрь 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

28

12 ЗӨЛӘЙХА.
Әзһәр Мөхәммәдиев

80 БЕР РӘСЕМ ТАРИХЫ.
Дания Фәйзуллина

ЭЧТӘЛЕК

«БЕЗНЕҢ МИРАС»КА — 25!

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.МИҢНЕХАНОВның котлавы.

Күренекле дәүләт эшлеклеләре, шәхесләр, әдипләр, галимнәр – журналыбыз хакында.

ТАРИХИ МИРАС

8 **Болгар. Ак мәчет.**
10 **Борынгы Болгарда.** *Р.Вәлиев*
12 **Зөләйха.** *Ә.Мөхәммәдиев*
21 **Казан патшалыгы турындагы тарих.** *Х.Бәдигый*
28 **Балтач төбәгендә Тукай эзләре**. *Г.Мөхәммәтшин*

ДИНИ МИРАС

40 **Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы.** *Г.Гатауллин*

ӘДӘБИ МИРАС

52 **Кутадгу билик. (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
56 **Чыңгызханның ак болыты.** *Ч.Айтматов*
63 **Мин әйттем...** *М.Әгъләм*
64 **Казакъның «баш акыны».** *Х.Миңнегулов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

80 **Бер рәсем тарихы.** *Д.Фәйзуллина*
82 **Милләт хадиме.** *Н.Нәккаш*

СӘНГАТИ МИРАС

89 **Садриевлар кавеме.** *Р.Сәгъди*

ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

100 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*

ХӘТЕР САГЫНДА

112 **Сугыш кораллары.** *Л.Нәгыймов*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның октябрь ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Көлке куа килә...**

118 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Сентябрь*
119 **Мирасворд**

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Марат Закиров
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-91)

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

Заказ №М-2522. Тираж – 2000 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 28.09.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең
Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 4 нче битендә – «Безнең мирас» журналының бүгенге хезмәткәрләре.
С.Исхаков фотосы

БАШ МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

ХӘТЕРЕ БАРНЫҢ ӘЙТЕРЕ БАР

Хөрмәтле дуслар, кадерле милләттәшләр!

Без – мираслы халык. Без – хәтерле халык. Мирасы барның киләчәге, хәтере барның әйтере бар. Хәтер безне данлы үткәннәргә илтә. Үткәннәрдән без кадерле ядкярләребезне алып кайтабыз. Тарихыбызга кайта-кайта, киләчәгебезгә күз сала-сала, кырыс һәм болгавыр бүгенебездә үзебезнең бай мирасыбызны барлыйбыз, аны халыкка кайтаруга хәлкадәри өлеш кертергә тырышабыз.

Егерме биш еллык тарихы булган «Безнең мирас» журналы – халкыбызның, аерым шәхесләребезнең фаҗигале-гыйбрәтле язмышын ачыклап, милләтебезнең рухи, дини, тарихи, әдәби һәм сәнгати мирасын барлап-теркәп баручы басма.

Узган гасырның даулы-давыллы туксанынчы елларында күренекле әдипләребез, галимнәребез һәм сәясәтчеләребез, шулай ук җөмһүриятебез җитәкчеләре фатихасы белән тернәкләнеп киткән «Мирас» журналының ният-мәсләге бер – халкыбызга хезмәт итү. Берара «Чын мирас», аннары «Безнең мирас» булып эшчәнлеген дәвам иттергән басманың максаты бүген дә шул ук – саллы һәм затлы мирасыбызны укучыларыбызга җиткерү.

Бисмилла әйтеп башланган эш хәерле булыр, диләр. Бер кыйблага йөз тотып, инде егерме биш ел буе дөнья күргән басмабыз – моңа бер дәлил.

Газиз кардәшләрем!

Тел сагында торучы, Татар илен бар вөҗүде белән яратучы, бай мирасыбызны барлаучы, ул гына да түгел, тарихи-мәдәни мирасыбызны һәрдаим төзекләндереп, яңартып торучы сездәй фидакяр затларыбыз, милләтпәрвәрләребез булганда, ак максатларыбызга ирешербез, шәт. Шагыйрь әйтмешли, киләчәктә татар халкының урыны түрдә булыр, иншалла!

Татарлар – барча кыйтгаларга сибелеп, шунда яшәгән, шунда гомер кичкән халык. Халкыбызның гыйбрәтле мәкален онытмыйк: аерылганны – аю, бүленгәнне бүре ашар. Аерылмыйча, бүленмичә, һәрчак бергә булып, бердәм булып, берләшеп яшик, кадерле туганнар!

Ләбиб ЛЕРОН

«Мирас», №8, 2003 ел

Халыкның бүгенгесе һәм киләчәге аның тарихында

Татарстан Республикасы
Президенты Минтимер Шәймиев

Татар халкы кебек буталчык тарихлы башка халык юктыр, мөгаен. Россиядә татарлар сан ягыннан икенче урында торса да, аларның меңьеллык бай тарихи мәдәниятен хәтта Россиядә дә белмиләр. Ә менә кайбер публицистлар һәм сәясәтчеләр вакыт-вакыт «татар-монголлар изүе», «татар яулары», «татар ясагы» дип, татарларга карата тискәре караш уятып торалар. Тарих дәреслекләрендә татарларга цивилизацияле җәмгыятькә ят булган сыйфатлар тагыла, ә ул дәреслекләр буенча Россия балалары тарих фәнен өйрәнәләр бит.

Россия тарихында татарлар уйнаган рольгә башка карашлар да бар, әлбәттә. Бөек галим һәм гражданин Лев Николаевич Гумилев «татар-монгол изүе» дигән нәрсәне халыкларның үзара мәнфәгати кызыксынуы, тартылуы нигезендә ту-

ган союз дип атый: русларга татар гаскәрләре көнбатыш чикләрне сакларга кирәк була. Ә русларның иминлеге өчен татарлар җыйган ясакны («десятина») һич тә зур дип әйтеп булмый. Ләкин Л.Н.Гумилев кебек үзгә, гадәти булмаган фикер әйтергә батырчылык иткән тарихчылар бик сирәк шул.

Тарихны бизәп күрсәтүнең бер кирәге юк. Теләсә кайсы чорда, теләсә кайсы халык тарихында күркәм сыйфатлар да, рәхимсезлек тә, күтәрелеш һәм түбәнгә тәгәрәү очракларын да табарга мөмкин.

Бүген исә тарихта бүтән нәрсәләрне – гакыл казанышларын, сәүдә элемтәләрен, мәдәниятләрнең үзара баюын күрә белү мөһим.

Татарлар тарихы гасырлар чоңгылына кереп югала. Татар этносы элементлары составын-



да борынгы заманнарда һуннардан, кыпчаклардан килеп чыккан болгарларны, нугайларны һәм Кытай чикләреннән Дунайга чаклы киң далалар буйлап күченеп йөргән башка төрки кабиләләрне табарга мөмкин. Ләкин хәзерге Татарстан җирендә яшәгән беренче татар дәүләте дигәндә, унынчы гасырны күздә тотарга кирәк.

922 елның маенда, бик зур юл газаплары күреп, Багдад хәлифе илчелеге Чулмандагы Бөек Болгар шәһәре җиренә аяк баса. Бу 922 елның 16 маенда Ислам динен рәсми төстә кабул иткән Болгар ханлыгын үзенә бер төрле халыкара тану була.

Бүгенге татарларның ата-бабалары – болгарлар югары мәдәниятле халык булган. Алар чуен коя белгәннәр, сууткәргечләре булган шәһәрләр төзегәннәр, югары үсеш алган фәнгә, әдәбият һәм сәнгатькә ия булганнар. Кол Галинең 1233 елда язылган бөтен көнчыгыш шигъриятенә зур йогынты ясаган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы татар әдәбиятының классик әсәре булып тора.

Болгар дәүләте рус кенәзлекләре белән килешүле мөнәсәбәтләрдә яши һәм Көнчыгыш Европа сәясәтенә дә йогынты ясый. Казан ул чакта әле бары тик төньяк чиктә кальга гына була.

Татарлар тарихының шуннан соңгы этабы – Алтын Урда чоры.

Нәкъ менә шушы гаять зур дәүләт сәясәте аркасында татарлар бөтендөнья тарихына кереп калалар да инде. Ханнар Алтын Урдада да, аннары Казанда да, әлбәттә, Чыңгыз токымыннан, ягъни монголлар булганнар, ләкин алар ул вакытта инде төрки телдә сөйләшкәннәр һәм шактый татарлашканнар. Алтын Урда Чыңгыз хан кануннары җыелмасы – «яс»лар нигезендә төзелгән. Татар-монголлар хәрби эштә генә зур югарылыкка ирешеп калмаганнар, ә үз вакыты өчен камил идарә системасы да төзегәннәр. Шуның белән бергә Чыңгыз ханның «яс»лары башка диннәргә гадәттән тыш зур ирек биргән. Нәкъ «татар-монгол изүе» чорында православие дине чәчәк ату һич очраклы түгел. Үзбәк хан иң беренче булып Чыңгыз хан васыятен бозарга батырчылык иткән һәм рәсми дин сыйфатында

Ислам динен кабул иткән. Хәер, православие динендәге русларга моның кагылышы булмаган.

Алтын Урда чорын гел начар итеп күрсәтергә ярамый. Чәчәк аткан дистәләрчә шәһәрләр төзегән бу дәүләтнең иҗади ягын да күрә белергә кирәк. Алтын Урда дәүләте, сәүдә өчен куркынычсыз юллар салып, Көнбатыш белән Көнчыгышны тоташтыра. Бу чорның казанышы әнә шунда да. Чыңгыз хан токымына кадәр Көнбатыш белән Көнчыгыш асылда мөстәкыйль, аерым яши торган дөнья булганнар. XIII-XV гасырларда Бөек Дала аларны бербөтенгә берләштергән.

Алтын Урда аркасында үзара көрәш белән мәшгуль рус кенәзлекләре Мәскәү тирәсенә тупланалар. Халык исәбен төгәл алып торган хан, аның катгый кануннары, Урданың коммуникация системасы булмаса, бөек Россия дә булмас иде. Руслар әле үзара мөнәсәбәтләрен ачыклау белән бик озак шөгыльләнеп, тарихи инициативаны күршеләренә бирерләр иде.

Империяләр туа һәм таркала. Алтын Урда да шундый ук язмышка дучар булган. Аның нигезендә Казан, Әстерхан, Себер, Кырым, Касыйм ханлыклары һәм үз тирәсенә рус кенәзлекләрен берләштергән Московия барлыкка килгән. Шулвакыттан русларның Көнчыгышка омтылышы башлана. Рус дәүләте экспансиясен, имеш, әледән-әле һөҗүмнәре белән Мәскәүне бимазалап торган «мәкерле татарларны» акылга утыртырга теләү белән аңлатырга маташучы тарихчыларны аңлау җиңел түгел. Бу дәлилнең Иван Грозный өчен бернинди роль уйнамавын ачыклар өчен, мәскәүлеләрнең казанлыларга, ә казанлыларның мәскәүлеләргә ничә кат һөҗүм ясавын санау да җитә.

Халыкның тарихи хәтере белән теләсә ничек уйнарга ярамый. Җырларында һәм риваятьләрендә татарлар Бөек Болгар, Алтын Урда каһарманнары, Сөембикә турында матур истәлекләр саклыйлар. Алар Иван Грозныйның канлы образын да, диннәргә тигез караш турында указ чыгарган әби патша Екатерина Икенченең кешелекле адымын да хәтердән чыгармыйлар. Боларга күз йомарга, кешеләргә ялган тарих көчләп тагарга һәм бигрәк тә бер генә халыкны да түбәнсетергә ярамый. Татарлар үзләренең үткәннәренә гаделсез карашка аеруча сизгер. Үзәкнең бу мәсьәләдә сәясәтен аңлау авыр.

Әгәр Россия, Конституциядә язылганча, күпмилләтле дәүләт икән, ул чакта гражданлык җәмгыяте төзергә, балаларда татарларга һәм башка халыкларга дошманлык хисе тәрбияләргә түгел, ә аларны тарихның объектив характерын аңларга өйрәтергә кирәк.

Демократия шартларында Россия дәүләте тарихына «рәсми» караш кына көчләп тагу читен эш. Россия үз тарихына объектив карашка мохтаҗ. Һәм андый тарих гаять зур мәйданны эченә алган дәүләт үсешенә үзеннән лаеклы өлеш керткән барлык халыклар галимнәре тырышлыгы белән, бары тик күмәк язылырга тиеш. ■

Болгар.
Ак мәчет

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

2012 елның 10 июнендә киң җәмәгатьчелек катнашында ел саен үткәрелә торган «Изге Болгар җыены» көннәрендә тантаналы төстә Ак мәчет ачылды. Архитектор Сергей Шәкүров проекты буенча төзелгән Ак мәчет ансамбленә мәчет үзе, мөфти хәзрәтләренең резиденциясе һәм мәдрәсә керә. Мәчетнең гыйбадәт мәйданы – мусалла 88 колоннадан торган арка белән әйләндереп алынган, үзәгендә фонтан төзелгән. Арканың ачыклыгы нәтиҗәсендә бирегә килүчеләр табигать матурлыгын да, борынгы Болгардагы археологик казылмаларны да күрә ала.

Мәчет үзенең геометрик орнаменты, уеп ясалган бизәкләре, интерьерларының нәфислеге, гомуми стилистикасы белән таң калдыра. Гыйбадәт бүлмәсенең мәйданы – 180 квадрат метр. Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев тәкъдиме белән, бөтен дөнья мөселманнарының зыярәт кылу урыны булган Мәдинә шәһәрендәге Мөхәммәт пәйгамбәр (с.г.в.) мәчете манараларына охшатып ясалган 46,5 метр биеклектәге ике манара мәчетнең төп бинасын бизәп тора. Төп бина гөмбәзенең диаметры – 10 метр, эчке биеклеге – 17 метр, ул традицион декоратив элементлар белән бизәлгән. Төзелешендә 1200 тонна мәрмәр кулланылган. Мәчетнең ак төсе тынычлыкны һәм ниятләр чисталыгын сынландыра.

Мәчет алдындагы мәйданда күл ясалган, аның тигезлегендә гүзәл Ак мәчет тулысынча чагылып тора. ■

Борынгы Болгарда

Разил Вәлиев

Болгар җире, Бөек Болгар иле...
Тарихка мин саклыйм зур үпкә.
Бабамнарның мәгърур җаны кебек
Күтәрелә тургай биеккә.

Басу буйлап берәү җырлап килә,
Чал тарихтан килә диярсең.
Барысы да мең ел элеккедәй...
Аргамаклар чаба иярсез.

Барысы да мең ел элеккедәй:
Ай-кояшы, зәңгәр күге дә...
Бөек илдән чүлмәк ватыклары
Бүләк булып калган бүгенгә.

Бөтен нәрсә монда якын миңа,
Әйтерсең мин әнкәм куенында.
Бөтен нәрсә монда Болгарымның
Оныклары кебек тоела.

Хәрабәләр, ташлар арасында
Башын иеп тора кылганнар...
Бабайларның сүзен сөйләр өчен
Тик кылганнар гына калганнар.

...Болгар иле – бабамнарның иле,
Тургай моңы – минем моңнарым.
Мин тургайны түгел, бүген гүя
Бабамнарның җырын тыңладым.

Уңышлар сиңа, «Безнең мирас»!

Хөрмәтле каләмдәшләр!

«Безнең мирас» журналының 25 еллыгы уңаеннан сезгә ихлас котлавымны җиткерәм.

25 ел чал тарих өчен күп булмаса да, журнал шушы вакыт аралыгында укучыларына меңнәрчә мирас ядкярен тәкъдим итәргә өлгерде.

Мирас, дигәндә, милләтебезнең бай тарихи, әдәби һәм рухи хәзинәләрен күз алдына китерәбез. Алар белән танышу безгә татар халкының шанлы һәм фаҗигале тарихын тулырак аңларга, үткәннәрдән гыйбрәт алып, тиешле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә. Юкка гына: «Үткәне юкның, киләчәге дә юк», – димиләр. Үткәнне дөрес аңлау безне ялгышлардан гына саклап калмыйча, киләчәккә максат-бурычларыбызны билгеләргә дә ярдәм итә. Ә халкыбызның тарихы ерак гасырларны колачлый. Мирасыбызның да киң катламнары күтәрелмәгән чирәм хәлендә. Журнал редакциясе алдында әлеге катламнарны күтәреп, бәһасез рухи җәүһәрләребезне халкыбызга кайтару бурычы тора. Шул юлда сезгә яңа эзләнүләр һәм табышлар насыйп булсын.

Редакциянең барлык хезмәткәрләренә, аның абруйлы авторларына һәм әзерлекле укучыларына сәламәтлек, иминлек һәм уңышлар теләп калам.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе **Данил САЛИХОВ**

ЗӨЛӘЙХА*

Әзһәр Мөхәммәдиев

Икенче көнне патша сараена килү белән, керү сәгатен көтеп торучылар арасында ул әлеге divananы да күрде. Күз кабаклары шешенгән, иске төссез җиләненең ертыкларыннан пычрак арык тәне күренеп торган бу җан иясен күргәч, Бибарсның күңелендә кызгану хисе уянды, шулай да остазының сүзләрен истә тотып, аның артыннан күзәтүен дәвам итте. Дивана башка кешеләргә ияреп эчкә, патша сараена үтте. Аның авызыннан кайчак бер-берсенә бәйләнмәгән төрле сүзләр дә ычкынгалап куя иде.

Ул хөкүмәт урнашкан бина ишегеннән кермичә һәм андагы бүлмәләргә кагылып тормыйча, беркадәр читтәрәк торган патша сараена үтте. Анда да аның сыргалап эшләнгән, урамга карап торган киң имән ишекләренә тукталып та тормыйча, сарайны әйләнеп узып, арткы якта урнашкан хуҗалык ишегенә таба атлады. Ишек тәмле аш исләре чыгарып ачылып китте һәм аннан бер ашчы хатын чиләк түгәргә чыкты. Шуны гына көтеп торган дивананың авызыннан сөенеч авазы яңгырады.

* «Зөләйха» – 2 нче саннан (2016) бирле чыгып килгән «Чыңгызхан хәйләсе» әсәренең дәвамы.

«Болгар урамы».
Канәфи Нафыйков
рәсеме

Хатын аны күрү белән шулай ук җанланып китте.

– Әйдә, Хашим, калган тәмле ризыклар да бар, кер, сыйлыйм үзеңне, нарасый...

Дивананың йөзе яктырып китте. Ул куаныч белән көлә-көлә шактый ук аңлаешлы итеп хәл белеште, ничек аш әзерләгәнлекләрен, аларның тәмле ризыклар пешерүләрен, аның инде белгәнлеген, ә менә патша галиҗәнаплары кәнәгать булдымы икән, юкмы икән, дип сораштырды.

Дивана шулай көлә-көлә, сөйләшә-сөйләшә эчке катка хәрәм ирләр йөргән, катиблар утырган патша бүлмәләренә үк барып җитте. Һәр җирдә дә аны үз итеп, шаяртып каршы алдылар. Дивана да һәркем белән аның кем, кайдан, нинди эш белән шөгыльләнгәнлеген белүен күрсәтеп, үз чиратында хәл белеште, исәнлек-саулык, гаилә иминлеген сорашты. Шулай ул бөтен сарайны диярлек әйләнеп чыкты. Аннары диваналарга хас төрле мәзәк сүзләрен сөйләнүендә дәвам итеп, кире борылды һәм яңадан ашчылар бүлмәсенә керде. Аны ашчы хатыннар шундагы өстәл артына утыртып, үз хәлләре турында үзара сөйләшүләрен дәвам иткән хәлдә калдык ашлар белән сыйладылар.

Дивана шулай сөйләшкән һәм ашаган арада башка кереп чыгып йөрүче хезмәткәрләргә уралып эчкә узган Бибарс, аны күзәтүен дәвам итеп, сарайның икенче алгы ягына – ак ишеккә таба юнәлде. Ул алгы якка турыдан гына чыгып, урамда диваны көтеп торырга булды.

Зур гына зал аша узганнан соң, Бибарс тар бер коридорга килеп эләкте. Каршысына таба атлап килгән ниндидер ханымны күреп, коридор диварына сөялде һәм аска карап тын да алмыйча юл бирде. Ул бу ханымның Чәчәк икәнлеген абайламады. Ләкин кыз Бибарс янына килеп җиткәч туктады һәм аңа туры карап, назлы тавыш белән:

– Нигә минем белән сөйләшмисең, Бибарс, әллә миннән качасыңмы? – дип сорады.

– Бәлки патша кызына сәлам биреп торуны кирәк тапмыйдыр Борҗан егете? – диде арттанрак килгән кырнагы аны таныганлыгын күрсәтеп.

– Борҗан егетедер, дисеңме син аны?

– Маңгаена язылган бит, озын чәчләренә генә кара!

Бибарс күзләрен күтәреп карарга мәҗбүр булды. Ул каршысында торган дөньядагы матурларның да матуры булган гүзәл патша кызын күрде.

– Танымаганым һәм сәлам бирмәгәнем өчен гафу ит, Чәчәк бийм. Эш белән ашыгам. Бер генә мизгел вакытым да юк!

Чәчәк назлы үпкәләү һәм наян бер тавыш белән:

– Аһ, Бибарс, минем өчен шулай ук бер генә мизгел вакытың да юкмы инде синең? – дип сорады.

Егетнең телсез калуын абайлап алган яшь кенә кырнак тагын ярдәмгә килде һәм бу чорда яңа гына язылып, нөсхәләре кулдан-кулга йөргән китаптан шигырь әйтте:

Тикмә кеше гәүһәр кадерен кыяс кылмас[1],
Бу назымның, кадерене ахмак белмәс!

– Син, Айнур, андый шигырь әйтеп егетне оялтма инде, бәлки аның «Йосыф китабы»н укыганы да юктыр әле...

Бибарс җавап урынына үзе мәдрәсәдә ятлаган китаптан бер шигырь әйтте:

...Йә, Зөләйха, әйтим шуны,
Мин Мисырның хөкемдары, бел син моны,
Мисырга кил, теләр булсаң әгәр мине,
Табарсың син, шиксез, мине шунда имди...

– Ай-һай, югары чирттерә бу егет, Мисырга бармыйча һәм эзләмичә булмас инде, – диде Чәчәк көлеп.

Егет кызыксынуын баса алмыйча, кыюланып:

– Синең исемеңне Йосыф китабыннан алып кушканнармы әллә, Зөләйха? – дип сорады.

Зөләйха чая елмаеп:

– Юк, Бибарс, киресенчә Кол Гали бий «Йосыф китабы»ндагы Мисыр патшабикәсенә минем исемемне кушкан! – диде ул.

Бибарс нинди эш белән йөргәнен исенә төшереп, саубуллашты һәм ашыгып урамга чыкты, ләкин диванадан җилләр искән иде инде. Ул сарай капкасына йөгерде. Капканы чыгып урамнан беркадәр баргач, ниһаять, дивананың урамнан сулга таба тар гына икенче бер тыкрыкка борылып кереп китеп барганын күреп калды.

Бибарс та аның артыннан китте. Бераздан тыкрык тар гына бер урамга әверелде. Ул урамнан шактый гына барганнан соң, дивана, тагын бер тыкрыкка таба борылып, бакча эчендә утырган зур гына йортның капкасын шакыды. Кемдер ашыгып чыгып капка ачты. Ихатаның бура коймалары тыгыз һәм биек булганга күрә, Бибарс ишегалдында аны кем каршы алуын күрә алмады.

Бура койма өстеннән күренеп торган бүрәнә өйнең кай тирәдә урнашканлыгын хәтерләп һәм чамалап ул инде кайтып китеп барганда, әле генә дивана кергән ян капкадан шактый пөхтә киемле берәүнең чыкканлыгын абайлады. Аннары ул, гаҗәпләнүенә каршы, сикереп атка атланган бу пөхтә киенгән кешенең шул ук дивана икәнлеген абайлады һәм күзгә чалынмаска тырышып, тагын аның артыннан китте.

Тыкрыкларны үткәннән соң әлеге атлы кеше зур урамга чыкты һәм шәһәр

[1] Кыяс кылмас – аера белмәс.

читенә таба юл тотты. Беркадәр барганнан соң, ул агач йортларны артта калдырып, кызыл кирпечтән салынган кәрвансарайга якынлашты һәм анда таш баганалы ачык капкадан узып, эчкә – кәрвансарайга кереп китте. Бирелә кешеләр иркенләп һәм күпләп кереп-чыгып йөргәнгә күрә, Бибарс та кәрвансарайга үтте һәм аның ишегалдында әлеге кешенең сәүдәгәрләргә тауарларын куеп торырга дип төзелгән амбарлардан сулдарак, дөяләр өчен салынган абзар каралтылары буенда буйлы-буйлы җилән кигән Кашгар сәүдәгәре Мөхәммәт Кушлавыч белән сөйләшеп торганлыгын күрде. Озак кына сөйләшкәннән соң, әлеге «дивана» кәрвансарайдан чыгып, килгән юлыннан китеп барды.

Сәүдәгәрнең, хезмәтчесен ат мендереп каядыр җибәрергә җыенганын күргәч кенә Бибарс та кайтыр якка таба борылды.

Көн кичкә авышты. Ул тынычланып, кайтып ук китмәкче булган иде, ләкин атына атланып өлгергән кешенең артыннан килүен күргәч, борчылуы артты. «Бу кара йөз теге шымчының бөтен күргән-белгәнен Чыңгыз ханга илтеп җиткерәчәк инде», – дип уйлап алды. Урам тар булуга карамастан, арттагы кешенең аты якынлашып килгәнен сизсә дә, юл бирмәде. Колак төбендә ат сулышы көчәйгәч, ул юл уртасында туктап борылды.

– Өскә менәсең бит инде, башка юл юкмы әллә, ләгъзин!

Атлы кеше дәшмәде. Болгар егетләре булса, юл бирмәгән кешене өзәнгесе белән бәреп очырып үтәр, әмма үзе башлап юл сапмас иде. Әлеге кешенең пычакка-пычак килердәй мыскыл сүзенә түземле булуы анда болгарлык булмавы турында сөйли иде.

– Мин сине «чучка» дип атадым, җаным! – диде ул болгарларча «җаным» сүзен өстәп.

Атлы кеше, янап, билбавындагы пычагына үрелде.

– Кит юлдан!

Шуны гына көткән Бибарс кинәттән генә аның тезгененә ябышты.

– Кыпчак егетен пычак белән куркыталармыни, ахмак! – диде ул атлының пычак тоткан кулын әләктереп һәм аны сеңерләре шыгырдавы ишетелгәнче каерып. Аннары яшен тизлеге белән җайдакның артына сикереп атланды һәм аның кабыргасына пычагын сизелерлек үк итеп терәп:

– Тының чыкмасын, атлат атыңны! – диде.

– Кем син? Нигә урамнан үтеп барган кешенең юлын бүлеп, аңа бәйләнәсең?

– Патша чауышы мин.

Теге кешенең куркуыннан йөзләре агарынды.

– Мин каравыш кеше. Ни кушсалар, шуны эшлим. Минем гаебем юк.

– Ул кадәрлесен патша яраннарына сөйләрсең. Шәһри Болгарда гаепсез кешене кыерсытмыйлар, – диде ул ике җайдаклы булып алган атның тезгенен патша сараена таба тартып.

Бибарс Баян бүлмәсендә озак кына аны көтеп утырды. Бераздан остаз килеп керде. Аның йөзе ачык, ә күңеле күтәренке иде. Күрәсең теге Бибарс алып килгән кеше белән ул ачык итеп сөйләшергә өлгергән иде. Тик остаз, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, ишеккә таба кире борылды.

– Тагын бераз гына сабыр ит, Бибарс, хәзер керәм, – диде ул һәм каядыр чыгып китте.

Берникадәр вакыттан соң Баян ниндидер бер кеше белән килеп керде. Өстенә

кигән чөгәсенең алтын җепләр белән нәзакатьле итеп чигелгән булуын күрмәсә, Бибарс бу урта буйлы, юка гәүдәле, зыялыларга хас ак йөзле, коңгырт күркәм сакаллы кешегә артык зур игътибар да бирмәс иде.

Баян әлеге кешене ихтирам белән ишектән үзеннән алдан уздырып:

– Солтан галиҗәнаплары, рәхим итегез вәзирегез бүлмәсенә. Бу – йомышчы егет Бибарс була. Ул барысын да бөртекләп үзе сөйләр, – диде.

Бибарс дулкынлануыннан сикереп торды һәм солтанның үткен күзле йөзенә күтәрелеп карап, баш иеп сәламләде.

– Сәламәт бул, – диде патша тыныч тавыш белән. – Димәк, шундый мин көткән кирәкле хәбәрне хуҗасы-ние белән китерүче егет син буласың?

Бибарс бөтенләй югалып калды. Аның патша кадәр патша белән сөйләшү хыялына да кергәне булмаганлыктан, ул үзен ахмакларча хис итте һәм ни дип әйтергә дә белми торды. Әмма патшага бу күркәм ачык йөзле, ыспай төзек гәүдәле кыпчак егете ошады. Ул «аркасыннан сыйпамасаң, мәченең дә умыртка сөягеката» дигән мәкальне истә тотып, үзенә тугрылыклы булган кешеләрне тәхетенә якынайтырга омтыла иде.

– Вәзир, безне бу егет белән бер генә мизгелгә калдырып тор.

– Баш өсте! – дип Баян чыгып киткәч, патша конгырт сакалын сыйпап алды һәм уйланып:

– Бәлки, йегет, бедгә кыпсак телендә сүләшү жаксы булыр? – дип сорады.

Патшаның болай төрле кыпчак кабиләләре тел үзенчәлекләрен бутап сөйләшүе Бибарска кызык тоелды һәм аның каушавы берьюлы бетеп китте.

– Юк, падишаһ галиҗәнаплары, мин сөйләшә дә, укый-яза да беләм.

Гадәттә, әдәби болгар теленең «төрки» дип аталганлыгын Колгали яки Бакыргани кебек атаклы шагыйрьләрнең үз әсәрләрен шул ук телдә язганлыкларын ул яхшы белә иде.

– Хөкемдарларны шулай яратып бетермиләр инде аны, күрәсең яратмый мине беркем дә, – диде патша кинәт кенә төшенкелеккә бирелгәндәй итеп, – хөкемдарны кем яратсын инде?

– Остаз Баян сине, патша галиҗәнаплары, туган Болгар илен яраткан кебек өзелеп ярата. Мин дә...

– Рәхмәт. Син моны эшең белән расладың. Каравашны кулга алып киткәнлегеңне сәүдәгәр үзе күрмәдеме?

– Юк, әфәндем. Мин кәрвансарайдан шактый ерак киткән идем инде...

Патшаның кызыксынуын тоеп, Бибарс күргәннәре турында аңа бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Патша игътибар белән тыңлаганнан соң:

– Рәхмәт, мине синең хәбәрең куандырды, егет, – диде.

Бибарсның күзләрендә шатлык очкыннары чагылып үтте, әмма йөзе дала кешесенә хас тынычлыгын югалтмады.

– Үзегезгә рәхмәт, патша галиҗәнаплары, аны искә алганыгыз өчен. Ә ул каравыш һәм шымчыга нинди җәза булыр икән, әгәр сорарга яраса?

– Хезмәтенә карап җимеше. Гаепсез кешене рәнҗетмәбез. Урал таулары җир катында алтын-көмеш чыгарыр өчен эшче куллар җитми, дип зарланалар... Җир каты, эше авыр – тиз үләләр икән. Шуңа күрә, ерак ялан-япанга ат чабып, каравыш көчен юкка әрәм-шәрәм итмәсен, патша казнасын баетсын, дидек. Ә шымчыны төнлә буып суга ыргытырга әмер бирелде. Идел киң һәм тирән бит ул!

– Ә нигә төнлә? – дип сорады Бибарс чирканып.

– Чыңгызхан үз шымчысының күптән дөньяда юк икәнлеген белмәсен, ә аның хәбәрен көтсен өчен. Көтү яхшы эш, өметле нәрсә ул, дип фараз кылдык. Синең ярдәмең белән, егет. Сизгерлегең, күзәтә һәм нәтиҗә ясый белүең мактауга лаек.

Патша күзләре белән бер ноктага текәлеп үзен борчыган ниндидер бер уйны уйлап торганнан соң, Бибарска карады:

– Мин сине, егет, Сүбәдәй баһадирга илче итеп җибәрергә, дип уйлап торам.

«Гаҗәп хәлләр, илче!» – дип уйлап алды Бибарс, әмма үзенең куанычын сиздермәскә тырышты.

– Зурлавың өчен рәхмәт, патша галиҗәнаплары, тик минем бервакытта да илче булып караганым юк. Булдыра алырмынмы икән?

Патша күзләре белән генә елмайды:

– Илче булып тумыйлар, егет. Аннары Хаҗи тархан кебек морзаларны илче итеп җибәрә алмыйм бит инде мин. Очрагы башка. Андый илчелек өч-дүрт атна юлда булып, кырык-илле кешедән торырга тиеш. Ә моның өчен безнең вакытыбыз таррак. Син үзең генә барырсың һәм минем шәхси илчем булырсың. Иптәшкә берәр кеше ияртсәң дә начар булмас. Мангуллар фарсы җирләрен басып алып, Азәрбайҗанны, Каф болгарларын яулап яталар. Син өч-дүрт көн эчендә безнең Идел тамагы шәһәре Саксинга төшеп җитәрсең, ә биш-алты көн дигәндә инде Сүбәдәй станында булырсың. Берочтан Суар, Самар, Бөрҗан яки Машаек һәм Саксин ямнарын тикшерерсең. Баян вәзир анда тәртип кертелде, дип белдерде. Хаҗи тархан дигәннән, ул миңа синең турыда сөйләп өлгерде. Шуңа күрә илче итеп сине җибәрергә уйладым да мин.

Бибарс чын куңеленнән гаҗәпләнде:

– Хаҗи әфәнде минем турыда мактау сүзе әйттеме?

Патша елмайды:

– Мин бит мактау сүзе әйтте, димим, егет. Дөресен генә әйткәндә, киресенчә, яман сүз. Җик вәзир кайберәүләрнең үкчәсенә баскач, алар миңа зарланырга киләләр һәм шуңа күрә вәзир белән берочтан аның яраннарына да эләгә. Ул сине коллыкка бирергә тәкъдим итә.

– Ни өчен икән, әфәндем?

– Син патша бакчасына да күз саласың икән...

– Юк сүз бу, әфәндем, мин йомыш белән генә, шул шымчы артыннан йөрдем!

– Ярар, яхшы. Мин бу турыда кызымны яратканга күрә генә сөйлим. Шуңа курә гөлчәчәге кебек җитеп килгән гүзәл бер патша кызын күргән егетнең йөрәгендә ихтирам һәм соклану хисе уянмаса, мин гаҗәпләнер идем... Илчелек турына килсәк, барлык нечкәлекләрен дә вәзир Баян белән сөйләшерсең. Ул тәҗрибәле һәм укымышлы кеше...

– Әгәр шулай кирәк дип тапсагыз, әфәндем, баш өсте!

– Бу минем өчен яки Болгар йорты өчен генә түгел, ә халыклар иминлеге өчен дә кирәк һәм зур әһәмиятле вазифа, Бибарс! Шуны онытма, һәрвакыт исеңдә тот. Ә хәзер, бар, вәзирне монда чакыр, ә үзең юлга әзерлән...

Дәвамы бар ■

«Мирас», №10, 2004 ел

ГӘҮҺӘРШАД

Фирдәвес Зариф

Тарихи хикәя

Гәүһәршадның бүлмә ишеген шакыдылар.

– Әйе, керегез.

Бикә бүлмәсенә, сулуы кабып, карачы йөгереп керде:

– Ханбикә, шомлы хәбәр китерүем өчен алдан ук кичерү сорыйм! Урыслар...

Гәүһәршад аны сабыр-ипле генә бүлдерәсе итте:

– Ханбикә дип әйтмәү хакында мин сине кисәткән идем шикелле, Тугыш карачы.

– Кичерегез, бикә! Алтын Урда ханнары нәселеннән булган Ибраһим хан кызына мин башкача эндәшә алмыйм.

– Казанда нәселгә карап түгел, ә тәхет биләүгә карап баш ияләр, Тугыш карачы.

– Анысы шулай, бикә. Әмма ул тәхет хуҗалары соңгы вакытларда килмешәкләрдән генә тора башлады шул. Килмешәкләр басты Казанны!..

– Хак сүз сөйлисең, Тугыш карачы. Мәҗлес әһелләренең, бәкләр, морзалар һәм угланнарның күпчелеге – килмешәкләр. Килмешәкләр хәзер татар иле, Казан, илкөн язмышы белән сату итә! Сер сакларлык, киңәшерлек кеше дә бетеп бара Казанда. Кемне алма, шул шымчы... Сүз сөйләрлек кешеләрдән сәед белән син генә калдың.

– Ышанычыгыз өчен рәхмәт, бикә. Сүзегез – хакыйкать! Аксөякләрдән ил язмышын кайгыртырлык кеше калмады шул.

– Ярый, читкә киттек, карачы. Хәбәреңне әйт.

– Урыслар Зөя кирмәненнән Казанга яуга кузгалган, бикә. Алар белән Шаһгали, качкын ханнар һәм морзалар гаскәрләре дә бар, ди.

– Шаһгали... Бикәсе дә аның беләнме?

– Әйе, ханбикә... кичерегез, бикә.

– Казанны алып, берсе – хан, икенчесе ханбикә буласы килә, димәк. – Гәүһәршадның йөзе ачу-нәфрәттән алсуланып чыкты. – Бу хакта хан хәзрәтләре беләме?

– Юк әле, бикә. Җиткерергә өлгермәдем.

– Кичекмәстән җиткер. Бер очтан, Шәрифкол сәедкә дә сугылып чык.

– Баш өсте, бикә, баш өсте.

Тугыш карачы, түбәнчелек белән баш иеп, ишеккә таба арты белән чигенде дә, юк булды.

***

Шартлау тавышлары тынып, җимерек дивар тузаннары басылырга да өлгермәде, Шаһгали һөҗүм башларга әмер бирде. Җимерелүдән хасил булган аралыкларга, җанлы дивар булып, Казанны саклаучылар басты. Җанлы калканга бәрелеп, «маңгаен авырттыргач», Шаһгали Нугай капкасына юнәлде. Әмма казанлылар, капкадан чыгып, аларны чигенергә мәҗбүр иттеләр. Шуннан соң Шаһгали, каберләр өстендәге агачларга яшеренеп, Болакны кичте һәм Арча тарафына үтте. Арча кап-

Зөфәр Хәкимов рәсеме

касы буендагы бәрелештә, сан ягыннан өстенлек һәм зур югалтулар исәбенә ул, ниһаять, ныгытма эченә үтеп керүгә иреште. Һәр адым коточкыч кыйммәткә төште сатлык татарларга. Берничә сәгать дәвамында алар бер адым да алга китә алмадылар. Инде көн төшкә авышкач, алар артыннан калага, аяк атларлык ара калмый түшәлгән җансыз гәүдәләргә басып, урыс гаскәриләре тулды. Хәер, биредә аларга да эш калган икән әле. Беришләре, ыңгырашу авазларын ишетеп, яралыларны сөңге белән чәнчеп чыкса, икенчеләре инде сакчыларсыз калган йорт, мәчет ишекләрен ватып кереп, биредә яшеренеп торган хатын-кыз, карт-карчык, бала-чагаларга ташландылар. Кычкырыш, елаш китте. Урыслар барлык ир-атларны, арба көпчәгеннән калкурак булган ир балаларны суя башладылар. Аларны яклап арага кергән хатын-кызларны да аяп тормадылар. Гүзәл хатын-кызларны һәм мал-мөлкәтне дивар аръягында-

гы лагерьга озата бардылар. Кулга эләккән алтын-көмешне, патша малы исәбенә кертмичә, изүгә генә шудырдылар...

Ә кала үзәгендә аяусыз кырылыш бара иде. Шаһгали сугышка өстәмә көчләр кертте. Кенәз Курбский аңа ярдәмгә кенәз Воротынскийны һәм, патша рөхсәте белән, Иоанн запас полкының бер өлешен җибәрде.

Ядгәр хан яугирләре белән акрынлап төньякка таба чигенә башлады һәм Таҗик чокыры аша аргы якка чыкты. Шулчак аларга ярдәмгә Шәрифкол сәед җитәкчелегендәге дин әһелләре һәм шәкертләр кушылды. Ядгәр хан ярсулы һөҗүмгә күчте. Сирәгәйгән Шаһгали гаскәриләре тәртипсез рәвештә чигенә башладылар. Алар артыннан килгән урыс полклары да куркып-каушап калды, чигенү җаен карады. Тора-бара, чигенү качуга әйләнде. Качучылар талаучы башкисәрләр белән тигезләшкәч, тегеләр, таланган әйберләрен ташлап, куркудан күзләрен акайтып, төрле якка сибелделәр:

– Каравыл, бетерәләр!

– Татарлар килә, качыгыз!

Котылу юлын таба алмагач, күпләр дивар коймасыннан ташланды.

Урысларны җиңелү ачысын татудан Шаһгалинең поскында торган атлы гаскәре коткарып калды. Алар Ядгәр хан яугирләренең сирәгәйгән сафларын чигенергә мәҗбүр иттеләр. Әмма Шәрифкол сәед җитәкчелегендәге дин әһелләре, шәкертләр һәр адымны үтә тәвәккәллек белән сакладылар һәм һөҗүм итүчеләрне җамигъ мәчетенә якын җибәрмәделәр. Бары сәед һәм аның тарафдарлары һәлак булгач кына Ядгәр хан яугирләрен хан сараена кысрыклауга ирештеләр. Сарай капкалары янындагы аяусыз сугыш сәгатьтән артыкка сузылды. Капка сакчылары һәлак булгач, урыслар, капкаларны ватып, Шаһгали татарлары белән эчкә бәреп керделәр. Алар күзенә бер якта дәрәҗәле татарлар һәм җансакчылары белән хан, икенче якта затлы киенгән меңнән артык гүзәл зат күренде. Һөҗүм итүчеләр Ядгәр хан яугирләренә ташландылар. Калку урынга менеп басып, сарайны саклаучылар белән җитәкчелек иткән Гәүһәршадны Шаһгали шундук танып алды:

– Бирелегез, бикә! Хан кызы булганга, мин олуг патшадан Сезгә ярлыкау сорармын.

– Мин этләрнең кызгануына мохтаҗ түгел, Шаһгали! Кяферләр патшасына койрык болгап йөрдең, үлемең дә баскыч астында булыр...

Бу сүзләр Шаһгалинең йөрәгенә хәнҗәр булып кадалды. Ул бер агарынды, бер күгәренде. Аннары, исенә килеп, үзен уратып алган яугирләргә: «Алыгыз аны!» – дип боерды.

Гәүһәршад, янында басып торган җансакчысының кылычын алып, үзе үк Шаһгалигә таба ыргылды. Шуны гына көткән гүзәл затларның кулында хәнҗәр һәм кыска кылычлар пәйда булды.

Хатын-кызларның батырлыгын күреп, Ядгәр хан яугирләре гайрәт белән дошманга ташландылар һәм аны сарай капкаларыннан кысрыклап чыгардылар. Әмма шулвакыт дошманга ярдәмгә яңа көчләр килеп җитте. Гүзәл затларның барысы да, дошман кулына бирелми, сарай капкалары янында ятып калды. Гүзәллекләре белән илчеләрне дә сокландырган чәчәктәй гомерләр шулай өзелде. Алар арасында егылганда да кулыннан кылычын төшермәгән, Казан халкының йөз аклыгы, намусы булган ватанпәрвәр – Ибраһим хан кызы Гәүһәршад та бар иде.

Гәүһәршадның сөттәй ак күлмәгенең күкрәк турысы шәфәкъ кызыллыгы төсенә кергән. Коеласы татар канының әле азагы күренми, ә татар дәүләтчелегенең кояшы баю ягына авышкан иде... ■

15 ОКТЯБРЬ – ХӘТЕР КӨНЕ

КЕРЕШ СҮЗ

Урыс елъязмаларының 546 биттән, 101 бүлектән торган 19 нчы томы Казан ханлыгы тарихын язуга багышланган. Чыганакларда ул тарих 1564-1566 елларда язылган, дип күрсәтелә. Аны иске славян теленнән хәзерге урыс теленә профессор Н.В.Водовозов тәрҗемә иткән. Шуның татар теленә тәрҗемә ителгән кыска гына өзекләре Хәтер көнен искә алу уңаеннан «Безнең мирас» журналына тәкъдим ителә. Беренче тапкыр ул бераз үзгәрешләр белән 2002 елда «Мирас» журналының 10 нчы санында басылып чыккан иде. Беркадәр тарихилыкны, шул чордагы әдәби телне, шигъри үлчәмне, ритм-рифманы саклау максатында әдәби тәрҗемәдә иске татар сүзләрен, гарәп-фарсы алынмаларын да кулланырга, аларның хәзерге әдәби телгә тәрҗемәләрен дә бирергә туры килде.

1552 елда Казан ханлыгының, Явыз Иван тарафыннан коточкыч вәхшилек, кансызлык-рәхимсезлек белән басып алынуы, җимерелүе, халкының кырылуы, талануы, канга батырылуы турында бик күп истәлекләр, язмалар, әдәби әсәрләр барлыкка килә.

Әлеге гаять зур күләмле елъязма нигездә Явыз Иванның Казан ханлыгын басып алуына, мөселман халкын кара канга батырып кырып, бар байлыгын талап алып бетерүенә, шул исәпкә урыс дәүләтен зурайтуына, христиан динен көчәйтүенә чиксез шатланып, мәдхия яудырса да, шул тарихи фактларны хәтта ул да яшереп кала алмаган. Шушы кыска гына өзекләрдә дә ул шактый чагылыш таба.

Явыз Иван явының дәүләтебезне җимерүе нәтиҗәсендә халкыбыз 4-5 гасыр дәвамында баскыннар тарафыннан кырылып, таланып, хокуксыз булып яши. Ошбу хакта 1935 елда «Казан китүгә 383 ел үтте» дигән мәкаләсендә **Гаяз Исхакый**: «*Бу 383 ел эчендә Казанның төп халкы төрек-татарның өч кенә елы да халкыбыз үзе теләгәнчә, үзе аңлаганча рәхәт итеп тора алмагандыр. Бу 383 елның тарихын тикшерсәк, без төрек-татарның канлы яшәешенең өзелмәенчә дәвам иткәнен, вә ара-тирә шул күз яше катып китеп, милләтнең тешен кысып, куәтен җыеп шул дошман золымыннан котылырга атылганын күрәбез*», – дип язган. Шуннан соң 80 ел вакыт узып китсә дә, бу сүзләр бүген язылгандай тоела.

Хәтер көне безне шул тарихи хәтерне онытмаска, дәүләтебезне торгызырга, бәйсезлек-мөстәкыйльлеккә омтылырга чакыра.

Хәнәфи Бәдигый

КАЗАН ПАТШАЛЫГЫ ТУРЫНДАГЫ ТАРИХ[1]

(Урыс елъязмасы битләреннән)

Әсәр шагыйрь, җәлилче-галим Хәнәфи БӘДИГЫЙНЫҢ әдәби тәрҗемәсендә бирелә

«Казанны алу». Г.Медведев рәсеме

КАЗАННЫ САКЛАУЧЫЛАРНЫҢ УРЫС ПАТШАСЫНА ҖАВАБЫ

Түземлеген төкәндереп патшаның
Тәвәккәлләр әйтеп салды аһ-зарын:

– Сабыр берлә тыңла, Мәскәү патшасы:
Казан ханы, Казан халкы изкярын[2]:

«Син белеп тор! Без кырылып бетсәк тә,
Мал-гыялдан[3] тәмам өмет өзсәк тә,

Хаклык өчен керсәк тә хәтта гүргә,
Тезләндерә алмас бәгуз[4] гомергә.

Җанны алсаң да, алалмассың Иманны,
Таптамабыз җиребезне – Ватанны,

Мирас булып калган гореф-гадәтне,
Ходай үзе бүләк иткән мәдәдне[5].

Башкалабызга мөкиббән бар җөмһүр[6] –
Безнең үскән, кендек каны тамган җир.

Мәрхәмәтле булды барча ханыбыз,
Кыйтгаларга мәгълүм безнең даныбыз.

Беләбез: байлыгың синең бихисап,
Шәһәрләрең дә күп, диләр,
булыр сәдъ[7].

[1] Елъязманы хәзерге урыс теленә профессор Н.В.Водовозов күчергән.
[2] Изкяр – искәртү, исенә төшерү, хәтерләтү.
[3] Мал-гыял – байлык, өй җәмәгате, бала-чага.
[4] Бәгузә – черки, сукыр черки.
[5] Мәдәд – ярдәм, булышлык.
[6] Җөмһүр – җәмәгать, халык.
[7] Сәдъ – йөз (100).

Бездә фәкать бер шәһәр бар – башкала,
Чиры туплап, алмакчы син изага[8].

Тик уйлама: икейөзлек, янаулар,
Буйсындырмакка халыкны – юк алар.

Беләбез синең мәкерле хәйләне:
Бирелгәннәр күрде шундый сәйеәне [9] :

Утка аттыгыз тезләнергә килгәнне,
Күрделәр синең каһкаһә көлгәнне.

Булмабыз шаһиты мондый золымның,
Тыңламабыз гол [10] – зынҗарларның чыңын.

Көч белән алынса әгәр бу шәһәр,
Башланыр монда кыямәт – чын мәхшәр.

Тапталачак шәригать кануннары,
Урыс гадәтләре керер аннары».

ЧИРМЕШЛӘРНЕҢ БАТЫРЛЫГЫ ҺӘМ ГАЗАПЛЫ ҺӘЛАКӘТЕ

Казанлылар саклаганда каланы,
Урыс явын кортты чирмеш зыяны.

Алар төнлә оста һөҗүм иттеләр,
Көндез күп атларын урлап киттеләр.

Һөҗүмгә күчкәч, ярсыган урыслар,
Гаиб булдылар[11] тиз үк черемислар[12] ,

Чытырманлык, чокыр-чакыр, текә яр –
Әһле салибларга[13] булды капкын, гарь[14].

Черемислар пәйда булалар[15] кинәт,
Салибларны дөмбәслиләр төркемләп.

Өч көн баргач урыс явы ал-ялсыз,
Төшлектә камалды чирмеш бик җайсыз.

Йорт-җир, гавам[16] ут эчендә, юк чара,
Меңләгән халкы кырылды, бичара.

Биш яу башы, биш йөз аксөякләре,
Әсир төштеләр һәммәсе – альләре[17].

***

Урыс явы кавемнәрен[18] әсир итте,
Затлыларын атка бәйләп алып китте.

Арчаның унике кенәзе төште әсир,
Чирмешнең җиде яу башы – тотык кәбир.

Өч йөз азамат йөзбашы бар арада,
Биш меңләп тоткынның күбесе ярада.

Казан ханын бирелергә өндәп-янап,
Тоткыннарны китерделәр кабат-кабат.

Тотыкларның ялварулы елаулары –
Баскыннарның хәйлә-мәкер, алдаулары.

Патша күрде – тырышлыкның буш икәнен,
Вәгъдәсенең чынга ашмас хаша[19] икәнен,

Казанлылар горурлыгы – син мәсхәрә,
Буйсынырга өндәүләрең – калды шәрә.

Ачуыннан шартлар чиккә җитте патша,
Канлы суеш белән янап, тәмам шаша.

Ярсуыннан «мәрхәмәтен» чынга ашырды –
Җиде мең чирмешне гаскәргә тапшырды.

Казыкларга утырттылар ма ягыннан[20],
Күпчелеген дарга астылар аягыннан.

Кылыч белән туракланды калганнары,
Котлары очсын һәм югалсын, дип аңнары.

Вәхшилекнең тәэсир көчен белә алар:
«Казанлылар кан коймыйча бирелерләр».

[8] Изага – бетерү, югалту, юкка чыгару.
[9] Сәйеә – начарлык, явызлык, бозыклык.
[10] Гол – муенга сала торган богау, чылбыр.
[11] Гаиб булу – күз алдында булмау, юкка чыгу.
[12] Черемислар – чирмешләр (мари халкының электәге исеме).
[13] Әһле салиблар – тәре сугышын оештыручылар.
[14] Гарь – хурлык, оят.
[15] Пәйда булу – күренү, килеп чыгу.
[16] Гавам – халык.
[17] Аль – гаилә, өй җәмәгате.
[18] Кавем – кардәш халык, нәсел.
[19] Хаша – һич, беркайчан да булмаслык.
[20] Ма ягыннан – шул (арт) ягыннан.

КАЗАННЫ САКЛАУЧЫЛАРНЫҢ БАТЫРЛЫКЛАРЫ

Казанлылар өмет өзгәч, бар ярдәмнән,
Урыс явы китермәсен дип җәһәннәм,

Алмашка дип һәлак булган ир-атларга,
Хатын-кызлар сафка басты ил сакларга.

Өйрәнделәр сөңге белән сугышырга,
Диварларда[21] корал белән орышырга.

Кыю кызлар хәрби кием киенделәр,
Шуңа алар яугир булып күренделәр.

Тик шулай да хатын-кызның күңле нечкә –
Кыргыйлар да бирелә шул курку-хискә –

Казанлылар ныгыттылар үз шәһәрен,
Сындырырга урысларның бар зәһәрен.

Балчык өеп, таш койма, капка койдылар,
Бөтен җиргә туплы кораллар куйдылар.

Тәҗрибәле яу башлары план корды,
Яугирләре дошман юлын саклап торды.

Казанлылар һөҗүмнәрне кире какты,
Җәяүлегә һәм атлыга туптан атты.

Урысларның ташкын явы килә торды,
Казанлыларның сафлары шиңә барды.

Ышыкланып диварларга сакландылар,
Туп-ядрәне бушка гына атмадылар.

Урыс явы Казанны алырга ташлангач,
Гаскәрләре каты һөҗүмен башлагач,

Казанлылар корал тотып сафка басты,
Туптан атып, урысларга нык ут ачты.

Сугыштылар ук-сөңгеләр, мылтык атып,
Дөмбәсләделәр урысны ташлар атып.

Өсләренә кайнар су, сумала койдылар,
Курку хисен гүя бер читкә куйдылар.

Казанлылар җиңүгә бик омтылдылар,
Мәскәүлеләр качарга ук тотындылар.

***

Безнең кыю урыс гаскәре шәһәргә
Унике тапкыр күтәрелде һөҗүмгә.

Көне-төне, ару-талу белми алар,
Кырык көн рәттән шәһәрне утка тоттылар.

Сугышларда сынмаган казанлыларга
Минут тынгы бирмәделәр, хәл алырга.

Осталыкка хәйлә кушып, мәскәүлеләр,
Шәһәр кулга төшсен, дип бик теләделәр.

Тик аларның хыяллары чынга ашмады,
Шәһәр бик нык каршы торды, какшамады.

Урыс явы аптырашта, чара эзли,
Казан диварын ватудан өмет өзми.

БАТЫР КАЗАНЛЫЛАРНЫҢ ҺӘЛАКӘТЕ

Нибары өч мең казанлы исән кала,
Алар бар да бер урынга җыелып ала.

Кочаклашып елашалар, үбешәләр,
Һәм бераздан батырлары киңәшәләр:

Тиз арада без шәһәрдән чыгып китик,
Иркен кырда исәнлеккә өмет итик.

Үлемгәчә урысларга сугыш ачыйк,
Йә булмаса, башны алып, моннан качыйк.

Шунда алар ярсу атларга атланып,
Патша капкасы аша очалар, канатланып.

Казансу аша киң сахрага чыгалар,
Үзләренең көчләренә ышаналар.

Дошман сафын бәреп ташлап,
тиз шылырга,
Нугай Урдасына барып кушылырга.

Кинәт алар ерткычлардай очып чыга,
Урысларның моны күреп, коты чыга.

[21] Дивар – стена.

Мәскәүлеләр куркып-каушап, сафтан чыга,
Гүя аларны искәрмәстән, шөпшә чага.

Хан капкасы тирәсендәге киң җирне,
Каплаган мәскәүлеләр һәр тирә-юньне.

Урыс явы батырларны чорнап ала,
Казанлылар ни булганын күрми кала.

Шунда коточкыч сугыш-суеш башлана,
Һәр казанлыга илле урыс ташлана.

Батырлар ятып кала, Казанны саклап,
Урыс йөри канга баткан кала айкап.

ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕҢ КАНЛЫ КОТЫРЫНУЫ

Канга туймас ерткычлар йөри иснәнеп,
Йортларда, мәчетләрдә канга кинәнеп.

Картмы, яшьме, табылса да берәү генә,
Шунда ук хәнҗәр кадыйлар күкрәгенә.

Яшь хатыннар, йә сылу кызлар котыла,
Йә күчәрдән дә түбән сабыйлар кала.

Бөтен җирдә өелгән мәет таулары,
Елга, чокыр, кое, урман канаулары.

Канлы үлек белән капланган йорт-нигез,
Өелгән гәүдәләр койма белән тигез.

Казансу, Болак буйлары, болынлыклар,
Гәүдә таптап ат чапмый – канлы тояклар.

Атлана урыслар ял иткән атларга,
Тагын тотыналар кан-мәет таптарга.

Урамнарда яшьле кан елгасы ага,
Яңгыр суларыдай – чокырларга таба.

Күл, елга, коелар кызыл – аккан каннан;
Исәннәр җиде көн су эчалмый аннан.

Көн дә таңнан төнгәчә барган бу суеш –
Дөньяда тиңе булмаган вәхши сугыш...



ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕҢ ТАЛАУ-КӨЧЛӘҮЛӘРЕ

Баскыннар, ни теләсәләр – шуны талаган,
Халкы кырылгач – шәһәрдә байлык
күп булган.

Байлык өчен үзара сугышлар башлана:
Көчлерәкләр көчсезләргә эттәй ташлана.

О байлык! Көнчелек! Мал, алтынга табыну,
Җәһәннәм туктаталмас –
бу шундый багыну.

Җитмәгәнме сезгә биргән байлык
Ходайдан,
Кеше талап, ник җыясыз аны яңадан.

Урыслар, Казанны талап, чумды байлыкка:
Җитте ул хатын, бала, туачак оныкка.

Ашап-эчеп, уйнап-көлеп, ачтылар күңел,
Эшләп тапкан мал түгел бит,
һич тә җәл түгел. ■

«Безнең мирас» – дәүләтчелегебез сагында торырга тиеш!

«Мирас» журналы турындагы сүзне Флүн Мусин исеменнән башламасам, һич кенә дә дөрес булмас иде. Ул – журналның беренче мөхәррире, идея авторларының да берсе. Флүн Мусин – асылы белән безнең мирасыбызны барлап баручы, халкыбызга кайтаручы чын шәхес. «Мирас» журналы мәйданга чыккан, аны шулвакытта ук таный башлаганнар икән, бу, әлбәттә, Флүн Мусин исеме белән бәйле.

1990 нчы еллар башында «Мирас» журналы чыга башлау – татар халкының уяну, мөстәкыйль дәүләт төзү, милли азатлык өчен көрәшүенең күркәм бер нәтиҗәсе. Азатлык таләп иткән халык һәрвакытта да тарихка кереп кала. 1990 нчы елларда да азатлык мәйданнары гөрләде, төбәкләрдә милли оешмалар төзелде. Алар мирасыбызны, гореф-гадәтләребезне өйрәнүне, аның тамырына төшенүне максат итеп куйды. Яңа дәүләтчелегебезне төзегән чорда да халкыбыз борынгы дәүләтләребез, ханлыкларыбыз тарихы белән аеруча ныклап кызыксына башлады. Шулар барысы да «Мирас» журналының оешып, аның барлыкка килүенә сәбәп булды.

Хәзерге журнал редакциясе хезмәткәрләре киләчәккә карап гамәл кылырга тиеш. Ә киләчәккә юл тотар өчен, тарихны белү кирәк. Тарих белән бүгенге яшәешебезне чагылдыру, киләчәккә юллар билгеләү – «Безнең мирас» журналының төп максаты.

Без һәрвакыт дәүләтчелегебезне торгызуны максат итеп куйдык, бүгенге көндә дә шушы юнәлештә эш алып барабыз. Хәзер кылына торган эшләребезгә тарих белән ярдәм итү мәслихәт. Хәзерге вакытта да күпләргә дәүләтчелегебезгә хаклы икәнлегебезне исбат итү таләп ителә. Аны гамәлгә ашыру, каршы як тарафны күндерү өчен, тарихыбызны, мирасыбызны пропагандалау төп шарт.

«Безнең мирас» журналы хәзер дә татар дәүләтчелегенең сагында тора. Бүген милли хәрәкәт сүнде, диләр. Юк, бу фикер һич кенә дә дөрес түгел. Милли хәрәкәтнең сүнгәне юк. Ул яңа рәвешкә генә керде. Яңа буын барлыкка килде һәм алар эшне башкачарак рәвештә дәвам итә.

«Безнең мирас» журналы милли күтәрелеш елларының рухын яшь буынга сеңдерергә тиеш. Яңа буын тарихыбыздан өзелергә тиеш түгел. Яшьләр тарихны яңа сулыш, көч белән баетсын! Алар белән халкыбызның, милләтебезнең яшәү көче барлыкка килә. Ә халкыбызның яшәү көче бүгенге көндә ачык күренеп тора. Россиядә татар факторы – иң көчлеләрдән берсе. Күп урыннарда инде рус авыллары юкка чыкты, ә татар авылы, Татарстаныбызда гына түгел, чит төбәкләрдә дә бар. «Безнең мирас» журналы алга таба Шыгырдан, Урта Йөрүзән кебек бай авылларыбызның тарихын да яктыртуны үзенә бурыч итеп куйсын иде. Алар – татар халкының ничек яшәргә тиешлеген күрсәтә торган үрнәк авыллар. Авыл – татарның яшәеше, аның нигезе, гореф-гадәтләре, бай мирасы... Авыл бетсә, татар да бетә. Шуңа күрә, журналыбыз, башка матбугат чаралары да, һичшиксез, авыл проблемасына һәрвакыт игътибарлы булырга тиеш.

Индус ТАҺИРОВ,
КФУ профессоры, тарих фәннәре докторы

Мирас юбилеена

Борынгы заманнардан бирле зур тарихи-мәдәни мирас туплаган мәгърифәтле татар халкы, башка халыклар шикелле үк, үткәненә битараф кала алмый. Тарихи-мәдәни мирасны туплау, аны тирәнтен фәнни өйрәнү һәм пропагандалау соңгы вакытта бигрәк тә актуальләште, чөнки көне-төне байлык артыннан чабу хәтерне зәгыйфьләндерә, ә кеше үз мирасына битараф кына түгел, хәтта онытучан да була. Бу бигрәк тә үткән гасырның 90 нчы елларында Советлар Союзы җимерелеп, яңа Россия дәүләте формалаша башлаганда, капитализм үз тәртибен урнаштырганда сизелә башлады.

25 ел элек «Мирас» журналын оештырып җибәрүне шул еллардагы татар халкының милли-азатлык көрәшенең кайтавазы, татар зыялыларының милли, дини, рухи бәйсезлеккә омтылыш нәтиҗәсе итеп карап булыр иде. Шушы чорда журнал редакциясе халкыбызның бай тарихын, әдәбиятын, мәдәниятен пропагандалау өлкәсендә алыштыргысыз хезмәт куйды һәм ул аны уңышлы дәвам итә. Әлбәттә, 100әр еллык тарихы булган татар журналлары белән чагыштырганда, «Безнең мирас» әле вакыт дәрьясында бер мизгел генә яши. Заманалар, редакторлар, атамасы үзгәрүгә карамастан, исеме җисеменә тугры калган журналда гасырлар дәвамында тупланган тарихи сәхифәләр, сәяси, дини, иҗтимагый хезмәтләр, татар әдәбиятының төрле жанр үрнәкләре, сәнгать әсәрләре киң урын алып килә, чорыбызның мөһим вакыйгалары, әдәбият, мәдәният-сәнгать яңалыклары һәрдаим яктыртылып барыла. Минем өчен дә татар тамгалары белән кызыксынып китү 1992 елда Дамир абый Гарифуллинның «Төрки тамгалар» мәкаләсе белән танышканнан соң булгандыр, дип уйлыйм. «Онытылган мирас» дип аталган тамгалар турында беренче зур мәкаләм 1999 елда «Мирас»та басылып чыккан иде.

Журналның заманча бизәлеше-дизайны да укучы өчен кызык, яңа, моңа кадәр файдаланмаган төрле стильдә эшләнгән гаҗәеп матур, якты, зәвыклы рәсемнәр, фотосурәтләр белән бизәлә.

Басма татар тарихында зур урын алып торган мөхтәрәм шәхесләр арасыннан язучылар, шагыйрьләр һәм җәмәгать эшлеклеләрен искә алырга онытмый, аларның биографияләрендәге әлегә билгеле булмаган фактлар белән таныштырып тора. Мисал итеп, легендар шагыйребез Муса Җәлилнең әлегә басылмаган шигырьләрен генә атар идем.

«Безнең мирас» редакциясе оештырган төрле актуаль проблемаларга багышланган «түгәрәк өстәл»ләр материаллары да укучыларны битараф калдырмый.

Юбилей көннәрендә яраткан журнал коллективына яңа иҗади табышлар, ә укучыга татар тарихи-мәдәни мирасыннан кызыклы яңа сәхифәләр телим.

Фәйзелхак ИСЛАЕВ,
РИИ профессоры, тарих фәннәре докторы

Балтач төбәгендә Тукай эзләре

Гарифҗан Мөхәммәтшин

Миңа үз гомеремдә бик күп татар авылларын күрергә, азмы-күпме аларның гамен күңелем аша кичерергә насыйп булды – туган Татарстаныбызда, күрше Башкортстан, Мари Иле, Удмурт, Чуваш Республикаларында, Оренбург, Әстерхан, Киров, Чиләбе өлкәләрендә, Уралда, Казакъстанда, ерак Төркиядә... Аларның һәрберсе изге бер үҗәтлек, соклангыч тырышлык белән сыкранмый-сынмый халкыбызның иманын, телен, гореф-гадәтләрен саклап-баетып, мул-иркен тормышта күркәм итеп яшәп ята. Милләттәшләремнең рухи күркәмлеге сокландыра – алар тыйнак, алар сабыр, ыгы-зыгыны, зарлану-сыктауны белми, үз язмышының бары тик үз кулында гына булуын, рухи ныклыгыннан битәр, таянычы юклыгын аңлап, төшенкелеккә бирелмичә бер гаилә булып гомер кичерә, балалар үстерә, милләтебезнең киләчәген, яшәешнең мәңгелеген тәэмин итә.

Әмма һәр авылның үзенә генә хас үзенчәлекләре, бер-берсен кабатла-

Сосна Пучинкәсе авылы күренешләре һәм аның мәчете.
Вакыйф Зәкиев фотолары

мый торган бай мирасы бар. Әнә шул артык кычкырып, күзгә бәрелеп тормый торган үзенчәлек-үзгәлекләре белән үзенә тарта да инде күңелне авыл. Бер уйласаң, гади генә авыл, ә аның яшәешендә, тарихында бөтен тулылыгы белән халкыбызның фаҗигале-газаплы, әмма данлы тарихы чагыла. Аны барлый башласаң, еш кына атаклы шәхесләребезнең тормышына бәйле сәхифәләргә, аларның эзләренә юлыгасың. Кызганыч, авылларыбызның күбесенең тарихы җентекләп өйрәнелмәгән шул әле...

«КЫЙЛ ДОГА, ИХЛАС БЕЛӘН ТЕЗЛӘН ДӘ КЫЙБЛА КАРШЫНА...»

Балтач районының Сосна Пүчинкәсе – әнә шундый серле-үзенчәлекле авылларның берсе. Ул әле чагыштырмача яшь авыл – аны 1868 елда районыбызның Сосна авылыннан күченеп килгән Хәбибулла, Мотыйгулла, Ибраһим, Вилдан, Гани, Фәтхулла исемле кешеләр нигезләгән. Сосна – безнең төбәкнең зур һәм борынгы авылларының берсе. Монда инде императрица Анна Иоанновнаның 1740 елның 17 сентябрендә башка диндәге (иноверческие) халыкларны тоташ христианлаштыру турындагы указы кабул ителгән чорда ук өч мәхәллә булган, өч җамигъ мәчете эшләгән. Авыл җәмәгатенең җирләре дә бик киң, еракка – Балтач авылы яныннан Мари Иле чигенә кадәр сузылган. Бирегә әнә шул ерак басуларның хуҗасы булып килгән әлеге игенчеләр. Үз авылларының исемен дә саклап калган алар – Сосна Пүчинкәсе (Починок Сосна) Соснадан күченгән дигән мәгънәне бирә. Аларга тигән җир мәйданы Вятка губернасына караган Малмыж өязенең 1884 елгы статистика мәгълүматларында 366 дисәтинә дип күрсәтелгән. Моннан тыш 18 дисәтинә урманнары, 6 дисәтинә көтүлекләре, болын-печәнлекләре булган. Куе мари урманнарына барып тоташкан урманнарны кисеп, җирләрен тагын да киңәйткәннәр алар – күмәкләшү елларына җирләренең мәйданы инде 450 дисәтинәдән артып киткән. 1884 елда авылда инде 17 хуҗалык булуы, 104 кеше яшәве теркәлгән. Йөгерек агымлы Көшкәт елгасында үзләренең су тегермәннәрен булдырганнар. Егерменче гасырны 33 хуҗалык, 184 кеше булып каршылаганнар. Әмма гасыр башыннан башланган сансыз тетрәнүләр, түнтәрешләр, сугышлар, бәла-казалар авылга зур булып үсеп китәргә мөмкинлек бирмәгән. Шулай да ул татарга хас үҗәтлек, тырышлык белән бүген дә таза-көр тормышта яшәп ята.

Татар кайда гына нигез корса да, иң беренче итеп авылның иң күренекле, иң күркәм урынында гыйбадәт йорты булдырган. Пүчинкәлеләр дә шушы игелекле йолага тугры калганнар – монда инде 1880 елда ук кечкенә мәчет булган. Аның имамы вазифасын **Мөхәммәтшакир Фәйзуллин** башкарган. Киров өлкә архивында саклана торган «1894 елга Малмыж өязендәге мәктәп һәм мәдрәсәләр турындагы ведомость»та авылда биш вакыт намаз мәчете эшләве, гыйбадәтләрне Мөндеш авылының бер крестьяны укытуы теркәлгән. Шулай итеп, без Мөхәммәтшакир хәзрәтнең Мөндеш авылыныкы булуын ачыклыйбыз.

Бу чорларда кечкенә авыллардагы биш вакыт намаз мәчетләре иң якындагы зур авылның җамигъ мәчете мәхәлләсенә кертелгән һәм аның имамы биш вакыт намаз мәчетенең дә баш имамы булып саналган. Әлеге ведомостьта бу вазифаның күршедәге Көшкәтбаш авылы имамы **Әсхәдетдин Ибраһимов**ка йөкләнүе күрсәтелгән. Әсхәдетдин хәзрәт – гаять киң һәм тирән белеме, зыялылыгы белән бил-

геле имам. Ул – үз вакытында шанлы булган, бөтен татар дөньясына мәгълүм имамнар тәрбияләгән Сосна мәдрәсәсенең мөдәррисе, Соснадагы инде биш мәчетнең (өч җамигъ мәчете һәм ике биш вакыт намаз мәчете) берсенең имамы **Таҗетдин бине Габдрәшит бине Мортаза әл-Иштирәки**нең оныгы. Таҗетдин хәзрәт Балтач һәм гомумән Казан арты төбәге өчен гаять зур игелекле эшләре белән мәгълүм. Аның хакында Ризаэддин Фәхреддин үзенең «Асар» исемле бик тә тирән мәгълүматларга бай тарихи язмаларында: *«Таҗетдин хәзрәт бу мәмләкәт галимнәре арасында иң мәшһүрләреннән вә нәсел-нәсәпләре дә гаять таралган һәм күп булган»*, – дип яза. Чыннан да, аның балалары, оныклары, кияүләре Балтач төбәгендә генә дә дистәгә якын авылларда имамлык иткән, олы ихтирам казанган. Сәгъдетдин хәзрәт әнә шуларның берсе. Аның Түнтәр мәдрәсәсендә мәшһүр **Мөхәммәтгали бине Сәйфулла (Гали ишан)** шәкерте булуын искәртү үзе генә дә күпне аңлата.

Бәян ителә торган чорда имамнарның урыс телендә сөйләшә, укыйяза белүе таләп ителгән, шунсыз аларга имамлыкка указ бирелмәгән. Алда телгә алынган «ведомость»та Сосна пүчинкәсе авылында имамлык иткән Мөхәммәтшакир Фәйзуллинның белем-әзерлеге сай булуы, урысча бөтенләй белмәве күрсәтелгән. Авыл өлкәннәре аның табигатенең дә шактый ук кырыс булуын искә ала торган булганнар. Башкача була да алмагандыр. Кечкенә авылда имамлык итү хәзрәткә зур керем бирмәгән, аңа ул чорда болай да җиңел булмаган тормышны үзенең хәләл көче белән, көн-төн казганып алып барырга туры килгән. Шулай да Әсхәдетдин хәзрәт йогынтысында ул авылда шактый тирән игелекле эш алып барган, авыл кешеләре арасында абруй казана. Мәсәлән, 1894 елда аның тәкъдиме белән, авыл җәмәгатьчелеге Вятка губерна идарәсенә (хәзерге Балтач районының иң зур күпчелек авыллары 1780-1920 еллар дәвамында Вятка губернасында булганнар) авылда яңа мәчет төзергә рөхсәт сорап, үтенеч белән мөрәҗәгать иткәннәр. Шулай итеп, 1896 елда кечкенә авыл өчен шактый иркен һәм күркәм мәчет калкып чыга. Ул агач бурадан күтәрелә. Мәчет төзүнең мәшәкатьләрен һәм чыгымнарын үз өстенә авылны нигезләүчеләрнең берсе булган Вилданның улы Кадыйр ала, Кенәрдән бер бай саллы ярдәм күрсәтә (әлеге егетнең каенатасы булса кирәк). 1915 елда инде авыл халкының күпсанлы үтенечләре нәтиҗәсендә мәчеткә җамигъ мәчете статусы бирелә. Әмма Мөхәммәтшакир хәзрәткә инде анда имамлык итәргә насыйп булмый – ул 1916 елда, йөзгә җитәргә өч кенә ел кала вафат була.

Җамигъ мәчетенең имамы итеп 1893 елда туган **Габдрахман Мөхәммәтгарифов** билгеләнә. Ә мәчет исә, районыбызның башка мәчетләре кебек үк, бик күп рәнҗетүләр кичерә. Шунысы куанычлы, аның ахыргы язмышы башка күп авылларның мәчетләренекенә караганда барыбер бәхетлерәк. Дөрес, 1925 елда ул изге хезмәтеннән туктый, 1940 елда манарасы ук киселә. Ватан сугышына кадәр анда авылда оешкан «Уңыш» колхозының балалар бакчасы эшләп ала. 1940 елдан соң төрле елларда башлангыч мәктәп, уку йорты, авылның клубы булып хезмәт итә. Ниһаять, 1963 елда ул сүтелеп, күршедәге Югары Субаш авылында мәктәпкә янкорма итеп корыла. 1991 елда монда мәһабәт урта мәктәп бинасы төзелгәч, авыл халкы мәчетне үзенең хокукый урынына кайтарып, төзекләндереп торгызуга ирешә. Бу эшнең башлап йөрүчесе сугыш һәм хезмәт ветераны **Әхмәтхан ага Гыйльманов** шактый

еллар аның имамы вазифаларын башкарды. Быел төзелүенә 110 ел тулган мәчет халкыбызның иманын ныгытуга бүген дә хезмәт итә.

«БАР КҮҢЕЛЛӘРДӘН ҖЫЛЫ, ЙОМШАК СИНЕҢ КАБЕРЕҢ ТАШЫ...»

Бөек Тукаебызның әнисе Зиннәтулла кызы Бибимәмдүдәгә Казан артының шушы ерак почмагына сыенган кечкенә авылга килен булып төшәргә язган була. Хатыны вафат булгач, Мөхәммәтшакир хәзрәт 1888 елның 22 декабрендә Бибимәмдүдә белән никахлаша. Хәзрәткә инде бу вакытта 69 яшь, Бибимәмдүдәгә исә нибары 23 яшь кенә. Үзенең әле ярты яше дә тулмаган беренче һәм соңгы баласы Габдуллаҗан белән тол калган яшь ана әлеге адымга теләсә-теләмәсә дә барырга мәҗбүр була – әтисе Зиннәтулла йортында үзенең алты баласы белән килгән үги әни, ире йортында аның туганнары хуҗа...

Сосна Пүчинкәсендә кыска гына гомер яшәсә дә, Бибимәмдүдә авыл кешеләре күңелендә якты хатирәләр калдыра. Авылның инде бакыйлыкка күчкән өлкәннәре аның бик тә чибәр булуын, күркәм, моңлы-мәкамле тавышы белән бик тә тәэсирле итеп Корьән аятьләрен укуын, эшкә бик тә җитез-елдам булуын искә ала торган булганнар. Истәлекләрдә аның бик тә пөхтә киенүе, кешеләр белән бик тә ягымлы, итагатьле мөнәсәбәттә булуы телгә алына. Ул өенә җыеп кыз балаларга дәрес биргән, аларны укырга-язарга өйрәтүгә зур игътибар биргән. Аның шигырьләр, бәетләр иҗат итүе телгә алына. Күрәсең, шанлы Кышкар мәдрәсәсендә укып ныклы-нигезле белем алган, ипле холыклы, күркәм әдәпле әтисе Зиннәтулла хәзрәтнең бәрәкәтле йогынтысы зур булган.

Яңа урынга урнашып җитү белән, 1889 елның башында Бибимәмдүдә фәкыйрә вә ялгыз карчык Шәрифәдә калдырган сабый улын үз янына алдыра. Үзенең Сосна Пүчинкәсенә килүен шагыйрь «Исемдә калганнар»ында бик тәэсирле итеп бәян итә: *«Мин бу карчыкта торган мөддәттә анам да теге муллага үзләшеп йиткән булса кирәк: ул бервакыт мине үзе янына Саснага алырга атлар йибәрткән.*

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән дәкыйкаларда миндә, бала булсам да, бер нәүгы шөгур хасил булганмы, нидәндер, мин хәзер дә атка утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганыны онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине кемнәр каршылады – анысын белмим, ләкин үги әтиемнең мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә».

Сосна Пүчинкәсе авылы табигатьнең гаять хозур бер почмагына урнашкан. Авылның сул тарафыннан аны усал җил-давыллардан саклап куе урман-куаклыклар белән капланган шактый гына текә Көшкәт тавы сузылып киткән. Тау иңләп йөгерек сулы, язларын кырыс табигатьле Көшкәт елгасы ага. Тау астыннан саркып чыккан саф сулы дистәгә якын чишмә челтерәп агып ята. Елга яры буйлап тезелеп киткән авыл өйләре балкып тора. Авылның нәкъ уртасыннан көньякка таба басу юлы менеп китә. Авыл бакчалары бетүгә шушы юлның бер ягында мәчет, икенче ягында зират урнашкан. Алар һәр юлчыны фанилык һәм бакыйлык турында уйланырга чакырып каршы ала, озатып кала...

Чирек гасырдан артык инде монда ел саен изге шагыйребезнең әнисен

Халкыбызның танылган әдипләре, сәнгатькярләре, галимнәре – Бибимәмдүдә абыстай кабере янында

яд итү мәрасимнәре үткәрелә. Анда районыбызның һәр авылыннан балалар, яшьләр, өлкәннәр, дин әһелләре, зыялылар җыйнала, күрше районнардан вәкилләр катнаша, халкыбызның танылган әдипләре, сәнгатькярләре, галимнәре килә. Монда изге Ана рухына Корьән аятьләре укыла, кaберенә тере чәчәкләр салына. Тантана хуҗалык үзәге булган Субаш авылы, район үзәге Балтач мәдәният йортларында шигырь бәйрәме буларак дәвам итә, зур бәйрәмгә әверелә. Хәзер инде бу чаралар Республикада Тукайны искә алу көннәре программасына кертелде һәм аны башлап җибәрүче чара булып кабул ителә, төбәгебез халкының, бигрәк тә яшьләрнең, балаларның хәтерен яңарту, иманын ныгыту, телебезне саклау җәһәтеннән бәя биреп бетергесез әһәмияткә ия. Бөтен дөньяга сибелгән татар халкы өчен, гомумтөрки җәмгыять өчен бик тә зарур булган бу чараларның изге Ана истәлеген яңарту белән башлануы – үзе бер символик фал. Шулай булырга тиеш тә бит инде. Ни өчендер, безнең халкыбызда хәтер мәсьәләсе четереклерәк халәттә. Белгәнебезчә, руслар Пушкинны үстергән-тәрбияләгән Арина Родионовнаның истәлеген дәүләт бәйрәме дәрәҗәсендә үткәрәләр. Рәхмәт аларга! Без әле изге Ананың истәлегендә әнә шул дәрәҗәгә күтәрүдән ераграк торабыз шул.

Бәйрәмгә килгән зыялыларыбызның күбесе монда тирән бер моң, уйландыра торган аура барлыгын әйтә. Минем бу фикерне Мөхәммәт ага Мәһдиевтән, Аяз ага Гыйлаҗевтән, Илдар ага Юзеевтан ишеткәнем булды. М.Мәһдиевнең Бибимәмдүдә абыстай кaберенә берничә мәртәбә махсус килүен хәтерлим. Изге шагыйребезнең алда китерелгән истәлекләрен укыганда мин гел ул өч яшьлек сабый күңеле белән әнә шул моңны, әнә шул ауранЫ тойгандыр, дип уйлап, сискәнеп куям – алар сабый күңеленә «әллә нинди нурлар» булып иңгәндер, аның күңелен «киң вә рәхәт галәмгә» алып менгәндер. Шушы яшендә үк бик күп золымнар, гаделсезлекләр кичереп, әнисен бик тә сагынып, инде әнисеннән аерылмаячагына ышанып килә бит ул монда.

Шулай итеп, Сосна Пүчинкәсенә килү белән ананың да, булачак шагыйрьнең дә тормышы көйләнә, сабый күңеленә бик тә зарур булган ана назы кайта. Әмма бу көйле тормыш озакка бармый – Бибимәмдүдә авырып китә һәм 1890 елның 18 гыйнварында вафат була. Аның җәсаден Сосна Пүчинкәсе зиратында җир куенына иңдерәләр. Габдулла өч яшь тә тугыз айлык сабый килеш тома ятим булып кала. Менә шушы сабый хәтере белән ул әнисе белән мәңгелеккә хушлашу мизгелләрен үзәк өзгеч бер моң белән искә ала: «*... мин монда, әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, ялан-баш хәлемдә капка астыннан үкереп җылый-җылый йөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне биреңез!» – дип шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне язамын.*

Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле карьясендәге анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән».

Сөекле шагыйребезнең Сосна Пүчинкәсе авылында узган өч-дүрт яшь арасындагы бер ел сабыйлык гомере әнә шулай уза. Шагыйрь күңелендә гомере буе җуелмас бәхетле һәм хәсрәтле хатирәләр калдыра ул чор. Тукай тормышының Сосна Пүчинкәсе чорын шактый еллар үткәч тә искә ала, алар турында уйлана. «*Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең каберең ташы,/ Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы...*» дип мөрәҗәгать итә ул әнисенә күп еллар узгач. Бибимәмдүдә абыстайның кабере өстенә Г.Тукайның тууына 100 яшь тулган көннәрдә архитектор Р.Билалов проекты буенча эшләнгән мәрмәр таш куелды, кабер төзекләндерелде. Кабер ташы алдына куелган кара гранит ташта шагыйрьнең нәкъ менә шушы үзәк өзгеч моңлы юллары язылган.

Бер гыйбрәтле хәл – Казаннан алып кайтканда кабер ташы, бик җентекләп төрелгән һәм махсус йомшак түшәлмәгә урнаштырылган булуга карамастан, урталай сынган иде. Бу хәл күпләрнең күңелендә Бибимәмдүдә язмышына бер ишарә буларак кабул ителде. Кем белә инде... 2006 елда әлеге таш граниттан эшләнгән яңа ташка алыштырылды. Бу изге эш шагыйрь Разил Вәлиев инициативасы белән башкарылды. Балтачлыларның олы рәхмәте ирешсен үзләренә.

Мин монда еш киләм. Шушы кыйбласыз-имансыз заманның, күп гасырлар яшәп тә үзенең асыл кыйбласын таба алмаган Россия дип аталган иксез-чиксез Ватан түрә-караларының имансыз гамәлләреннән күңелем әрнегән, җаным гасабиланган вакытларда киләм. Изге ананың бәхетсез язмышы турында уйланам, үз баласын үз итмәгән халкы өчен бихисап игелекләр кылып бик тә яшьли бакыйлыкка күчкән бөек шагыйребезнең ачы язмышын күз алдымнан кичерәм. Халкыбызның бүгенге аяныч халәте, аның киләчәк язмышы турында уйланам. Бу дөньяга бөек татар халкының бер баласы булып дөньяга килгән һәр кешенең гомерендә бер генә мәртәбә булса да шушында килүен, әнә шул уйларны күңеленнән кичерүен телим. Бик тә кирәк безгә бүген болар турында уйлану!

РЕДАКЦИЯДӘН: Күренекле шагыйрь, журналыбызның авторы, җәмәгать эшлеклесе **Гарифҗан Садыйк улы МӨХӘММӘТШИНГА** 12 октябрьдә – **75 яшь**! Аны шушы күркәм гомер бәйрәме белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, иҗади уңышлар телибез! ■

«Мирас», №9, 1992 ел

Мирасның ниндие генә юк!

ГОМӘР БӘШИРОВ,
Татарстанның халык язучысы:

Нинди мирас хакында фикер йөртергә? Мәгълүм ки, халыкның яшәү мохите ифрат киң, ул биниһая тармаклардан хасил була. Бабаларыбыздан калган мирас хакында сүз кузгалганда без, беренче нәүбәттә, тарихи мирасны, әдәбият-сәнгать мирасын күздә тотабыз. Хәлбуки, мирас алар белән генә чикләнә алмый. Халык иҗаты, этнография, гореф-гадәт һәм халык тормышындагы башка тармакларның да мирасы бар. Инде тагын да киңрәк фикер йөрткәндә, нигә журналга экология мирасын да үзенең игътибар үзәгенә алмаска икән? Мәсәлән, Кайбыч төбәгендә тарихта үзенең эзен калдырып килүче уникаль имәнлек бар, республикабызда, беркайчан да сука-тырма кермәү сәбәпле, бик борынгыдан ук сакланып калган төрле кыргый үсемлекләр, Иделдә, Чулманда, Агыйделдә генә үрчегән балыклар,



Кайбыч төбәгендә тарихта үзенең эзен калдырып килүче уникаль имәнлек бар, республикабызда, беркайчан да сука-тырма кермәү сәбәпле, бик борынгыдан ук сакланып калган төрле кыргый үсемлекләр, Иделдә, Чулманда, Агыйделдә генә үрчегән балыклар, урманнарда, кырларда күп төрле, безнең зонага гына хас җәнлекләр яшәп килә. Алар һәммәсе дә безгә мирас булып калган, һәммәсе дә бездән игътибар көтә.

урманнарда, кырларда күп төрле, безнең зонага гына хас җәнлекләр яшәп килә. Алар һәммәсе дә безгә мирас булып калган, һәммәсе дә бездән игътибар көтә.

Һәркайсыбызга мәгълүм, татар халкы бик аяныч хәлгә дучар булды. Ул үзенең тарихын белүдән явыз ният белән мәхрүм ителде. Халыкның тарихын бөтенләй яңадан язу мәҗбүрияте алга килеп басты. Бу изге эшкә борынгыдан калган төрле легендалар, җир-су атамалары, өлкәннәр хәтерендә сакланып калган төрле риваятьләр, истәлекләр дә, минемчә, азмы-күпме ярдәм итәр иде. Мәсәлән, минем туган авылым Яңасаланың (Арча районы) урман кырыендагы бер култыгын «яурышкан» дип, бер инкелен «сөрән таяк ташлаган» җир дип атыйлар. Уйлап карасаң, тарихның бик кыйммәтле серләр яшергән җанлы шаһитләре бит болар! Монда лингвистка да, тарихчыга да зур вакыйгаларга алып чыгардай мавыктыргыч материал бар. Бу кайсы заман сүзләре? Монда нинди яу орышкан? Кайчан? «Сөрән» атамасы артына нинди сер яшеренгән? Бәлки бу якларда кайчандыр «сөрән» дип аталучы зур ыруг булгандыр, ул урман буенда барган бер бәрелештә җиңелеп, «таягын» – сугыш күсәген ташлагандыр?

Халкыбызның, бигрәк тә хатын-кызларның рухи ихтыяҗларын гасырлар буена канәгатьләндереп килгән мөнәҗәтләрне дә яңадан «әйләнешкә» кертәсе иде бит! Мин балачакта безнең әниләр һәм әбиләр, апалар һәм җиңгиләр мөнәҗәтләрне күз яшьләрен сөртә-сөртә, әсәрләнеп тыңлыйлар, моңаялар, ул аларның күңелләрен сизгерләндерә, сабыр булырга өнди, тормыш авырлыкларын җиңеп чыгарга куәт бирә иде. Радио һәм телевидение, газета-журналлар юк заманнарда бәетләр, мөнәҗәтләр, китап сүзләре хатын-кызга бердәнбер рухи азык иде. Әгәр дә безнең хатын-кызларыбыз моңарчы әдәпле, гаиләсенә тугрылыклы, күркәм, сабыр холыклы булып танылганнар икән, аларда бу сыйфатларны тәрбияләүгә әнә шундый халык иҗаты әсәрләре дә өлеш кертте булса кирәк.

Бу соңгы җитмеш елда мөнәҗәтләрне «дин сөреме белән агулый» дигән сылтау белән юкка чыгарырга тырышканнар иде бит. Әгәр дә редак-

ция мөнәҗәт әйтә белүчеләр исән чакта алардан ишеткәнне, сүзләре һәм ноталары белән журнал битләрендә бастыра алса, халык моны бик хуплап каршы алыр иде.

Мирасның матбугатта бик сирәк телгә алына торган янә бер тармагы бар. Ул – эпиграфика. Борынгы кабер ташлары тел, орнамент һәм әдәбият элементларын саклап калулары белән тарихны өйрәнүдә зур урын тоталар, һәркайсыбызга мәгълүм, Татарстан җирендә һәм күрше өлкәләрдә Болгар һәм Казан ханлыгы чорыннан калган кабер ташлары шактый күп. Ләкин аларның бик күбесен беркем дә кайгыртмый диярлек. Шул сәбәпле, алар ватылып, югалып, елдан-ел кими баралар. Күреп кайтучыларның әйтүенчә, Мамадыш районындагы Кирмәнчек тә хәрабә хәлгә төшкән, ул тирәдәге «ханнар зираты» дип аталган урынны көтү таптап уза икән. Кычкырып торган наданлык, хәтта кыргыйлык билгесе бит бу! Әтнә районының Бәрәскә авылы зиратындагы «хан кызы күмелгән» дип атап йөрткән урын да, андагы кабер ташы да шундый ук ташландык хәлгә төшкән. Гомумән, һәммәбезне дә оялтырлык аяныч хәл бу.

Әгәр дә «Мирас» журналы бабаларыбыздан калган бу биниһая кадерле һәйкәлләрне игътибар үзәгенә алып, аларны саклау кирәклеген укучыларына бөтен кискенлеге белән төшендерә барса, бик тә изге бер эш башкарылган булыр иде.

Элек безнең халыкта өй эчләрен, мәдрәсә диварларын шәмаилләр белән бизәү, зуррак нәселләрнең шәҗәрәләрен язу да киң таралган күркәм бер гадәт иде. Яңа журнал, бәлки, аларга да үз битләрендә урын табар? ■

«Мирас», №2, 1993

«МИРАС»ка

Равил Әмирхан

Күр, биләүдән яңа төшкән
***«Мирас»**ның гайрәтләрен,*
Каләм гаҗиз тасвирлаудан
Мөштәрәм Хәйрәтләрен.

«Без тарихта әзлебез», – дип
Ачылды сынау саның,
Биш-алты номер чыгуга
Таралды илгә даның.

Борынгы, затлы шәйләргә
Бирелде «яшел ут»лар,
Атмаган икән мирасны
Алтатар түгел, туплар.

Язгы ташкындай халкына
Кайтты бөек Исхакый,
Инде башка фидаиләр
Журнал «ишеген шакый».

Түрдә Мәҗлиси, Фәхреддин,
Сөембикә ханшалар,
Габдулла Буби, Дәүләтшин,
Еникеев Гайсалар.

Дисбегә тезелгән сыман
Мәчетләр, шәмаилләр,
Әтраф, төбәк тарихлары,
Татар яшәгән илләр...

Милләт чыгышы бәхәсе.
Тезмә. Чәчмә. Парчалар.
Болгар чоры, шәһре Казан,
Җукәтаулар, Арчалар.

Ислам нигезләре, иман,
Тыйбб, тарихи сурәтләр,
Мәшһүрләрнең рәсемнәре,
Фатихаи теләкләр.

Без дә синең юбилейга
Иң мөкатдәс теләктә,
Горурлык хисләре дөрли
Ашкынулы йөрәктә.

Инкыйлабка хәтле чыккан
Мәҗәлләләр варисы,
Синдә парлак дәвам итсен
Журналларның тарихы.

***«Аң»**ның зиһенен алга сөр,*
***«Карчыга»** үткенлеген,*
Аңласын татар, ниһаять,
Бу җиһанда кемлеген.

*Юлың **«Ак юл»**дай пакь булсын,*
*Кыюлыкларың **«Туп»**тай,*
***«Гасрел-җәдид»**, **«Уклар»**ында*
Юл сызган сиңа Тукай.

***«Яшен»**дәй яшьнә, **«Ялт-йолт»**тай*
Милләт күгендә балкы,
***«Чүкеч»** кебек, маңкортларның*
Каткан калебен талкы.

*Житез бул син **«Чикерткә»**дәй,*
*Раушанрак **«Миръат»**тан,*
Үң мөштәрәм хатын-кыздан
һәм, әлбәттә, ир-аттан.

***«Икътисад»**ның саллылыгын*
Өлге итү дә важиб,
«Мөгаллим»**, **«Мәктәп»**, **«Мәгариф»
Шулай ук үтә нәҗиб.

***«Тәрбияи...»**, **«Нәҗат»**, **«Ислах»** –*
Зур хезмәт нәтиҗәсе,
*Боларның да **«Мирас»** өчен*
Зарури тәҗрибәсе.

***«Дин вә әдәп»**, **«Мәхкәмәи...»** –*
Шуларның замандашы,
Дини-рухи матбугатның
Тотрыклы нигез ташы.

*«**Мохтарият**», «**Сөембикә**»,*
*«**Азат ханым**», «**Нисван**»нар*
«Мирас»ка юл ярган күркәм,
Күңелгә хуш ризваннар.

*«**Мәгыйшәт**»нең үз эзе бар*
Тарихында басманың,
*«**Балалар дөньясы**» – күрке*
Журналистик язманың.

*«**Шура**» – милли диңгезебез,*
Синең асыл элгәрең,
Шуның үрнәгендә эшләп,
Артсын һаман егәрең.

Ошбу журналлар солтаны –
Юллаучы йолдыз сыман,
«Мирас» – «Шура» варисы, дип
Хак булыр кылсаң гөман.

*Тик «**Атака**» була күрмә*
*һәм «**Сугышчан алласыз**»,*
Шулар калдырды милләтне
Бабичсыз, Акмулласыз.

Мең елдан олуг тарихлы
Халкымның бул тулпары,
Шанлы милләтнең тап төшмәс
Байрагын тот югары.

Гасырлар кичкән мирасны
Белсен милләт өммәте,
Бабайларның һиммәтенә
Артсын даим хөрмәте.

Кавемнең һәрбер симасы
Күрсен синдә шәүләсен,
Милләтеннән йөз чөергән
Укысын ләхәүләсен.

Колач-дәрманың көчәйсен,
Киңәйсен офыкларың.
Аяк терәп даула, әйдә,
Милләтнең хокукларын.

Халкым язма тарихына
Иң булып алтын мирас,
Хак Тәгалә сиңа кылсын
Галәмдә иң зур тираж! ■

Иллюстрацияләр КФУның Н.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе хезмәткәре Рәйсә Шәрәфиева ярдәме белән әзерләнде.

Ишмөхәммәт хаҗи кыйссасы

Гали Гатауллин

1734-1744 елларда Сенатның обер-секретаре И.К.Кириллов тәкъдиме белән, хәзерге Башкортстанның көньяк-көнчыгыш чикләрендә ныгытмалар төзү өчен, Оренбург экспедициясе оештырыла. Әлеге ныгытмалар системасы Урта Азия һәм Казакъстанны Русиягә кушу өчен плацдарм хезмәтен үтәргә тиеш була.

XVIII гасырның икенче яртысыннан башлап, ныгытмалар тирәсендә посад һәм бистәләр барлыкка килә, Оренбург, Троицк, Орск калалары эчке һәм тышкы сәүдә үзәкләренә әверелә башлый. 1738 елның җәеннән Оренбург аша Көнчыгыш илләре белән кәрван сәүдәсе юлга салына. Игенчелекне үстерү максатында Урта Идел буеннан крестьяннарны күчерү, ныгытмалар тирәсенә отставкага чыккан сол-

Ахыры. Башы журналынын 9 нчы санында.

датларны, драгуннарны, казакларны урнаштыру башлана. Элеккеге Ашкадар тоз пристане урынында 1766 елда Стәрлетамак шәһәре төзелә, ә 1787 елда урыс казаклары ныгытмасы нигезендә Чиләбе шәһәре барлыкка килә.

Һиндстан һәм Урта Азия дәүләтләре белән сәүдә итүне тагын да киңәйтү максатында, Екатерина II идарә иткән дәвердә Оренбургтан дүрт чакрым читтә ярминкә йорты төзелә башлый һәм ул 1758 елда тәмамлана. Бик зур мәйданны биләгән, таш кибетләр белән уратып алынган әлеге төзелеш ныгытма рәвешендә була, анда 329 кибет эшләгән. Ел саен, август аеннан октябрьгә кадәр Алмаш (Меновой) ярминкәсенә Һива, Бохара, Һиндстан һәм башка дәүләт сәүдәгәрләренең кәрваннары килгән. Ярминкәнең даны еракларга таралып, товар әйләнеше дә арткач, Алмаш ярминкәсе биләмәсендә таштан мәчет һәм чиркәү төзелә.

1789 елның 17 сентябрендә генерал-губернатор Аким Апухтин Ишмөхәммәт Заитовны Меновой (Алмаш) мәчетенең мөдәррисе итеп тәгаенли һәм мәчет эшчәнлеге өчен кирәкле кешеләрне билгеләүне аңа тапшыра. 1790 елда Ишмөхәммәт хаҗи Каргалы бистәсе мәчетенә мөдәррис итеп күчерелгәч, Меновой мәчете мөдәррисе вазифасын Бөгелмә өязенең Баулы авылында туган Мансур улы Мөслим башкара.

Каргалы бистәсе заманында Оренбург төбәгенең мәшһүр мәгърифәт, мәдәният үзәге булган. Ул 1744 елда Оренбург шәһәреннән унсигез чакрым төньяктарак, Сакмар елгасына Каргалы суы койган урында төзелә башлый. Аны патшабикә рөхсәте белән Казан губернасыннан күчерелгән 200ләп татар гаиләсе нигезли. Оренбургтагы «Меновой двор» һәм якындагы башка ярминкәләрдә тернәкләнеп киткән бистә сәүдәгәрләре Русия белән Урта Азия арасындагы сәүдәне җанландырып җибәрәләр. Заманында танылган шагыйрь, дин һәм җәмәгать эшлеклесе, Каргалы бистәсендә туган Каргалый Әбелмәних Ишмөхәммәт хаҗиның шәкерте була. Соңыннан Әбелмәних үз язмаларында мөгаллимен тирән ихтирам белән искә ала.

Хәрәзмнән Ширнияз улы Ишнияз һәм Багдадтан Хәсән улы Вәлиятдин кебек мөхтәрәм затлар истәлекләрдә Ишмөхәммәт хаҗиның эшчәнлеген югары бәяләп: *«Ул шәкертләргә генә түгел, ә безгә – мөгаллимнәргә дә – остаз булды»*, – дип яза.

1793 елда мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов тәкъдиме белән Ишмөхәммәт хаҗи Оренбургта бай казакъ балалары өчен ачылган мәдрәсәдә шәкертләрне Коръән уку серләренә төшендерә башлый.

Ишмөхәммәтнең якташы, фикердәше Мөхәммәтҗан Хөсәенов Уфа өязенең Солтанай авылында туган. Каргалы авылы, Бохара, Кабул, Оренбург мәдрәсәләрендә югары дини белем ала һәм өстәмә рәвештә Ишмөхәммәт хаҗидан Коръәнне көйләп уку осталыгына өйрәнә.

Мөхәммәтҗан Хөсәенов 1785 елда Оренбург экпедициясенең ахуны булып тора һәм шул ук елны патшабикә фәрманы белән өлкәнең беренче ахуны итеп билгеләнә.

1788 елның 22 сентябрендә Уфада ачылган Диния нәзарәтенә Екатерина II Мөхәммәтҗан Хөсәеновны мөфти итеп тәгаенли.

Мөфти Мөхәммәтҗан Хөсәенов, иң беренче чиратта, казакъ далаларында йогынтысын көчәйтергә теләп, экспедиция оештыра һәм үзе белән ислам дөньясында зур абруй казанган Ишмөхәммәт хаҗины да ала. Алар далада, кышлаудан кышлауга күчеп, старшина, мулла һәм солтаннар белән очрашалар. Мөфти Мөхәммәтҗан

үз вәгазьләрендә ислам дине, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәяхәтләре турында сөйли, хәдисләр бәян итә, ә Ишмөхәммәт хаҗиның Коръәнне яттан матур мәкам белән укуы җыелган кешеләрне әсир итә.

Икенче елны мөфти, үзенә юлдаш итеп Ишмөхәммәт хаҗины да алып, берничә тапкыр башкалага юл тота һәм ел ахырында, ниһаять, алар патша белән очрашалар.

1825 елның 30 сентябрендә Оренбург ахуны Габдессәләм Габдрахимов Оренбург диния нәзарәтенең мөфтие итеп тәгаенләнә.

Габдессәләм Габдрахимов 1765 елда Самара губернасының Бөгелмә өязе Габдрахман авылында туа. Башлангыч белемне туган авылы мәчете каршындагы мәдрәсәдә ала. Соңыннан Казан шәһәрендә Ишмөхәммәт хаҗи хезмәт иткән беренче мәхәллә мәдрәсәсе шәкерте була, Каргалы авылы һәм Оренбург шәһәре мәдрәсәләрендә укый. 1799 елда, Ишмөхәммәт хаҗи тәкъдиме һәм фатихасы белән, Оренбург җамигъ мәчетенең имамы һәм мөдәррисе итеп тәгаенләнә.

Ул чорда остазыңнан фатиха алу зур ышаныч, дәрәҗә саналган һәм андый фатихалы кеше өчен һәр юл да ачык була.

***

Мөэмин-мөселман кеше белемгә өйрәнеп,үзенең белгәнен дин кардәшенә өйрәтсә, шул сәдаканың иң олысы булыр.

Хәдис

Җәяүләп хаҗ сәфәренә чыгып киткән Ишмөхәммәт, күп илләр, җирләр гизеп, егерме биш елдан соң гына туган авылы Күбәкнең туфрагына аяк баса. «*...Бу вакытта яшьләре дә 47 булган икән. Фәкать бу юлы «скрипкачы Ишмөхәммәд» түгел, бәлки галим вә фазыйль Ишмөхәммәд хәзрәт буларак мәйданга чыккан. Байлыгы күп булып, тегермән вә кярханәләр (остаханә, фабрика) салып, күп урман вә җирләргә ия булган*», – дип яза Риза Фәхреддин .

Ишмөхәммәт хаҗи, Фатыйма исемле кызга өйләнеп, гаилә кора. Фатыйманың нәсел-нәсәбәсен ачыклар өчен, янә Риза Фәхреддиннең «Асар» хезмәтеннән өзек китерик: «Ишмөхәммәд бине Тукмөхәммәд (Тәмәк) бине Нияки бине Төнләч бине Сабырхуҗа бине Йәмаш бине Бәраш бине Байтөгәл бине Габдерразак бине Сардак бине Йәмин.

Тукмөхәммәд, Болгар шәһәреннән чыккан биләрдән булып, Дагыстан тарафына барып укыган һәм Тукмөхәммәд хафиз, Тукмөхәммәд шәех дип танылган. Ишмөхәммәд Малмыж өязендә Адай авылында XVII гасыр ахырларында аеруча шөһрәт казанган бер зат, Шәех баба дип танылган.

Уфа вилаятендә Көбәк (Күбәк) авылында имам булган хаҗи Ишмөхәммәд бине Мөхәммәдзаһид каләме белән үзенең «Фәтави Һиндия» нөсхәсенә язганнан бер өзеге, бу урынга мөнәсәбәтле булганга, биредә китерелә: «*Адай авылының Тәмәк Хафиз угылы Шәех баба булып, исеме Ишмөхәммәд. Аның угылы Балтай, Балтай кызы Ниязбикә исемле. Ниязбикә кызы Сәгадәт булып, Сәгадәтнең ике кызы булды. Берсенең исеме Хәдичә вә икенчесенең исеме Хәҗәр. Хәҗәрнең кызы Фатыйма бинте Гомәр булып, әл-хаҗ Мөхәммәд хатыны. Сәгадәт илә Хәсән икесе бертуган вә Ниязбикә бинте Балтай балалары булып, аталары да Габдулла исемле зат иде. Ишмөхәммәд хаҗи бине Мөхәммәдзаһидның «әл-хаҗ Мөхәммәд» дигән кешесе үзедер*».

Әйтергә кирәк, Ишмөхәммәт хаҗи күп кенә язмаларында үз исемен «Мөхәммәд» дип язган.

Фатыйманың затлы нәселе белән тагын да тулырак танышу өчен,

Ишмөхәммәт хаҗи нәселенең дәвамчылары: Миңнеәхмәт (сулдан беренче), хатыны Асия (сулдан өченче); Равил (уртада), хатыны Сания (сулдан беренче). Вәлиәхмәт (уңнан беренче) һәм хатыны Рәзинә (уңнан беренче). Өч бертуган Ишмөхәммәтовларның әниләре Җәмилә (уңнан өченче)

Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» әсәренә дә мөрәҗәгать итеп, бер өзек китерү урынлы булыр: *«Мелла Әбелхәсән Гали бине Исхак бине Габделкәрим бине Балтай бине Ишмөхәммәд бине Тәмәк бине Нияки бине Төнләчи бине Сабирхуҗа бине Ямаш бине Бараш бине Байтәвәккәл бине Габдерразак бине Сардак бине Ямин әл-Каргалый. Оренбургтагы беренче мәчеттә имам булып, соңыннан урыныннан алынып, Казан шәһәренә килеп гомер итә һәм 1259 (1843) елда вафат була. Казанның яңа зиратына җирләнә, җеназасын мелла Сәгыйд бине Хәмид укый. Кыз балаларыннан башка балалары булуы мәгълүм түгел. Казанда Коръәнне чагыштыру белән шөгыльләнә. Халык арасында «Каргалы мәхдүме» дип танылган була. Югарыда китерелгән нәсел-нәсәбен үзе ачыклап төзи. Бу хакта мелла Мөхәммәдшәрифкә язган хатында болай ди: «Нәсел-ыру һәм бабаларыбыз хакындагы мәсьәләне үзебез белүебезчә, хосусан, хөрмәтле атабыздан һәм бабаларыбыздан ишетүебезчә, сезгә белдерәбез. Хәзрәтегезгә сер түгел, атабыз Каргалыда агач мәчеттә байтак еллар имам булып, 1216 (1801) елда, хәмәлнең унсигезенче көнендә вафат. Халык арасында «Көмешче Исхак хәзрәт» дип танылган, мәшһүр остаз. Мәшһүр мелла Габдеррахман хәзрәт, атабыз мәдрәсәсендә торып, гыйлем алып, аның кызына өйләнеп, кияве булды. Мәшһүр мәхдүм хаҗи Хәбибулла, мелла Гатаулла, мелла Хәйрулла әлеге тутабыздан тудылар. Кабере Каргалыда».*

Атабызның әткәсе – мелла Габделкәрим. «Шәехгәрәй хәзрәт» дип танылган. Ул Каргалыга беренче күчеп килгән кешеләрдән. Бохарага барып, «Җәһрия» тарикатындагы ишан Әмлагә янында унсигез көн яшәп, иҗазәт (рөхсәт кәгазе) ала һәм Каргалыга кайта. Анда яраннар тәрбияләгән. Мелла Балтай һәм аның әткәсе Ишмөхәммәд шәех кабере – Адай авылында. Мелла Әбелхәсәннең атасы, Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Болгари тарихына караганда, Тукмөхәммәд булган. Әмма үзебезнең шәҗәрәдә Тәмәк икәнлеге билгеле. Тәмәк Нияки углы – изге Болгардан

чыккан Чыңгыз хан биләреннән. Кошыбыз – күчкән, агачыбыз – карагай.

Әлеге өзектә очраган «би» сүзенең мәгънәсен хәтеребезгә төшерик. Би (бәк, бәй) урысларның кенәз дәрәҗәсенә тиң, ул төрки халыкларда ыруг-кабилә башлыклары, соңрак – эре аксөякләр титулы. Алтын Урда һәм татар ханлыкларында олыс, өлкә идарәчеләре дәрәҗәсе, хан диваны әгъзасы. Би дәрәҗәсенә нәселле аксөякләр – морзалар билгеләнгән.

Фатыйманың туган ягы – Малмыж өязенең Адай авылы 1780-1920 елларда Вятка губернасына, 1780 елга кадәр Казан губернасы биләмәсенә кергән төбәк. Адай авылы бүгенге көндә Татарстанның Кукмара районына карый. Вятка елгасының уң кушылдыгы Бөре буендагы Адай – 1678 елдан ук тарихта билгеле авыл.

1797 елда ахун дәрәҗәсенә лаек булган Ишмөхәммәт хаҗи, кайткач, Күбәк мәчетенең имамы һәм мөдәррисе итеп тәгаенләнә. Иң беренче эше итеп, үз исәбенә мәдрәсә өчен аерым бина төзетә башлый, ә ул әзер булганчы шәкертләрен өендә укыта. Аңардан сабак алырга күрше-тирә авыллардан да киләләр. Ишмөхәммәт мөгаллим дәресләрен яңача алып барган, гади, аңлаешлы итеп аңлаткан, шәкертләр дүрт-биш айда укырга-язарга өйрәнгән.

Коръәнне яттан белгән Ишмөхәммәт хаҗи шәкертләренә Коръәнне дөрес һәм матур итеп көйләп укырга гына түгел, ә аның телен, стилен һәм терминологиясен дә өйрәткән. Ул Коръән-Кәримдә очраган терминнарның (мәсәлән, «хәниф», «бәшәр», «адәм», «бәнү адәм» һ.б.) һәрберсенә дә аерым мәгънә салынганлыгына басым ясый, Коръәндәге һәр сүзне бары тик контекстта гына өйрәнү зарурлыгын аңлата.

1831 елның 23 декабрендә Күбәк авылының җомга мәчете «җамигъ мәчете» итеп үзгәртелгәч тә, аның имамы, мөдәррисе итеп янә ахун Ишмөхәммәт хаҗи сайлана.

Ислам тәгълиматын таратудагы хезмәте, мөселманнар арасында патша хөкүмәтенең сәясәтен үткәрүдәге эшчәнлеге өчен ахун, хаҗи Ишмөхәммәт Заитов югары даирәләрнең Мактау Аттестатларына лаек була, ә 1833 елның 30 октябрендә патша указы нигезендә Көмеш медаль, язулы Анна лентасы белән бүләкләнә. Гомеренең соңгы елларында патша хөкүмәтенең Бронза медаленә лаек була .

Ишмөхәммәт хаҗи авылдашларына, якташларына дини йолаларны дөрес итеп башкаруда да ярдәм итә. Дөньяви мәшәкатьләргә дә вакыт таба тынгысыз җан иясе – Идәш елгасында су тегермәне корып җибәрә. Тегермәнгә килүчеләрдән алынган бер өлеш онны Ишмөхәммәт хаҗи ярлы авылдашларына биреп бара торган була.

Язу-каллиграфиясе ифрат күркәм вә гүзәл булган Ишмөхәммәт хаҗи шәмаил эшли торган остаханә дә ачып җибәрә. Шәмаил – бизәп язылган дога, аять, изге сүз. Ул алтынсу хәрефләр белән яктырып, гарәп язуының сәнгатьчә камиллеге белән балкып, нур чәчеп тора һәм рухи дөньяны чагылдыра. Ишмөхәммәт хаҗи остаханәсендә эшләнгән шәмаилләр сыйфат ягыннан гаять югары була һәм алар мөселман халыклары яшәгән бик күп төбәкләргә – Казан, Уфа, Оренбург, Казакъстан, Урта Азия якларына таралган.

Ишмөхәммәтнең язылган догалары халык авыз иҗатында да чагылыш тапкан. Нәселенең чыгышы белән Күбәк авылыннан булган, ә картлыгында Алан авылында яшәгән Хәбибә Маннурова үзе иҗат иткән мөнәҗәттә:

Юл буенча укып килдем,
Ишмә сызган догасын.

ИШМӨХӘММӘТОВЛАРНЫҢ ШӘҖӘРӘСЕ

Йәмин
↓
Сардак
↓
Габдерразак
↓
Байтөгәл (Байтәвәккәл)
↓
Бәраш
↓
Йәмаш
↓
Сабырхуҗа
↓
Төнләч
↓
Нияки
↓
Тукмөхәммәд (Тәмәк).
Болгардан чыккан Чыңгызхан биләреннән (князь)
↓
Ишмөхәммәт. Шәех баба буларак шөһрәт казанган зат
↓
Балтай
↓
Ниязбикә
↓
Сәгадәт
↓
Хәҗәр
↓
Ире-Гомәр
↓
Фатыйма

Бишмәт
↓
Аяз
↓
Чытырман
↓
Урманчы
↓
Кызылбай
↓
Колаш
↓
Кулыш
↓
Алуш
↓
Әлмөхәммәт
↓
Бикмөхәммәт
↓
Заит
↓
Ишмөхәммәт

Ишмөхәммәт	Фатыйма

↓
Абдулҗәлил
↓
Бикмөхәммәт
↓
Мөхәммәтхәммәт
↓
Шаһгали → Миңнеәхмәт
↓
Вәлиәхмәт
↓
Әхмәт
↙ ↘
Руслан Рөстәм

Миңнеәхмәт
↓
Әнгам
↓
Роберт

Әхмәт Вәлиәхмәт улы Ишмөхәммәтов – үзе төзегән мәчет каршында

Ишмөхәммәт хаҗиның янә бер лаеклы нәсел дәвамчысы – Әнгам Миңнеәхмәт улы Ишмөхәммәтов

Тәкъдиргә шулай язгач,
Ничек аны бозасың, –

дип язган. Мөнәҗәттәге «Ишмә» исеме «Ишмөхәммәт» исеме белән бәйле. Әлеге исемнең халык телендә байтак кына фонетик үзгәрешләргә дучар ителеп: Ишмөхәммәт – Ишми, Ишмә, Ишмүк, Ишмәт формасында кулланылуы гадәти күренеш. Мәсәлән, «Бикмөхәммәт» исеме – Бикмәй, Бикмүш, Бикмәт, Бишмәт дип тә әйтелгән.

Күбәк һәм Таулар авылларын салкын җилдән сакларга теләгәндәй бөгәрләнеп яткан Илбай тавы итәгендә безнең көннәргә «Ахун тугае» исеме белән килеп ирешкән төбәк бар. Табигатьнең матур да һәм бераз серле дә шушы урынына якын гына Уба сырты калкып тора, әрәмәлекләрендә борынгыда тамырланган карлыганнар әле дә татлы җимешләрен бирәләр. Уба үзендә нindидер сер саклыйдыр сыман, чөнки борынгыдан, Уба ата-бабалар җирләнгән изге урын булып исәпләнгән һәм кешеләр анда килеп акбабалары рухына дога кылган.

Бу тарафта «Хөбәйбә тавы» дип аталган төбәк тә бар. Заманында анда җир җиләге, чия, кызыл карлыган мул булган, сәламәтлек өчен файдалы үләннәр дә күп үскән. Күбәктә яшәүче Хөбәйбә әби җәйләрен әлеге тау буйлары, урман-яланнан җиләк-җимеш, сихәтле үлән җыйган. Көн-төн җылы, матур торганда Хөбәйбә әби, авылга кайтып тормыйча, урманда гына куна калган.

Көннәрдән берендә ул югала. Эзли торгач, авылдашлары аның җансыз гәүдәсен әлеге тау башыннан табалар. Шушы хәлдән соң «Хөбәйбә тавы» атамасы халык теленә керә.

Әлеге җирләргә, урманнарга Ишмөхәммәтнең ата-бабалары 1707 елдан ук хуҗа булганнар.

Игътибар итегез: Заитның (Заһитның) өч улы булган: Ишмөхәммәт, Баязит һәм Әлмөхәммәт. Хөбәйбә – Әлмөхәммәтнең өлкән кызы. Баксаң, Хөбәйбә әби бер дә чит-яр җирләрдә җиләк-җимеш җыймаган икән – үз акбабаларының аяк эзләре сакланган газиз җирләрне гизгән ул һәм шунда мәңгелеккә күзен дә йомган.

Ишмөхәммәт хаҗиның нәсел дәвамчысы Хәләфетдин дә әүвәл акбабалары җире булган төбәктән 40 гектар җир ала һәм шунда иген игә башлый. Күбәк һәм Тугай авыллары арасындагы бу урын бүген дә «Хәләф җире»дип атала.

***

Гомерен, гыйлемен Ислам диненә, иленә һәм халкына хезмәт итүгә багышлаган, мөселманнарга Коръән серләрен ачарга булышлык иткән һәм күп шәкертләрнең остазы булган Ишмөхәммәт хаҗи картайган көнендә бик авыр хәлдә кала – Тарлау басуын (Ахун тугаен) өч вотчинник һәм 43 припущенник рөхсәтсез басып ала, урманнары да читләргә китә, малмөлкәте дә тарала.

Гомеренең соңгы еллары ничек кенә авыр булмасын, Ишмөхәммәт хаҗи элеккечә үк ачык һәм йомшак күңелле, һәр сүзеннән гыйлем байлыгы сизелеп торган акыл иясе, абруйлы дин әһеле, остаз булып калган. Үзенең яраткан бәндәсенә Алла, сынар өчен, байлыкны да, авырлыкны да бирер, дип юкка гына әйтмиләр инде.

Инде картайган әтисенең авыр хәлен күреп, белеп торган улы Мөхәммәтлатыйф, яклау, ярдәм сорап, Оренбург-Самара генерал-губернаторына рапорт язарга мәҗбүр була. Әмма югары даирәләрдән, буш сүзләрдән гайре, юньле ярдәм күренми.

***

Татарстанның Әгерҗе районы Кыдырлы авылында әүвәл бертуган Әхмәтшакир белән Шиһабетдин Заитовлар яшәгән. Шиһабетдин җәяүләп хаҗга да барып кайткан. Бертуган Заитовлар, Чучкан авылы янындагы җирләрне сатып алып, Минзәлә өязендәге Югары Саклау авылыннан җирсез берничә гаиләне күчереп утырткан һәм үз акчаларына кызыл кирпечтән, шул чор өчен бик күркәм манаралы мәчет салдырган. Без, кызыл әләмнәр күтәреп, коммунистлар җитәкчелегендә социализмнан коммунизмга «китеп» барган чорда, әлеге мәчет хәрабә хәленә килә: түбәсе дә, түшәме дә, ишек-тәрәзәләре дә юкка чыга аның – бары тик стеналары гына утырып кала. Мәчет кенә түгел, юлсыз, мәктәпсез, кибетсез калгач, Саклау авылы үзе дә тарала – анда җәйләрен бишалты кеше генә кайтып яшәп китәр була.

Әхмәтшакир белән Шиһабетдиннең нәселе дәвамчысы, Казан шәһәрендә яшәгән Шамил Заитов бабаларының ядкәре булган Саклаудагы мәчетне торгызырга алына һәм озак та үтми, яңартылган мәчеттә моңлы азан тавышы яңгырый.

Саклау мәчетенә яңадан «җан өргә» әлеге мөхтәрәм шәхесне беркем дә мәҗбүриләмәгән, ә аны әлеге изге гамәлгә буыннан-буынга күчкән тылсымлы көч этәргәндер дә инде!

Ишмөхәммәт Заитовның туган авылы Күбәк белән иңгә-иң терәшеп торган Таулар авылында заманында дүрт мәчет булган. Илебездә коммунистлар хакимлеге урнашкач, әлеге Аллаһ йортлары халыкка хезмәт итүдән туктатылды, манаралары кисеп төшерелде, биналары хуҗалык ихтыяҗлары өчен кулланыла башлады. 2008 елның апрелендә Таулар авылында да мәчет нигезенә беренче таш салынды һәм ноябрь аена ике манаралы мәшһүр мәчет төзелеп тә бетте. Ике катлы әлеге Аллаһ йортын төзүгә мәхәллә халкы кулларыннан килгәнчә ярдәм итте, «Алга» хуҗалыгы да читтә калмады. Ә төп иганәче, мәчет төзүгә бик теләп алынучы – Ишмөхәммәт хаҗи нәселенең дәвамчысы – Әхмәт Вәлиәхмәт улы (әнисе – Рәзинә Гариф кызы) Ишмөхәммәтов булды. 2015 елның ноябрь аенда мәхәллә халкы Таулар авылы жамигъ мәчетенә «Ишмөхәммәт» исемен бирде. ■

«Мирас», №1, 2005 ел

Себер татарлары тарихы

Марсель Әхмәтҗанов,
Филология фәннәре докторы, академик

Соңгы елларда халкыбыз тарихы турында фәнни хезмәтләр күренгәли башлады. Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Габделбәр Фәйзрахмановның «Фән» нәшриятында рус телендә чыккан «История сибирских татар. С древнейших времен до начала XX века» («Себер татарлары тарихы. Бик борынгы заманнардан алып XX гасыр башына кадәр») исемле зур күләмле монографиясе башка хезмәтләрдән нык аерылып тора. Бу монография Себер татарлары тарихының бик озын чорын – 37 гасырны эченә алып, системалы, комплекслы һәм шактый тулы өйрәнү нигезендә язылган.

Монографиянең әһәмиятен күтәрә торган кайбер проблемаларга тукталып китик. Беренче итеп аның хронологик рамкаларын алыйк. Китапта тасвирланган вакыйгалар бик озын чор – 37 гасыр буйлап бара, алар безнең эрага кадәр XVIII гасырдан башланган, 1917 ел белән тәмам булган. 37 гасырлык татар тарихы кайдан килгән, Себер татарлары шундый борынгы халыкмыни? – дигән сорау туарга мөмкин. Автор Себер татарлары тарихын гомумтатар тарихы һәм гомумтөрки тарихы белән бер чылбырда дип карый һәм шулай яза. Бигрәк тә татар халкы тарихының борынгы чоры безнең ерак бабаларыбыз сөннәр һәм башка борынгы төркиләр тарихына барып тоташа.

Автор язганча, безгә анык билгеле иң борынгы төрки телле халык сөннәр булган. Аларның ватаны Ордос өлкәсендә, ягъни Кытайдагы Хуанхэ елгасының урта агымының төньягында, ә Хуанхэның көньягында кытайлар яшәгән. Борынгы кытайлар бик яхшы елъязмачы булган, елдагы вакыйгаларны язу, аларны ил буенча туплау дәүләт эше итеп саналган. Бер үк вакытта Кытай елъязмачылары үзләренең дошманнары дип саналган сөннәр турында да күп мәгълүмат язып калдырганнар. Кытай елъязмалары безнең эрага кадәр XVIII гасырдан башлап сөннәр турында шактый күп мәгълүмат бирә. Г.Фәйзрахманов, Кытай чыганакларына таянып, сөннәр тарихын б.э.к. XVIII гасырдан башлый. Безнең эрага кадәр IV гасырда сөннәр үзләренең гаять зур дәүләтен – Бөек Сөн каганлыгын төзи. Сөннәр безнең эрага кадәр 55 елда, безнең эраның 93 елында һәм 155 елында Бараба даласына, аннан Тубыл буйларына килеп чыга, бер өлеше, шунда утырып калып, безнең эрага кадәр Көнбатыш Себердә яшәгән төрки кабиләләр белән кушылып, Себер татарлары бабаларының этник нигезен сала.

Күчем хан

Безнең эрага кадәр Көнбатыш Себердә нинди төрки кабиләләр яшәгән? Монографиядә бу ачык яктыртыла. Мең ел буена – безнең эрага кадәр V-IV гасырлардан башлап безнең эраның IV-V гасырларына кадәр Тубыл буйларында саргат мәдәнияте хакимлек итә.

Көнбатыш Себергә Барабадан көньяктарак яшәгән төрки телле динлиннар, гяньгуньнар (борынгы кыргызлар) үтеп керә. 552 елда Бөек төрек каганлыгы төзелгәч, биреге төркиләр килә. IX-XI гасырларда Көньяк Себердә һәм Казахстанда яшәгән Кимәк каганлыгы чорында Себер татарларының бабалары арасына кимәкләр һәм кыпчаклар үтеп керә, төрки телле башка кабиләләр дә бу җирләрне читләтеп үтми.

Габделбәр Фәйзрахманов бу вакыйгаларны борынгы кытай, фарсы, гарәп, төрек, Византия язма чыганакларына таянып тасвирлый, авторның бу чыганаклар өстендә тәнкыйди эшләгәне күренеп тора.

Шулай итеп, Себер татарларының этногенезы дәүләтләре төзелгәнче үк бик озын гомерле һәм катлаулы булган. Дәүләт төзелгәч тә, Себер татарларының этногенезы дәвам иткән, чөнки бирегә көньяктан төрек кабиләләре, көнбатыштан болгарлар, соңрак Идел-Урал татарлары килеп торган.

Кайбер тарихи хезмәтләрдә Идел-Урал татарларының этногенезы турында язганда, бик трафарет юл сизелә: «Без ике халыктан – болгар һәм кыпчактан туган халык». Әйтерсең Идел буена болгарлар килгәнче илләреннән сөн булып чыгып, юлда башка кабиләләр белән кушылып, һунга әверелгән, ләкин төрки нигезен саклаган халык килмәгән, монда Көньяк Себердән, Җидесудан, Урта Азиядән, Казахстаннан көнчыгышка юнәлгән күчмә тормыш алып баручы огузлар, бөҗәнәкләр, торклар яшәү өчен Тубыл, Иртеш буйларыннан уңайрак булган Урта Идел – Түбән Кама буйларын күрмәгәнмени? Болгарлар Урта Иделгә төрки кабиләләр кайнап торган чорда килеп, аларны берләштереп, дәүләт төзегәннәр. Күрәсең, тегеләре дә, болары да иҗтимагый үсеш ягыннан дәүләт төзү стадиясендә булганнар. Юкка гына Идел Болгарстаны күп кабиләле булмаган.

Г.Фәйзрахманов күп чыганакларга таянып, аларга тәнкыйди карап тикшергән икенче бер проблема – Көнбатыш Себердә татар дәүләтчелеге проблемасы. Бу – Себер татарлары тарихында шактый буталган мәсьәлә. Кайбер тарихчылар Себер татар дәүләтен Алтын Урдадан килеп төзегәннәр дип тә язды. Себер татар дәүләтен «Алтын

Урда кыйпылчыгы» дип караучылар да булды. Билгеле булганча, дәүләт төзелү – ул теге яки бу халыкның иҗтимагый үсеш нәтиҗәсе. Автор, төрле чыганакларны өйрәнү нәтиҗәсендә, мондый фикергә килә: Себер татарлары бабаларының беренче дәүләте, аларның иҗтимагый үсеш нәтиҗәсе буларак, XII гасырда Ишим елгасы буенда төзелгән, хан идарәсе Кызыл Тура шәһәрендә урнашкан була. Г.Фәйзрахманов шартлы рәвештә бу дәүләтне Ишим ханлыгы дип атый һәм аның 14 ханының исемен китерә. Шунысы бик игътибарга лаек: автор файдаланган чыганаклар татар халкы арасында сакланган, «Мирас» журналының 2002 елгы 8 санында басылган «Илдан белән Гөлдан» дастанына авазлаш. Бу хәл монографиянең чыганаклар базасы ышанычлы булуны күрсәтә. Себер татарларының икенче дәүләте – Ишим ханлыгының дәвамы булган Төмән ханлыгы XIII гасырның 20 елларында төзелә. «Себер елъязмалары »на таянып, Г.Ф.Миллер да Төмән ханлыгының тарихын шул еллардан башлый, «Илдан белән Гөлдан» дастанында да бу дәүләтнең башлануы монгол яулары вакытында дип күрсәтелә. Әлбәттә, монография авторы Ишим һәм Төмән ханлыкларының төзелү вакытын дастан нигезендә алмый, монда файдаланылган чыганакларның дастанга авазлаш булуына басым ясала. Ә бу фактор чыганакларның әһәмиятен күтәрә.

Төмән ханлыгы, Ибак (Ибраһим) хан вакытында көчәеп, халыкара аренага чыга, Нугай Урдасы, Казан ханлыгы, Бөек Мәскәү кенәзлеге белән дипломатик мөнәсәбәтләргә керә. Монографиядә автор Казан ханлыгына Мәскәү агрессиясе көчәеп, Казандагы көнчыгыш партиясе лидерларына куркыныч туганда, Төмән ханы Ибакның аларны үз канаты астына алып, Төмән ханлыгының башкаласы Чимги Турада саклап калуын ныклы документаль нигездә күрсәтә.

Себер татарларының соңгы дәүләте – Себер ханлыгы 1495 елда төзелүне чыганаклар раслый. Бу дәүләт Күчем хан вакытында зурая, көчәеп тә китә. Ләкин бу чорда Мәскәү дәүләте Себер татар дәүләтенә XV гасырда ук башлаган агрессиясен тагын да көчәйтә. Казанны басып алу аңа Себергә юл ача. Себер ханлыгын яулап алу өчен, Мәскәү Казанны яулап алу стратегиясен куллана, ләкин зуррак масштабларда. Әгәр Казанны алу өчен Мөдһиш Иван Зөя шәһәрен төзеп, анда хәрби-икътисади база булдырган булса, Себер ханлыгын басып алу нияте белән промышленник Строгановларга бер дәүләт җире кадәр биләмәләр биреп, анда шәһәрләр, кальгалар төзетә, анда утлы кораллар, азык тупларга әмер бирә. Строгановлар биләмәләре гаять зур хәрби-икътисади база була. Ермак казаклары анда торып Себер ханлыгын басып алырга әзерләнә. Себергә разведка ясый, кораблар төзи, кораллана, азык туплый. 1582 елда Ермак бандасы утлы корал ярдәмендә Себер ханлыгы башкаласы Искерне басып ала. Күчем кача. Ләкин ул, 17 ел буена сугышып, рус баскынчыларына бирелми. Күчемнең уллары һәм оныклары рус колонизаторларына каршы 70 ел буена сугыша.

Бу вакыйгалар автор тарафыннан документларга нигезләнеп тасвирлана. Автор күтәргән әһәмиятле проблемаларның тагын берсе – дәүләтләрен югалтканнан соң Себер татарларының аяныч хәле. Г.Фәйзрахманов басып алу сугышларында халыкның 90% ы һәлак булуны раслаучы чыганакларны күрсәтә. Исән калганнарының да беразы тынычрак урыннарга күчеп китәргә мәҗбүр була, күпләренең җирләре тартып алына, аларга авыр ясак салына. Рус дәүләте, православие чиркәве белән бергәләп, татарларны һәм Себернең башка халыкларын көчләп чукындыру эшен башлый.

Монографиядә Себер татар дәүләтләрендә һәм, дәүләт җимерелгәч, Рус дәүләте составында Себер татарларының хуҗалыгы, икътисади һәм рухи тормышы, алар язмышында 1394-1395 елларда кабул иткән Ислам диненең роле ачык тасвирлана. («...») ■

«Мирас», №7-8, 1995 ел

ХӨРМӘТЛЕ «МИРАС»ЧЫЛАР!

Бу хатны Сезгә Татарстанның Сарман районы Дими Тарлау авылыннан Әнәс Ганиев яза. Мин «Мирас» журналын чыга башлаганнан бирле алдырам һәм җентекләп укып барам. Журналга карата үземдәге фикерләр белән дә уртаклашасы килә. Әлбәттә, ошаган яклары бар, ошамаганнары да күренә. Ошаганнарның берсе – бизәлеше нәфис, әмма эчендәге сурәтләр кабатлану белән килешәсе килми. Аннан соң – гарәп хәрефле аңлашылмаган шәмаилләр дә күренә. Язуга аңлатма да бирелсә иде (мәс. Арслан сурәте). Галимнәребез дә берсен-берсе кабатлый кебек: Болгар чоры да, Алтын Урда чоры. Аннан элгәре безнең бабайлар кайларда яшәгәннәр, кемнәр булган алар? Алар турында бер мәгълүмат та юкмы? Никтер Нурихан Фәттах ага эндәшми, Әбрар ага Кәримуллинда да әлеге өлкәдә мәгълүматлар бар иде кебек. Бу урында галимнәребезгә бер үтенечемне дә язасым килә. Татар халкының шәҗәрәсен төзеп булмас иде микән? Кайчан, кайда яшәүләренә, вакытларына, нинди кабиләләр булуларына кадәр күрсәтеп. Тагын бер үтенечем дә бар иде: мөмкин булса, Шиһабетдин Мәрҗани хәзрәтләренең «Вафият...»е һәм мөфти Ризаэддин Фәхреддин хәзрәтләренең «Асар»ен безгә җиткерә алсагыз, нинди дә шәп булыр иде! Журналда рун хәрефләре белән язылган язуларны да укып күрсәтсәгез иде. Андый материаллар музейларда байтак туплангандыр дип уйлыйм.

Әнәс Ганиев,
Сарман районы, Дими Тарлау авылы.

«Мирас», №11-12, 1995 ел

МӨХТӘРӘМ РЕДАКЦИЯ!

Минем уй-фикерләрем сезнең тарафтан аңлау табар, дип ышанам. Һичсүзсез, журналыгыз олы игътибарга лаек!

Аяныч ки, милли тәкъдирләрне хәл итәрлек Мәгълүмат Үзәге юк шул. Әлегә без – колония һәм халкыбызның күпгасырлык тарихи-мәдәни һәм әхлакый-рухи мирасына йөз белән борылмыйбыз, яки бу милли дәүләтчелегебезне тергезү процесслары бердәй хәл ителү юлы белән чишелеш тапмый икән, – безне, бай рухи цивилизациягә ия булган милләт буларак, милли хасиятләребезне югалту, яраклашу «чире» һәм тулысынча тарихта эзсез югалу көтә. Ә Русия хөкүмәте, тарсынмыйча, үзенең иярченнәренә ачыктан-ачык матди ярдәм, тәҗрибәле инструктаж бирә. Бу чаралар исә милләтнең тотрыклылыгын, бердәмлеген какшатуга юнәлдерелгән. Икенче төрле итеп әйткәндә, мондый мәкерле һәм дәһшәтле империянең сәясәте мөстәкыйльлеккә, азатлыкка омтылган милләтләрне авызлыклау түгелме соң? Әйе, нәкъ шулай. Үз вакытында дәүләтчелекләрен югалткан Себер, Әстерхан, Кырым, Казан татарлары шундыйлардан. Ә Оренбургта, милли үзаңны томалау нияте белән, төрле брошюралар һәм газеталар күпләп басыла. Болар исә татарларга һәм милләтнең төрки гаиләлегенә каршы юнәлдерелгән.

Милләткә ялган кыйммәтләрне көчләп тагу аны тагын да рухи таркалуга, коллыкка этәрә. Үзебезнең милли хасиятләребезне читкә куеп, икенче милләт кыйммәтләре өчен көрәшергә мәҗбүр булабыз. Уйланыгыз бу хакта!

Мирхан Нәҗметдин,
Ташкент шәһәре, Татар җәмгыяте әгъзасы. ■

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни (Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Харамга катылма, үзеңне тот нык,
Харам ашаучыга – иң тирән тәмуг.

Рәхим-шәфкатьле бул һәрбер терегә,
Зыян-зарәт кылма, азып йөремә.

Хәмер эчмә, фәсәт кылма, күр аны:
Шулар боза гаскәр, кирмән, тураны[1].

Үлемгә дучардыр тумыш һәр инсан,
Ләкин атың калыр, чын кеше булсаң.

Яшәвең бер тотам, бер дулкын-ялкын,
Яманмы-яхшымы калыр тик атың.

Бу дөнья – бер тиле юата, әвертә сине,
Гафил булма, килер кыямәт көне.

Гафиллек кешене тәмам оетыр
Һәм ул иң кирәген хәтта, онытыр.

Әгәр кешедә булмаса шул гафләт,
Фәрештәдәй кылыр иде гыйбадәт.

Ни шәп әйтелгән бер белекле сүзе
(Аны тыңла һәм от, и күңле изге):

«Сөенеч һәм назлар илтә гафләткә,
Шуңа кеше рухан йоклый, гаҗәп тә.

Гафиллек йокысы басмасын иде,
Я Рабби, калдырма шундый халәттә».

Җете булсын күзең, уяу – колагың,
Халыкка ирешсен изге теләгең.

Ходай халык хаккын сорар нәкъ синнән –
Аның күз-колагы бар ич һәр җирдә.

Бак та күр, нәрсә ди фикерле кеше,
(Аның сүзен тотсаң, эшләнер эшең):

«И, баштак, мактанчык, адәм яманы!
Әзерлә Ходайга җавапнамәне.

И, күңел ачучан, әдәп-хаясыз,
Бар Ходай каршына барып басасың.

И, гамьсез яшәүче ашап та эчеп,
Хисап көне җитсә, котылырсың ничек?

Җавапка тартачак Тәңре барчасын,
Котылыр җирең ни, кая качасың?»

И, илбик, кулыңда кылыч һәм гөрзи,
Кемгәдер тияр ич алар беркөнне.

Алар, яманнардан гайри, беркемгә
Тимәсеннәр иде, шулай хөкемлә!

Яман илбик илне, дөньяны бозар,
Тыючы булмаса, юлыннан язар.

Хөрмәтлә яхшыны, күтәр изгене –
Барча халык яхшы булыр, илбигем.

**Яман илбик илне, дөньяны бозар,
Тыючы булмаса, юлыннан язар.**

---

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынан басылып килә.

[1] Тура – иң кечкенә ныгытма, форт. Әйтмәкче, шахмат фигурасы – тура сүзе шул сүздән килә һәм бу сүзне руслар элек куллансалар да, русча булган дип, ладья сүзенә алмаштырганнар. Хәлбуки, тура – турага охшаш, ладьяга түгел!

Уенга мавыкма һәм тыел үзең,
Ләззәткә бирелмә – аз калды көнең.

Тугрылык белән син идарә итсәң,
Дәүләтең яшәр гел имин вә исән.

Көчең җиткән кадәр тырыш һәм шунда
Гафу сора илдән һәр ялгышыңда.

Ни ди, әнә, ишет, илдә иләмән[2]
(Гаделлеге белән илләр биләгән):

«И, бий, тәкатьле бул хөкем эшендә,
Гаделлегең җитсен барча кешегә.

Әгәр ялгышсаң син, һичбер кайчан да
Гафу үтенүдән качма, тайчанма.

Казнаны күп җыйма алтын-көмештән,
Яхшы булыр бүлсәң гадел өлештән.

Чөнки үлеп китсәң, калыр файдасыз,
Әрәм-шәрәм итәр исәр угыл-кыз.

Тырыш, тик файдасыз яткырма малны,
Үзеңнән кызганма – куллан син аны».

Ни яхшы әйткән бер халыклар бийе,
Халыкта абруйлы инсан бөеге.

«И, казна җыючы дөньячыл бәкләр!
Үзеңнән соң казна калса, кирәкмәс.

Байлык-көрлек синнән хисабын ала,
И, асылзат, баргач, теге дөньяга».

И, илдә хөрмәтле асылзат кеше!
Сарыф ит байлыкны ахирәт өчен.

Вафасыннан җәфа күбрәк дөньяга
Артык ышанма син, күңел баглама!

Айә, бий халыктан барасың алдан.
Бийлекне ахирәт өчен файдалан.

**Тугрылык белән син идарә итсәң,
Дәүләтең яшәр гел имин вә исән.**

Озак яшәсәң, и, хирыслы бәндә,
Картайгач, байлыкны тапшыр яшьләргә.

Үлем тоткач, малның файдасы юктыр,
Торып калган малың кызыксыз йөктер.

Аз ашап, и, илбик, бул гыйбадәттә,
Аз сөйлә һәм өйрән олпат гадәткә.

Гарип, тол, ятимнәр хәлен белеп тор,
Ил күзендә шулай гадел булып тор.

Ялагай кешене якынлаштырма,
Түбән бәндәләрдән саклан, юл куйма.

Афәт андый затлар бүтән инсанга,
Ошакчы[3] кешеләр – сиңа дошманнар.

[2] Иләмән – иҗтимагый эшмәкәр, адвокат, килештереп йөрүче.
[3] Ошакчы – берәүне яманлап әләкләшүче.

**Дөньяның туклыгы – ачлык кырында.
Шатлыгың ачкычы кайгы кулында.**

Кеше комсыз икән, аңар кул бирмә,
Бозгынлык кертәчәк ул төзген илгә.

Тырышып үзеңне тәмугтан коткар,
Һаман изгелек кыл – Алла ярлыкар.

Бүгенге көннән соң һәрбер көнең дә
Изге генә булсын – монда, тегендә.

Белекле бер кеше әйткән ич: – Һәрбер
Эшең Тәңре өчен мәгълүм – теркәлер.

Диннең юнәлеше дөньяга чатмаш,
Аларның юллары һич тә очрашмас.

Берегәлми һич тә дөнья белән дин,
Моны инде, туган, белеп куй алдын.

Бусы якынласа, тегесе кача,
Юлдан язмыйм, дисәң, тор син уртача.

Дөньяң-гомереңне өермәгә санасаң:
Шаулап килде, үтте-китте, карасаң.

Килер кот, капкаңа бүләк китерер,
Өметләнгәнеңне бүтәнгә бирер.

«Баедым», димә син – бөлерсең тиздән,
«Мин алмазмын», димә – чүп син гүреңдә.

Дөньяның туклыгы – ачлык кырында.
Шатлыгың ачкычы кайгы кулында.

Нәфестән дә яман явыз дошман юк:
Аз гына юл бирсәң – кылыр дошманлык.

Вафа кылсаң аңа, ул кылыр җәфа,
Җәфа кылсаң таман, бап булыр аңа.

Нәфеслегең бастыр – тыныч калыр җан,
Белемең бий булыр, акыл булыр хан.

Дөнья дәрте – дошман, нәфесең – дошман,
Ике яктан сиңа тозак корылган.
Уңышка куанып, купмасын күңлең,
Ышанма дөньяга – аңардан түгел ул.

Олуглык, бөеклек – алар үрт[4] кебек:
Ялкынланыр, сүнәр һәм калыр көллек.

Ни ди, ишет, берәү – асылда бөек
(Миһербанлы кеше сүзен тот берук):

«Бу билегең белән борын чөермә,
Хөкемеңдә таудай күкрәк киермә.
Түбән дәртләрне[5] чүплеккә ыргыт,
Болай да Тәңре күп нигъмәтләр биргән».

Өч урынга, илбик, бик сайлап кына
Кешеңне куй сынап, абайлап кына:

Берсе – казый. Сайла шуны – күңле саф,
Уйчан һәм халыкчан бер кеше булса.

Икенчесе, шиксез, тәхет варисың,
Халык аннан фетнә күтәп тормасын.

Өченчесе бик тә җаваплы вәзир –
Халыкның язмышын кулда тоткан ир.

Бу өч тугрылыклы, эшчән булганда
Халык ышанычлы, котлы кулларда.

Халык байый, илбик абруйлы була,
Арта гына сиңа кылынган дога.

Бу өч кеше эшли алмаса эшен,
Авыр хәлдә калыр, болганыр ил-көн.

Моңа охшап бер сүз телемә килде,
И, күрекле йөзем, син тыңла инде.

«Вәзир генә бийнең юлын тотучы,
Илен, сәраен гөл кебек итүче,
Вәзир дилбегәне тота белмәсә
Бар эш харап, димен, мин – кисәтүче».

---

[4] Үрт – кырда-яланда, бигрәк тә торфлы сазлыкта сүндерергә кыен булган янгын.
[5] Түбән дәртләр – эчкечелек, хатыннар белән артык буталу һ.б.

Бу дөнья гүя бер җәюле табын,
Килер бәндә, ашар читеннән аның.

Бездән элек килеп киткән токымнар
Туган, үскән, яшәп, шунда тук булган.

Олы туйны уйла – көтеп яталар,
Чакыралар һәм без тиеш атларга.

Нәүбәттәге токым – безнең карында,
Алар дәстерханга[6] килеп калырлар.

Ашыйбыз, эчәбез, киемебез бар,
Ходай бирер, ләкин, кайчанга кадәр.

Тегендәгеләр «кил, кил», дип көтәләр,
Карындагылар «тор, тор», дип әйтәләр.

Берсе куа, берсе дәшә янына,
Рәхәтлек дөньяда булса аз гына.

Гафил булма бий, тик, уйлама озак,
Озакка калмабыз, булсын тик йөз ак.

Харамга катылма, и, илбик, саклан,
Харам каралтыр ул йөзне һәрьяктан.

Хәвефсез булыймчы, дисәң, и, данлым,
Хәләл аша, алсаң, хәләлдән алгын.

Ни ди, ишет, хәләл ашаган бер ир
(Харамнан саклана белгән кешедер):

«Хәләл аша – Алла рәхим әйләсен,
Бүген хәләл аша һәм иртәгәсен».

Кемнең гөнаһсыз, пакь булса тамагы,
Җиңелрәк җуелыр барча гөнаһы.

Рухи пакьлек өчен ашау пакь булсын,
Ашау пакь булса, күп файда табырсың.

Үз файдаңны түгел, илнекен эзлә,
Синең файдаң илгә файда эчендә.

**Ил башы гүяки кояшка охшаш:
Асылда дөньяны ашата кояш.**

Ни ди әнә, олуг шәһәр башлыгы,
(Һәрнәрсәгә аның җиткән акылы):

Бий – кот кошы, эше – илне котайту,
Халыкның тамагын, димәк, тугайту.
Төпләре энҗеле диңгезләр – бийләр,
Диңгезгә килгәннәр табыр энҗеләр.

Алтынлы, мәгьдәнле тавар бий кеше,
Аңа килгән булыр алтын-көмешле.

Кылсын илгә файда, мул куллы булсын,
Илен туйдырырлык акыллы булсын.

Ил башы гүяки кояшка охшаш:
Асылда дөньяны ашата кояш.

Билек ул – Ходайдән әмәнәт сиңа,
Асылда, бер йөк ул бийнең муйнына.

И, илбик, хәлеңне инде күрәсең,
Үзеңә күп байлык җыю кирәген.

Диңгездә булган бар энҗе-гәүһәрләр
Көтә сине, җыйыйм, дисәң, әгәр дә,

Кара, җирдә күпме алтын-көмешләр,
Барсын хәзинәмә җыйыйм, дип эшлә.

Бу таулар эчендә яткан гәүһәрне
Алып бетерү читен – ул шулкадәрле.

Кара җиргә чәчсәң, уңар игеннәр,
Урып тутырырсың амбар, әвенгә.

Очар кошлар, суда балык муллыгы,
Ауласаң, котылмас, и, җитез кулым.

Галәм гизсен синең кәрван – аргышың,
Ефәк, кеш һәм тиен[7] җыеп алырсың.

Дәвамы бар ■

---

[6] Дәстерхан – «үзенә ашамлык тезеп куелган ашъяулык».
[7] Оригиналда тиник, тэник – билгесез бер мехлы хайван, без тиен дип шартлы мәгънәдә яздык.

ЧЫҢГЫЗХАННЫҢ АК БОЛЫТЫ

Романга бәян

Чыңгыз Айтматов
(1928-2008)



* * *

«Бөек Азия киңлекләреннән Кояш баешы илләрен яуларга халкынчирүен иyртеп яу белән барганда, Чыңгызхан Сарүзәк далаларында бер җәзалап үтерү мәрәкәсе китереп чыгарды – сугышчыйөзбашын һәм тантаналы ефәк һораң-байракларның киң иннәрен авызларыннан ут-ялкын ургытып торучы аждаһалар белән бизәп, укалап чигүче яшь хатынны астырды.

Ул вакытка Азиянең зур өлеше Чыңгызхан үкчәсе астында калган, аның малайлары, оныклары һәм сәргаскәрләр (чирү башлыклары) арасында олысларга бүлгәләнеп беткән, хәзер инде нәүбәттә Идел аръягындагы төбәкләр язмышы, тулаем Аурупа язмышы тора...

Сарүзәк далаларына көз сулышы кагылган чак. Җәй дәвамында артык кипшенеп киткән күлләр һәм елгалар тоташ яуган яңгырлардан соң кабат үз хәленә кайта – инде атларны ничек сугару турында кайгырасы юк дигән сүз. Шулай да даланы иңләп-буйлап килгән чирү адымын тизләтте. Сарүзәк җирләре аша кичү юлның бигрәк тә авыр өлеше санала иде.

Өч чирү – унар мең сугышчыдан торган өч төмән – канатларын киң җәеп, алдан ерып, Идел тарафына таба бара. Төмәннәрнең куәте турында аларның адымы – ат тояклары астыннан күтәрелеп, дала янгыныннан соң дөньяны каплаган төтен сыман, офыктан офыкка эленеп торган тузан буенча фикер йөртеп була иде. Янә кирәге чыкса дип алынган алмаш атлары, олау-йөкләре һәм һәркөнне ашка суяр өчен кысыр мал көтүләре белән ике төмән арттан килә, – моңа ышану өчен бер каерылып карау да җитә, – анда шулай ук ярты күкне каплап тузан өермәсе уйный. Әлеерактарак булганга гына күренеп тормый торган бүтән сугышчан көчләр бар. Аларга – һәркайсында өчәр төмән булган сул («суңавыл») һәм уң («баравыл») канатларга барып җитәр өчен генә дә атка атланып берничә көн юртырга кирәк... Суыклар башланганчы, Идел ярына басып, хан тирмәсендә барлык унбер төмәннең дә сәргаскәренә алга таба хәрәкәт итүне килештерү һәм Чыңгызхан үзенә буйсындырырга хыялланган, аның яубашларының гына түгел, һәр җайдагының татлы хыялы булган бай вә шанлы илләргә таба Идел бозы аша кичүгә керешүнең тәртибен билгеләү күздә тотыла иде.

Яу сәфәрендәге чирүләр шулай, як-якка карамыйча, тоткарланмыйча, вакытны югалтмыйча алга барды да барды. Хатын-кызлары да олаулары белән аларга тагылган иде һәм бөтен бәла дә шулардан килеп чыкты.

Чыңгызхан үзе, озата баручы ярты меңләп кизүвыллары (кизүдә торган сакчылары) һәм яраннары – ясавыллары (ярдәмчеләре) белән, йөзмә утрау шикелле, әлеге хәрәкәтнең уртасында чайкала иде. Әмма ул алардан аерылыбрак – алданрак бара. Дөньяның Дүрт Тарафы Әмире, бигрәк тә яу сәфәре вакытында дәшмәвең артык булып, алга карау һәм эш турында гына уйлау тиеш чакта, үз тирәсендә күп кеше буталуын яратмый иде.

Аның ияре астында – бәлки, ярты дөньяны кичкәндер, чыныккан, чуерташ кебек шомарган, күкрәге һәм җилкәсе таза, ак яллы, кара койрыклы, ефәк кебек тигез-шома атлый торган яраткан юргасы Хуба. Чыдамлык һәм тиз йөреш ягыннан ким булмаган, кирәкләре чыга калса дип, сыбайлылар карамагындагы ике алмаш ат ялтырап торган бизәкле хан дирбиясендә йөксез генә бара. Хан атларны, тирли башлавы белән, юл уңаенда алыштыра.

Башы журналның 8 нче санында. Тәрҗемәче – Мөдәррис Вәлиев.

Әмма игътибарга иң лаегы Чыңгызханның тирә-юнендәгеләр – гомерләренә аларның үзләреннән бигрәк Чыңгызхан ия булган, шуңа да бит инде алар, хәнҗәр йөзе кебек, бик күпләр арасыннан берәмтекләп сайлап алынган – курку белмәс кизүвыллар һәм ясавыллар, шулай ук аларның табигатьтә сирәк табыла торган саф алтын төсле менә дигән менге атлары да түгел. Юк, ул сәфәрдә күз төшәргә мөмкин нәрсә бөтенләй бүтән иде. Юл буе Чыңгызханның баш өстендә, аны кояштан күләгәләп, болыт йөзде. Ул кая – болыт та шунда. Зур тирмә чамасы ак болыт, нәкъ менә тере җан иясе сыман, аның артыннан калмый барды. Һәм аның илаһи ишарә булуы беркемнең дә башына килми иде, югарыда болыт кисәкләре азмыни, ә бит Дөньялар Әмиренә фатихасын Күк-Тәңре шул рәвешле белгертте. Чыңгызхан үзе, нәрсәдер сизенеп, теге болытны астыртын гына күзәтә башлады, аның чыннан да Күк-Тәңренең ихтыяр тамгасы булуына торган саен ныграк ышана барды.

Болытның пәйда буласын Чыңгызхан бервакыт үзенә якынлашырга рөхсәт иткән ниндидер сәйяр күрәзәче алдан әйткән иде. Чит туфрактан килгән ул адәмчек, алтын тирмәдәге тәхетендә тәкәббер генә утырган дала илбасарының дәһшәтле чыраена төкергән кебек, горур башын югары тотып, ханның аягын үпмәде, аңа бил бөкмәде, ялагайлык күрсәтмәде, яраклашып күрәзәлек итмәде. Чандыр, йолкыш, җилкәсенә кадәр төшкән гаҗәеп озын чәче белән нәкъ бөдрәләрен тузгыткан хатын-кызны хәтерләтә иде ул. Карашы кырыс, сакалы дәү, кара-кучкыл йөз сызыклары арык иде.

– Мин синең янга, хакан, шуны әйтергә килдем, – дип уйгыр-тылмач аша сүзен җиткерде ул, – Күк-Тәңре ихтыяры белән, сиңа югарыдан аерым ишарә-ым булачак.

Чыңгызхан көтелмәгән хәлдән бер мизгелгә һуштан язган кебек булды. Бу килмешәк үз акылындамы соң, әллә мондый тәкәллефсезлек өчен аңа ни буласын аңламыймы?!

– Нинди ишарә, һәм сиңа ул кайдан билгеле? – дип, ярсуын көчкә тыеп, маңгаен җыерып кызыксынды чиктән тыш кодрәт иясе.

– Кайдан билгеле – анысын белгертергә ярамый. Ә ишарәгә килгәндә, яшерми әйтәм – синең баш очында ак болыт пәйда булачак һәм сиңа ияреп барачак.

– Болыт?! – Таң калуын тыя алмыйча кычкырып җибәрде Чыңгызхан, кашларын текә сикертеп.

Тирә-юнендәгеләрнең барысы да, хан ачуының шартлавын көтеп, ирексездән җәя җебе кебек тартылдылар Куркудан тылмачның да иреннәре агарды. Җәза җиле аңа да кагылырга мөмкин иде бит.

– Әйе, болыт, – дип җаваплады гаиптән хәбәр китерүче. – Ул – синең җирдәге бик югары дәрәҗәдә булуыңа үз фатихасын бирүче Күк-Тәңренең таныгы. Ләкин син бу болытны сакларга тиешсең, әгәренки аны җуйсаң, шул мәлдә үк хакимиятеңне, кодрәтеңне югалтачаксың...

Алтын тирмәдә үле тынлык урнашты. Чыңгызханнан ул мизгелдә теләсә нәрсә көтәргә була иде, тик кинәт аның карашының ярсуы, учактагы янып бетүче ут кебек, басыла төште. Үч алырга кыргый омтылышын җиңеп, ул мосафир күрәзәченең сүзләрен ачу китергеч дорфа кыланмыш дип кабул итмәскә кирәклеген һәм бигрәк тә аны җәзаларга ярамаганлыгын, әгәр шулай итсә, үзенең ханлык дәрәҗәсен төшерәчәген аңлады. Һәм Чыңгызхан, мәкерле елмаюын җирәнрәк төстәге сыек мыеклары астына яшереп, сүзен дәвам итте:

– Фаразан, синең күңелеңә бу хәбәрне Күк-Тәңре салды, ди. Ярар, мин дә моңа ышандым, ди. Тик син әйт әле, зирәкләрнең зирәге булган килмешәк, күктәге ирекле болытны мин ничек саклый алырмын соң? Ул болытны тотып торсыннар дип, канатлы атка атландырып, куалап торучылар җибәрергә түгелме тагын? Алар, алай-болай югалмасын өчен, аны ияр күрмәгән ат кебек авызлыклап куярга тиешләрдер бәлки, ә? Җил иркендәге болытны ничек үземә бәйләп куярга соң миңа?

– Ә анысы инде – синең кайгың, – дип кыска гына җавап бирде мосафир. Һәм кабат барысы да катып калды, тагын үлем тынлыгы урнашты, тылмачның да иреннәре янә агарды, бу мәлдә алтын тирмәдә булганнардан берсе дә әллә ахмаклыгы аркасында, әллә аңлашылмый торган бүтән берәр сәбәбе булып, үзен котылгысыз һәлакәткә дучар иткән бичара күрәзәчегә күзләрен күтәреп карарга кыймады.

Чыңгызхан тонык тавыш белән әйтеп куйды:

– Берәр бүләк бирегез дә китсенсәнә. – Аның бу сүзләре күңелләргә кибеп коргаксыган туфракка тамган саран яңгыр тамчылары кебек коелды.

Ошбу сәер, мәгънәсез очрак тиздән онытылды. Дөньяның нинди генә мәхлуклары юк, анысы да хак. Гаиптән хәбәр китердем, дип масаеп тора менә берәү! Әмма, ул килмешәк акылга җиңеләеп кенә үлем белән шаярган, дип әйтү гадел булмас иде. Үзенең нинди тәвәккәл адымга барганын аңлагандыр ул. Ханның кизүвылларына аны шунда ук боргычлап алып кыргый ат койрыгына бәйләп җибәрү – тәкәллефсезлеге һәм чиктән тыш оятсызлыгы өчен мәсхәрәле үлем кочагына ташлау берни тормый иде. Әмма шулай да ул кыю килмешәкне, бернидән дә өркеп тормыйча, чүлдәге арысланга тиң дәһшәтле һәм шәфкатьсез хаким каршысына килеп басарга нәрсәдер этәргән, нәрсәдер рухландырган бит. Акылсыз адәмнең сәер кыланмышы булдымы ул, әллә чынлап та бу – Күк-Тәңре шаяруы идеме?

Һәм инде узган көннәр агышында барысы да онытылгач, нәкъ төп-төгәл ике елдан, күрәзәче бичаракай кабат Чыңгызханның исенә төште.

Хаканлыкта Кояш баешы сәфәренә әзерләнү өчен чынлап та тулы ике ел вакыт китте. Соңрак Чыңгызхан инанды, хаканлык чикләрен тыела алмыйча киңәйтүнең юлларын табып килә торган хакимиятенә бу ике ел бөтен дөньяны яулап алуга, зарыгып көтелгән максатына – җирләрне һәм төбәкләрне басып алуга таба барыр өчен җитәрлек көч-гайрәт һәм юллык ризык туплауның иң эшлекле дәвере булган икән, – аларны кулына төшергәннән соң инде ул үзен, хаклы рәвештә, Дөньяның бөтен Дүрт Тарафы, җиңелмәс атлы чирүенең дәһшәтле дулкыны каплаган чикләргәчә бөтен ерак җирләр Хакиме дип саный алачак. Дала хакименең гаять рәхимсез асылы, аның тарихи миссиясе соңгы исәптә менә шушы саташулы идеягә, бөтенесе өстеннән хакимлек итү һәм котылгысыз рәвештә чиктән тыш кодрәтле булу сусынына кайтып кала иде. Һәм шуңа күрә мәмләкәтенең бөтен яшәеше – галәмәт зур Азия киңлекләрендә аның хакимлегендәге барча олысларның, бер каты кул астына тупланган төрле кабилә-нәселдән килүче халыкларның, калалардагы һәм күчмә тораклардагы бөтен бай вә гидайларның һәм соңгы исәптә һәр кешенең, ул кем булып, ни белән генә шөгыльләнмәсен, тулысынча бу мәңге туя алмас иблис вәсвәсәсенә – тагын, тагын да басып алуларга, яңадан-яңа җирләрне һәм халыкларны буйсындыруга йөз тота иде. Шуңа күрә һәммәсе дә баштанаяк бары тик аңа – Чыңгызханга хезмәт итү белән мәшгуль, барысы да бердәм нияткә – аның

хәрби куәтен туплау, үстерү, камилләштерүгә юнәлтелгән. Җир астыннан табып алынган һәм корал ясауга тотып булган бөтен нәрсә, тормыш өчен кирәкле бөтен төзү эшчәнлеге яу хаҗәтләренә тотылырга тиеш; Чыңгызханның Аурупага, аның әкияттәгедәй искиткеч бай калаларына көч белән ыргылуына, – ә анда кымыз елга булып агачак, һәр сугышчыны мул табыш көтә, анда – куе-яшел урманнар, ат корсагына тигәнче үскән үләне белән кызыктыручы аланнар һәм болыннар; кыскасы, дөнья күкрәгенә ике ботың белән басып хакимлек итү куанычы Чыңгызханның авызыннан ялкын ургылдыручы аждаһалы һоруңнары астында яуга барган һәркемгә тиячәк, һәм аларның һәркайсы, үзенең куенында иң дәртле хатынны татыган кебек, җиңү ләззәтен кичерәчәк, имеш. Шуның өчен алга барырга, җиңәргә һәм яңа җирләр яуларга боера бөек хакан, һәм ул әйткәнчә булып чыгар да...

Чыңгызхан исәпчел һәм алдан күрүчән, бөтен барлыгы белән эш (яу) турында гына кайгыртучы гамәл кешесе иде. Аурупага басып керү өчен әзерлек башлангада, ул вак-төягенә хәтле барысын да исәпләп карады, алдын-артын уйлады. Тугрылыклы шымчылары һәм аның тарафына качып чыгучылар, хаҗ кылучылар һәм сәйяр дәрвишләр аша, алып-сатарлар һәм төрле илләрдә эш йөртүче кытай-уйгырлар, гарәп-фарсыларның телен чиштереп, гаять зур хәрби көчләрнең хәрәкәте өчен белергә тиешле һәрнәрсәне – бөтен иң кыска юлларны һәм уңайлы кичүләрне белеште. Чирүе юнәләсе җирләрдә яшәүчеләрнең холык-фигыльләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен һәм шөгыльләрен исәпкә алды. Ул яза белми, шунлыктан аңа боларның барысын да, ягъни яу сәфәрендә үзен көтәргә мөмкин һәммә нәрсәнең файдасын һәм зыянын бизмәнгә салып чагыштырганнан соң, хәтер сандыгында сакларга туры килә иде. Эш барышында барысын да җайга салу, иң мөһиме – тайпылышсыз тимер тәртипкә ирешү бары тик шулай гына була ала. Чыңгызхан бернинди йомшаклык күрсәтүгә, дилбегәне бер мизгелгә дә бушатуга юл куймады, һичкем һәм һични аның төп максатына – Аурупаны басып алуына комачаулык итәргә тиеш түгел иде.

Нәкъ шул чакта, үзенең алга таба адымнарын уйлаганда, Чыңгызхан гасырларда күренмәгән эшкә – халык-чирүендә бала тудыруны тыюга барды. Хикмәт шунда ки, атлы яугирләрнең хатыннары һәм кечкенә балалары, гадәттә, гаилә олауларында, урыннан урынга күчә-күчә, чирү артыннан баралар иде. Бу гадәт күптәннән бирле яши, аңа кайчандыр тормыш ихтыяҗы мәҗбүр итте, чөнки, очыкырые күренмәгән үзара ызгыш-талашлар вакытында, бер як, еш кына, икенче якның тирмәләрдә яклаучысыз калган хатыннарын һәм балаларын үтереп, берберсеннән үч ала иде. Өстәвенә, бу нәселнең тамырына ук балта чабар өчен, беренче нәүбәттә, көмәнле хатыннарны үтерәләр. Әмма заманалар алышыну белән тормыш агышы да үзгәрде. Элек бертуктаусыз дошманлашып яшәгән ыруглар Чыңгызхан чорында көннән-көн күбрәк үзара килешә һәм бөек дәүләт гөмбәзе астында берләшә башладылар.

Яшь чагында, әле үз исеме белән Темучин дип йөртелгәндә, Чыңгызхан да күрше кавемнәр белән аз сугышмады, үзе ерткычларча кыланганына күрә җәфасын да татыды – меркитләр һөҗүм ясаганда, яраткан хатыны Бортэ, урланып, аларда берара кәнизәк булып алды. Хакимияткә ирешкәч, Чыңгызхан үзара сугышларны бик рәхимсез рәвештә бастырырга кереште. Ызгыш-талаш аңа идарә итәргә комачаулый, дәүләтнең көчен суыра иде.

Дәвамы бар ■

Кабатланмас басма

Мин – «Безнең мирас»ның һәр санын көтеп алучыларның берсе.

«Безнең мирас» («Мирас») журналының гамәлгә куелуы безнең фән, мәдәният өлкәсендә ифрат зур адым булды. Мин, мәсәлән, Башкортстанда, Мари Илендә, Удмуртиядә, Мордовиядә дә милләттәшләребезнең бу журналны яратып, көтеп алуларының шаһитымын.

Журнал безнең мәгълүмати киңлекне тулыландырган, баеткан, башкаларны кабатламаган, үзенчәлекле басма булды. Ул елдан-ел колачын киңәйтә, адымнарын ешлата бара, яңа рубрикалары, яңача бизәлеше белән, әлегәчә таныш булмаган сәхифәләрне, шәхесләрне ачып, аларны укучыларга җиткерүе белән куандыра.

Форсаттан файдаланып, «Безнең мирас»та көч куючы әдипләребез Ләбиб Лерон, Марат Закирга һәм башка зыялы егет-кызларыбызга иҗади уңышлар телим.

Мөдәррис ВӘЛИЕВ,
язучы, филология фәннәре кандидаты,
«Мәгариф-Вакыт» нәшриятының генераль директоры

Мирасыбыз

...Мирас булып безгә тапшырылган
Бабайларның изге ядкяре...
Газизләрдән-газиз Ана теле,
дастаннары, риваятьләре!..

М.Мирза

«Мирас», «Чын мирас», «Безнең мирас».
Егерме биш ел эчендә өч төрле исемдә аталуының аерым сәбәбе булуга карамастан, аның төп эчтәлеге, төп багланышы, мәгънәсе – мирас төшенчәсенә бәйле.

Мирас – аерым инсан өчен ата-анадан, нәсел-ырудан калган истәлек тә, алардан күчкән генетик билгеләр дә, гадәт-йолалар, акыл тәҗрибәсе дә. Һәр кешенең матди, рухи мирасы булган кебек, һәр халыкның да олуг хәзинәсе – мирасы бар.

Халкыбызның меңнәрчә еллык дәүләтчелеге тарихын, рухи-мәдәни мирасын халкыбызга җиткерү өчен бар ителгән «Мирас» журналы беренче саннарыннан ук үзенә йөкләнгән шул миссияне үтәүгә кереште. Күтәп алынган әлеге басмага күренекле галимнәр чакырылып, аның эшенә дәүләт архивы, фәнни-гамәли институтлар, оешмалар җәлеп ителде. «Мирас» журналы тиз арада татар зыялыларының, укытучыларның өстәл китабына әверелде. Журналны Россиядән читтәге мәмләкәтләрдәге милләттәшләребез дә яздырып алды... Иң мөһиме – ул республикабызның барлык китапханәләренең әдәби фондларын тулыландырды.

Әйткәнебезчә, бөтен халкыбызның мирасын барлау, белеп тору, аны саклау һәркем һәм бөтен халык вазифасы, бурычы. Аны бүлгәләү, аны хосусыйлаштыру – аңа зыян салуга китерер иде.

Иҗтимагый әһәмияткә ия булган мондый басманы бөтенләй югалту киләчәк алдында гафу итмәстәй хата булыр иде.

Яңа матбугат чарасы буларак, «Чын мирас» булып теркәлүендә аның булачак редакторының да, авторларының да катнашы юк иде. Мирас чын булмыйча, ялган булмас. Гәрчә мирасның яхшысы, начары булырга мөмкин...

«Чын мирас» журналының беренче – тәкъдир итү санын чыгаруны мин фәкыйрегезгә – ул чактагы Татарстан Язучылар берлеге рәисенә йөкләделәр. Беренче санны чыгаруга җәлеп ителгән галимнәр, мөхәррирләр, аның киләчәктәге хезмәткәрләре дә булачак иде. «Чын мирас» тиз арада үз укучыларын, үз авторларын тапты... Дөресрәге, әүвәлге «Мирас»ның югалып торуына тирән борчылу кичергән зыялыларыбыз һәм аның күпсанлы укучылары журналның яңарып чыгуына чын-чынлап сөенделәр. Бердәнбер кабул итеп бетермәгән яклары – журналның исеменә «чын» сүзе өстәлүе иде. Әйткәнемчә, ул сүз безгә гамәлгә куючылардан «мирас» булып тапшырылганга, аның исемен үзгәртү күп кенә чыгымнар һәм вакыт таләп иткәнлектән, төп игътибарны журналның алдагы һәрбер санының тыгыз эчтәлектә булуына юнәлттек. Унсигез айда 24 санын бастырып чыгаруыбыз нинди тыгыз ритмда хезмәт итүебезне сөйли булыр. Бу

җөмләне язганда журналыбызның укучылары даирәсен булдыру максатында дистәләрчә авыл, шәһәр мәктәпләрендә, яшәү урыннарында, күрше республикатөбәкләре шәһәр-районнарында очрашуларга йөрүебезне дә күз алдында тотам.

«Мирас» өр-яңадан өр-яңа булып аякка басты, шөкер. Аның эчтәлеге, авторлары турында бәйнә-бәйнә сөйләүнең кирәге юктыр. Алар сезнең күз алдында, хөрмәтле укучыларыбыз!

«Чын мирас»та әүвәлге «Мирас»ның әүвәлге чорындагы эшчәнлеген дәвам итүне: Мирасның үзен һәм Мирасны фән буларак пропагандалауны төп концепциябез дип билгеләдек. Яңа журналыбызга эшкә чакырган галимнәр, мөхәррирләр әүвәлге журнал эшеннән чын-чынлап хәбәрдар булды. Халкыбызның дәүләтчелеге тарихы, әдәби-мәдәни мирасы бүлекләрен алып баруга Фәннәр академиясенең тарих институты профессоры, тарих фәннәре докторы Илдус Котдус улы Заһидуллинны, Казан гуманитар педагогия университеты өлкән укытучысы, филология фәннәре кандидаты Рамил Гомәр улы Ханнановны чакырдым. Алар, үз чиратында, бик тә булдыклы, эшлекле яшь галимнәрне тәкъдим итте. Тарих институты аспиранты Ленар Гобәйдуллин, ИЯЛИ аспиранты Алия Мөбарәкшина, Ринат Миңнегалиевләр беренче көннән үк зур теләк һәм җаваплылык белән эшкә чумды. Журналны бизәүче Диләрә Нәүрүзова, корректоры Дания Фәйзуллиналар үз эшләренең осталары булды.

Бүгенге көндә «Безнең мирас» журналы әүвәлге «Мирас», «Чын мирас»лардан башланган изге эшне лаеклы дәвам итә. Журналның һәр чыгарылышын кызыксынып укып барам, аларда үзебез башлаган эшләрнең дәвамын күреп тә, өр-яңа башлангычлар күреп тә куанам: «Мирас», дим, «Чын мирас», «Безнең мирас» – мирасыбыз, киләчәгебез, дим! Амин, шулай булсын!

Илфак ИБРАҺИМОВ,
«Казан утлары» журналының баш мөхәррире

Мөдәррис Әгъләм
(1946-2006)

МИН ӘЙТТЕМ...

...Стенага терәп сорый Кирәк –
тамагы киң аның Кирәкнең...
Рәсәй кешесе дә кеше кебек
бер яшәргә тиеш:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Тыелып торган чишмәләр күп иде,
рәхмәт, Заман, ачтың, киңәйттең...
Калганнары миннән соңгыларның
әйтер сүзен көтә:
– МИН ӘЙТТЕМ...

...Бер дә гаҗәп түгел яманлыкка
әйләнүе яхшы ниятнең...
Яманлыкның гына
яхшылыкка әйләнүе булмас:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Үз яры бар хәтта тал-тирәкнең,
ник булмасын һәрбер йөрәкнең...
Эзләп, табып, югалтып ла кара –
син дә саргаерсың:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Еламаска өйрәтүең белән
шигырь язарга да өйрәттең...
Рәхмәт, язмыш, илгә һәм халыкка
әйтер сүзле иттең:
– МИН ӘЙТТЕМ!

...Тарту безнең нәселдә юк иде,
ә мин, җүләр, байтак көйрәттем...
Илне яклап көрәшмәгәннәргә
илне тарту хәрам:
– МИН ӘЙТТЕМ!

Казакъның «баш акыны»

Хатыйп Миңнегулов

(Абайның тууына 170 ел тулу уңае белән)

Йоклап яткан йөрәгеңне җыр уятыр,
Яшәвеңнең мәгънәсе һәм яме артыр,
Ләззәт биреп, дәрт кузгатып күңелеңдә,
Яшь баланы юаткан күк ул юатыр.
***Әхмәт Исхак** тәрҗемәсе*

Һәр халыкның сүз сәнгатендә аны дөньяга таныткан, кавемнең үзенә күрә бер символына әверелгән әдипләр бар: урысларда ул – Пушкин, үзбәкләрдә – Нәваи, украиннарда – Шевченко, кыргызларда – Айтматов, татарларда – Тукай... Бу затларның иҗатында аларны тудырган, үстергән халыкның асылы, яшәеше, моң-зарлары, теләк-омтылышлары аеруча тулы, калку гәүдәләнеш таба.

Мондый бөек әдип-шагыйрьләр үз кавеменең йөзе, энциклопедиясе кебек. Җиһан укучысы бу халыкны, иң беренче чиратта, шушы затлар, аларның иҗат җимешләре аркылы күзаллый, танып белә. Казакъ халкының мәшһүр улы Абай да әнә шундый символга әверелгән шәхесләрнең берсе. Инде аның исеме гасыр ярымнан артык казакъ белән бергә яши, куана, кайгыра, көрәшә. Шунысы кызыклы: ул да, гарәпләрнең Мөтәннәбие, фарсыларның Гаттары, татарның Дәрдеменде кебек, дөньяга рәсми исем-атамасы белән түгел, ә тәхәллүс-кушаматы белән мәгълүм. Әйтүләренә караганда, артык хәрәкәтчән булганы өчен әбисе Зәрә, әнисе Үлҗан (чын мәгънәсендә исеменә җисеме туры килешле зат: олы җанлы) шагыйрьне кечкенә вакытта яратып «абай», «абай бул» дип атаганнар. «Саклык», «уйчан», «игътибарлылык» мәгънәләрен белдергән «абай» сүзе бераздан бу олуг шәхеснең төп исеменә дә әверелеп китә [1:17, 2:25]. Чыннан да, Абай үзенең яшәеше, иҗаты белән кадерле әнисенең иркәләп әйткән сүзенә тугры кала: инсаннарга, кавемнәргә сак, игътибарлы була, һәрчак тормыш, милләт язмышы хакында уйлана.

Абай (Ибраһим Кунанбаев) 1845 елда Семей (Семипалатинск) тарафларындагы Каскаболак җәйләвендә туа һәм шунда ук 1904 елда вафат та була. Шул тирәдәге Җидебайда дәфен кылына. Чыңгызтау итәгендә урнашкан бу җирләр хәзерге Көнчыгыш Казакъстан өлкәсенең Абай районы (үзәге – Караул) составына керә.

Ибраһим мул һәм җиту тормышлы, заман агышын тоеп яшәгән гаиләдә туып үсә. Искетам җәйләвендә этисе ачкан мәдрәсәдә укый. Биредә аңа татар мөгаллиме Габитхан белем бирә. Бераздан этисе булачак акынны Семей мәдрәсәсенә күчерә. Бу вакытта һәм аннан соң да әлеге кала Россия төркиләренең мөһим сәүдә, административ, мәдәни үзәкләренең берсе була. Биредә шактый гына татарларның, аеруча сәүдәгәрләрнең, яшәве мәгълүм. Алар казакълар ара-

Яшь Абай.
Ә.Кастеев рәсеме.
1945 ел

Абайның Семейдәге
музей-йорты

сында белем-мәгърифәт таратуда да мөһим роль уйнаган. Бу хакта Казакъстан галимнәре менә нәрсәләр яза: *«Особую роль сыграли татары в повышении уровня грамотности населения в XIX-начале XX века. При отсутствии разветвленной сети государственного образования в Казакъстане именно татары стали главными распространителями грамоты среди казахского населения... В 1863 году в Семипалатинске действовали уже девять частных татарских школ с почти 500 учащимися. В то же время в 14 русских школах этого города обучалось около 340 детей»* [2:9]. XX гасыр башына Семейдәге татар уку йортларының саны 12гә җитә, аларның өчесендә кыз балалар да белем ала

[3:61]. Абай бу каладагы укымышлы татар мулласы Әхмәт Риза мәдрәсәсендә өч ел укый, татарча китаплар, бигрәк тә Ш.Мәрҗани, К.Насыйри хезмәтләре белән ныклап таныша. Мәдрәсәдә укуының соңгы елында өч айлап «приходская школа»га да йөреп ала, урысча укырга өйрәнә. Истәлекләрдә аның Семейдәге шәһәр һәм хосусый китапханәләрдән бихисап китаплар алып укуы да ассызыклана. Болар арасында Шәрык, татар, урыс, Аурупа авторларының әсәрләре дә була.

Актив табигатьле, инициативалы, талантлы шагыйрь соңрак та күптөрле затлар (казакъ, татар, кыргыз, урыс, поляк кебек кавемнәр вәкилләре) белән аралаша, элемтәдә тора. Шунысын да искә төшерик: ул вакытларда Семей каласы – патша хакимияте тарафыннан сәяси яктан ышанычсыз дип табылган кешеләрне сөрү урыны да булган. Абай андый кешеләр белән дә аралашкан. Мәсәлән, Добролюбов һәм Чернышевскийларның фикердәше, Тургеневның «Аталар һәм балалар» әсәрендәге Базаровның прототибы Евгений Михаэлис үзенең сәяси эшчәнлеге өчен әүвәл Шлиссельбург крепостена ябыла, 1859 елда Семейгә сөрелә. Абай бу зат белән дустанә мөнәсәбәтләрдә тора. Кайбер язмаларда аның: *«Михаэлис сделал для меня больше, чем родной отец, открыв глаза на мир»*, – дигән сүзләрен дә телгә алалар [1:16-17].

II

Абай, үз чоры казакъ иҗтимагый тормышында мөһим роль уйнаса да, тарихка барыннан да элек шагыйрь, әдип буларак кереп калган. Юкка гына аны казакъларның иң бөек, иң югары дәрәҗәле баш акыны дип йөртмиләр. Өстәвенә, ул әле көйче-композитор да. Күп кенә шигырьләрен Абай чичән сыйфатында бәдиһә-импровизация ысулы белән чыгарып, музыка коралында уйнап, үзе башкарган. Хәзерге вакытта аның 27 җыры билгеле. Аларны үзешчән җырчылар гына түгел, ә профессиональ артистлар да бик теләп башкара.

Татар шагыйре Дәрдемәнд кебек, Абайның да иҗат мирасы күләм ягыннан зур түгел: 140тан артык шигырь, 3 поэма, 80 битлек проза, тәрҗемә әсәрләр. Алар, нигездә, уртача калынлыктагы һәм форматтагы бер китапка сыеп бетә. Әмма мәгънәви яктан, эчтәлек һәм сәнгатилек ноктасыннан, иҗтимагый-мәдәни, тарихи җәһәттән аның һәр әсәре игътибарга лаек.

Абайның язма мирасы берничә әдәби-эстетик башлангычның синтезкушылмасын тәшкил итә. Барыннан да элек әдип казакъ фольклорына, төрки чичәнлек традицияләренә таяна, авыз иҗатындагы казанышларны мул һәм уңышлы файдалана. Аның әсәрләрендә ораторлык, бәдиһә-импровизаторлык, публицистик башлангычлар өстенлек итә. Бу – бер. Икенчедән, Абай – Баласагунлы, Ясәви, Нәваиләрдән килүче төрки язма әдәбият традицияләрендә тәрбияләнгән шагыйрь дә. Өченчедән, ул Урта гасыр гарәп-фарсы классик сүз сәнгатеннән дә билгеле бер дәрәҗәдә хәбәрдар. Аның әсәрләрендә Коръән, «Кәлилә вә Димнә» һәм «Кабуснамә» китапларына, Сәгъди, Гаттар әсәрләренә, Фәрәби һәм аның аркылы Сократ, Платон, Аристотель хезмәтләренә авааздаш яклар да еш очрап тора. Дүртенчедән, Ибраһим Кунанбай углы Пушкин, Лермонтов казанышлары, урыс теле аркылы Аурупа сүз сәнгате белән дә теге яки бу дәрәҗәдә таныша.

Абай өчен әдәбият эстетик ләззәт чыганагы гына түгел, ә иҗтимагыйсәяси, әхлакый, милли-мәдәни мәсьәләләр өчен көрәштә мөһим корал да. Аның әсәрләрендә инсан, җәмгыять,

кавем яшәешенең күптөрле тармаклары, проблемалары гәүдәләнеш таба. Автор күп гасырлар буе адәм балалары туплаган рухи кыйммәтләрне яклый, гаделлек, намус-вөҗдан, иман-ышаныч төшенчәләрен үзәккә куя, һәр кешенең, һәр кавемнең ихтирамга, бәхеткә, яхшы тормышка хаклы булуын раслый. Шуңа күрә дә Абай әсәрләре казакъ халкы өчен генә түгел, ә башка кавемнәр өчен дә үз һәм якын.

Абай – барыннан да элек лирик шагыйрь. Аның парчалары өчен уйфикер, хис-кичереш тыгызлыгы, сөйләм динамикалылыгы хас. Ул пейзаж лирикасы остасы да. Аның «Җәй», «Кыш», «Яз» шигырьләре, мәсәлән, ел фасылларының сүз белән ясалган гүзәл рәсем-картиналарын хәтерләтә.

Абайның өч поэмасы да («Искәндәр», «Мәсгуд», «Әзим хикәяте») әкияти-романтик рухта язылган. Автор аларда вөҗдан, сүзгә тугрылык мәсьәләләрен яктырта, комсызлык, байлык артыннан куу, алдау кебек төшенчәләрнең һәм инсани, һәм әхлакый яктан начар, зарарлы булуын күрсәтә. Искәндәр (Александр Македонский) дөнья әдәбиятында барыннан да элек идеал дәрәҗәдәге бөек хөкемдар рәвешендә тасвирлана. Абай исә аның басып алуларын, кылыч сәясәтен, һавалылыгын кискен тәнкыйтьли. Автор фикеренчә, комсыз күзне кабер туфрагы гына туендыра ала [4:295].

Элеккеге Шәрык, шул исәптән төрки сүз сәнгатендә үгет-нәсыйхәт бирү, хикмәтле сүз әйтү, әдәбиятны инсани, әхлакый максатларга файдалану мөһим урын били. Абай да бу традицияне уңышлы дәвам иттерә. Аның шигырь-поэмалары шактый дәрәҗәдә дидактик рух белән сугарылган. Ә инде Абайның «Кара сөз» («Гаклия») дип исемләнгән чәчмә әсәре тулысы белән үгет-нәсыйхәт, киңәш-теләк характерында. Шуңа күрә аны еш кына

Абай уллары Акылбай (сул ягында) һәм Түрәгол белән. 1896 ел

«Нәсыйхәт китабы» дип тә йөртәләр. Автор бу әсәрен гомеренең ахыргы елларында үзенең якыннарына, халкына васыять, сабак рәвешендә язып калдырган. Эчтәлеге һәм рухы белән К.Насыйриның «Тәрбия китабы»н хәтерләткән «Кара сөз» композицион җәһәттән 45 «сүз»гә бүленгән. Һәр ике автор да халыкның яшәеш тәҗрибәсенә, антик дөнья, Шәрык рухи казанышларына таяна. Хәтта охшаш, уртак фикер-мотивлар, образлар да бар. «Тәрбия китабы»нда әдәби башлангыч, гыйбрәтле сюжет-вакыйгалар өстенлек итә. «Нәсыйхәт...»тә исә публицистик як, реаль тормыш белән бәйләнеш, тәнкыйди караш көчле. Казакъ авторы үз халкының артталыгына борчыла, аны ничек итеп алга җибәрү, тәрәккыят юлына бастыру хакында яна, көя. «Нәсыйхәт китабы»ның һәм, гомумән, Абай әсәрләренең телендә гарәп-фарсы алынмалары аз, гавам сөйләменә якынлык көчле.

Абай урыс шигъриятенең клас-

сик үрнәкләрен казакъ укучыларына җиткерүдә дә нәтиҗәле эшли. Ул А.Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасыннан аерым өзекләрне, М.Лермонтовның өч дистәләп әсәрен («Вадим», «Бородино», «Хәнҗәр» һ.б.), И.Крыловның унбер мәсәлен, И.Бунин, Я.Полонскийның аерым шигырьләрен казакъчага тәрҗемә итә. Абай урыс теле аша Байрон, Гёте, Мицкевичның аерым парчаларын үз туган теленә аудара.

Шунысын да искәртик: Абайның тәүге шигырьләр җыентыгы 1909 елда гына дөнья күрә. Моңа кадәр аның әсәрләре, еш кына авторы күрсәтелмичә, кульъязма хәлендә, өлешчә телдән дә тарала. Аларның вариантлары да очрый.

Соңгы йөз елдан артык вакыт эчендә Абайның тормышы, иҗаты ныклап өйрәнелде, шактый гына хезмәтләр язылды, әсәрләре оригиналда, төрле тәрҗемәләрдә күп мәртәбәләр басылды, шагыйрьнең үзе хакында дистәләгән китаплар, сәнгать әсәрләре иҗат ителде. Болар арасында аеруча шагыйрьнең якташы Мохтар Әүезовның «Абай» дип исемләнгән роман-эпопеясы йөзек кашы кебек аерылып тора. Ул Сәрвәр Әдһәмова тарафыннан татарчага да тәрҗемә ителеп, 1957, 1960 елларда аерым китап рәвешендә басылып чыккан. М.Әүезов дилогиясе казакъны, Абайны һәм авторның үзен бөтен дөньяга танытты [7:291-295].

III

Абай һәм татар дөньясы мәсьәләсен без Семей каласында уздырылган һәм бөек шагыйрьнең тууына 170 ел тулуга багышланган Халыкара конференциядә махсус рәвештә яктыртырга тырышкан идек.

Абай татар мәктәп-мәдрәсәсендә укыган, татарлар белән аралашкан, аларның тормыш-көнкүрешен, сүз сәнгатен яхшы белгән. Үзенең «Нәсыйхәт китабы»ның («Кара сөз»нең) икенче бүлекчәсендә («сүз»ендә) автор, урыс, үзбәк (сарт) халыкларын сыйфатлаганнан соң, болай яза: *«Инде татарына килсәң – солдат хезмәтенә дә чыдам, ярлылыкны да, килгән казаны да түзем генә кичерә белә алар. Мулла, мәдрәсәләрен саклап, Ходайга зарланмый гына яшиләр. Хезмәт куеп мал табуның да җаен шулар белә, зат-зиннәт тә юк түгел үзләрендә. Козгын тамагыбызны туендыру өчен без татар байларына әле ялчы, әле кош аулаучы булып ялланып кына торабыз. Безнең иң баебызны да алар: «Синең шакшы аягың белән пычратырга дип юылган идән түгел, чыгып тор әле, сасы казакъ», – дип өennән куып чыгара. Андый халык һич хур булмас, чөнки һаман һөнәр үзләштереп, төрлечә мал табып, бер-беренә булышып көн күрәләр»* [8:13, 187-188].

Аерым басмаларда Абайның Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Х.Фәизханов, И.Гаспралы кебек татар күренеклеләренең хезмәтләрен белүе, Казанда нәшер ителгән китаплардан файдалануы телгә алына. Үз чиратында татар зыялылары да бөек шагыйрьне, аның әсәрләрен теге яки бу дәрәҗәдә беләләр. Казакъ арасында мөгаллимлек кылган, атаклы «Казакъ кызы» романын тудырган Г.Ибраһимов үз язмаларында Абайны берничә мәртәбә искә ала [9:230, 431]. 1924 елда язылган «Пролетариат әдәбияты турында» исемле мәкаләсенең бер искәрмәсендә мондый юллар да бар: *«Бу казакъ шагыйренең әсәрләре мәрхүм Ниязколый[1] тарафыннан каралып, Казанда мәҗмуга рәвешендә чыкты»* [9:431].

[1] Ниязколый Максудов – Троицкида мәдрәсә мөгаллиме, «Шура» журналында басылган педагогик эчтәлектәге мәкаләләр авторы.

Мөгаен, Г.Ибраһимов Абайның 1922 елда Казанда дөнья күргән җыентыгын күздә тотадыр.

Дистә елдан артык гомерен Җаек-Уральск каласында уздырган Г.Тукай, гәрчә Абай исемен телгә алмаса да, казакъ халкының сүз сәнгате, шул исәптән «олы акын» иҗаты белән дә таныш була. «Шигырьләребез» исемле мәкаләсендә (1907) ул хәтта Абай әсәренә авазлаш «Карагым, айналаен...» дип башланган бер шигырь дә китерә һәм аны татар шагыйрьләренә үрнәк итеп тә куя [10: 223-224].

Оренбург төбәгендә яшәгән Дәрдемәнд тә казакъ әдәбияты белән кызыксына. Үз иҗатында ул Абай ярытып кулланган «алтыаяк», «сигезаяк» шигъри шәкелләренә дә мөрәҗәгать итә. Казакъ далаларында мөгаллимлек кылган Ш.Бабич Абай әсәрләрен «фәсахәт вә ләззәт табып» укуын яза, аны гарәпләрнең Имрелкайсысына (VI гасыр) һәм үзебезнең Тукайга тиңли [11:412].

Абай хакында аерым факт-мәгълүматлар «Тәрҗеман», «Вакыт», «Шура» һәм кайбер башка татар гәҗит-журналларында да очрый. Күренекле әдәбиятчы Габдрахман Сәгъдинең Абай турында казакъ һәм үзбәк телләрендә берничә мәкаләсе чыгуы билгеле. Кызганыч ки, татар һәм кайбер башка төрки телләрдәге бу төр материаллар безнең галимнәр тарафыннан әле тиешенчә барланмаган һәм өйрәнелмәгән.

Татар һәм өлешчә төрки басма сүз тарихын җентекле тикшергән Әбрар Кәримуллин фикеренчә, «казакъ китабының Октябрь революциясенә кадәрге үсеш тарихы турыдан-туры татар басма тарихына бәйләнгән» [12:102-109]. Бу чорда дөнья күргән 509 казакъ китабының зур өлеше Казан, Оренбург, Уфа, Петербург, Әстерхан калаларындагы татар наширлары тарафыннан чыгарылган. Бу китаплар арасында төп урынны фольклор әсәрләре, педагогик һәм матур әдәбият тәшкил итә. Тәрҗемәләр, шул исәптән татарчадан күчерелгән басмалар да шактый. Арада татар теле аша тәрҗемә ителгән Пушкин, Крылов һ.б. авторларның әсәрләре дә бар.

Абай әсәрләренең кайберләре моннан йөз еллар элек үк татарчага тәрҗемә ителә, төрле басмаларда дөнья күрә башлый. Әмма олуг акын шигырьләре аерым китап рәвешендә чагыштырмача соңрак – 1947 елда гына нәшер ителә. Бу җыентык шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңае белән әзерләнә. Китапка Абайның 40 шигыре, «Мәсгуд», «Искәндәр» поэмалары кертелә. Аларның барысы да җыентыкны төзүче, шагыйрь һәм прозаик Мәхмүд Максуд тарафыннан тәрҗемә ителгән. «Казакъ халкының бөек улы» дип исемләнгән кереш мәкаләсендә (3-6 битләр) М.Максуд Абайның тормышы, әсәрләренең идея-тематикасы, сәнгати үзенчәлекләре хакында да аерым мәгълүматлар китерә. *«Абайдан элек, – ди ул, – казакъ шигырь төзелеше ике генә форманы белә иде: һәр юлы 11 иҗекле булып, 4 юллы строфалардан торган шигырь формасы һәм һәр юлы 4 иҗекле булып, юл исәбе буенча строфаларга бүленмәгән шигырь формасы. Абай шуларны оста файдалану белән беррәттән, шигырь төзелешендә яңадан 11 төрле форма барлыкка китерә»*. Китапның сыйфатлы чыгуына аның мөхәррире Кави Нәҗми булу да уңай йогынты ясагандыр. Чөнки бу күренекле әдип гомеренең бер өлешен Актүбә шәһәрендә уздыра, казакъ телен, әдәбиятын, Абай иҗатын яхшы белә, Мохтар Әүезов белән дә еш аралашып тора.

1981 елда татар телендә бөек акын әсәрләренең чагыштырмача тулы басмасы дөнья күрә. Аңа шагыйрьнең 134 шигыре, 2 поэмасы, «Хикмәтле сүз»е

кертелгән (урыс теленнән тәрҗемәләре китапта урын алмаган). Шигырьләрнең 69ын Нури Арслан, 15ен Әхмәт Исхак, 15ен Марс Шабаев, 5сен Мәхмүд Хөсәен тәрҗемә иткән. Ике поэма һәм 16 шигырь М.Максуд чыгарган китаптан алынган. Тәрҗемәчеләрнең барысы да тәҗрибәле, талантлы әдипләр. Н.Арслан һәм М.Хөсәен – чыгышлары белән Казакъстанның Петропавловск (Кызылъяр) төбәгеннән. Икесе дә казакъ телен, әдәбиятын, бу халыкның гореф-гадәтләрен яхшы белгән. Мин әлеге җыентыктагы аерым шигырьләрне аларның оригиналы белән чагыштырып карадым. Тәрҗемәчеләр казакъча текстның эчтәлек-мәгънәсен генә түгел, шигъри үзенчәлекләрен дә татар теле чаралары белән чагыштырмача тулы бирергә омтылганнар. Бу хакта китапка кереш сүз язган Сибгат ага Хәким дә искәртә. Ул казакъ сүз сәнгате, аның үткәне, бүгенгесе, шулай ук Абай әсәрләренең кыйммәте хакында да кызыклы фикерләр әйтә: *«Абай күңеле, – ди ул, – казакъ халкының иксез-чиксез далага түгелгән зарын-моңын җыйган... Әйтерсең, берүзе казакъ халкының бөек Рухын формалаштыруны үз өстенә алган,* – дип яза, – аннары үз фикерен болай дип дәвам итә. – *Абай кайдадыр далада еракта калмады, бүгенге казакъ әдәбиятының колачы, масштабы – Абай колачы, Абай масштабы. Абайның киләчәккә карап әйткән юллары менә нинди:*

Ышанычлы дустым да юк, якыным да,
Шуңа күз яшьләрем әйләнделәр җырга,
Күрдем керләнмәгән күңел яктысында
Моңа кадәр күрелмәгән гаҗәп дөнья.
*(**Нури Арслан** тәрҗемәсе) [8:5-10]»*

Абайның татарча тәрҗемәләре, бу ике җыентыктан тыш та, төрле гәҗит-журналларында күренеп тора. Бөек акын әсәрләренең чагыштырмача тулы, заманча тәрҗемәләрен туплаган татарча җыентык чыгаруга бүгенге көндә ихтыяҗ зур.

IV

Абай – казакъ халкының һәм гомумән Казакъстанның даими юлдашы, фикердәше, остазы. Шагыйрь әсәрләре кардәшләребезнең күңеленә сеңгән. Абай исеме музей-һәйкәлләрдә, урам, оешма атамаларында мәңгеләштерелгән. Аңа багышлап йөзәрләгән сәнгать әсәрләре (әдәбият, музыка, рәсем, театр, кино) тудырылган, төрле телләрдә гыйльми-популяр хезмәтләр язылган. Шагыйрьнең туган көннәре, аеруча түгәрәк даталары, зур чаралар, чын бәйрәм рәвешендә билгеләп үтелә. Аларга еш кына татар әдипләре дә чакырылып тора. Абайның 170 еллыгы да шундыйлардан иде. Төп чаралар исә шагыйрьнең туган төбәгендә 2015 елның 5-7 августында үткәрелде.

Килгән кунаклар беренче көнне казакъ зыялылары белән очрашты. Икенче көнне әүвәл Шәкәрим исемендәге университетның актлар залында «Абай һәм дөнья цивилизациясе» темасына Халыкара фәнни-гамәли конференция булды. Пленар утырышта тәүге докладны миңа ясарга туры килде. Урыс телендә мин «Абай һәм татар әдәбияты» (дөресрәге, «...һәм татар дөньясы») темасын яктыртырга омтылдым.

Көннең икенче яртысында Семейдагы Абай исемендәге драма театрында бөек акынның тууына 170 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш һәм әдәби-музыкаль кичә булды. Зур зал шыгрым тулы иде. Казакъстанның дәүләт секретаре Гөлшара ханым Абдысаликова, министрлык вәкилләре, Көнчыгыш Казакъстан акиме Д.Әхмәтов, язучылар чыгыш ясады. Татарстан вәкиле сыйфа-

тында миңа да зурлап сүз бирделәр. Бу юлы мин, хуҗаларның үтенечен исәпкә алып, татарча сөйләдем. Казакъ-татар бәйләнешләре, шул контекстта Абай иҗаты, Семейдәге татар диаспорасы һәм кайбер башка мәсьәләләргә тукталдым. Казандагы үзәк урамнарның берсенә президент Нурсолтан Назарбаев исеме бирелүен телгә алдым. Усть-Каменогорск каласында патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл куюлары өчен татар җәмәгатьчелегенең рәхмәтен белдердем. Чыгышымны зал бик җылы кабул итте, берничә мәртәбә кул чабып котлады.

7 август көнне безне Абайның туган, яшәгән якларына алып киттеләр. Ул төбәкләр Семейдән 180 чакрымнар ераклыкта. Шәкәрим университеты проректоры Кумарбәк (Гомәрбәк) Әмирханов барысын да тәфсилле аңлатып, күрсәтеп йөрде. Рәхмәт үзенә!

Бөек акын гомер кичергән төбәктәге төрле чараларда гаять күп кеше катнашты. Әүвәл Абай районы үзәге Караулда тобыкты ыруы каһарманы – Мамай-батырга һәйкәл ачу тантанасы булды. Аннан Чыңгызтау итәгендә «Абай туе» дигән театральләштерелгән милли-этнографик тамаша, ат чабышлары оештырылды. Кунаклар өчен 50гә якын тирмә корылган иде. Шушы бәйрәм кысаларында милли көрәш, чичәннәр ярышы уздырылды. Боларның һәммәсе күңел ачуга гына түгел, ә милли рухны үстерүгә дә юнәлтелгән иде. Һәркайда – казакъ яшәеше, казакъ моңы, казакъ сөйләше.

Бераздан Караулдан ерак булмаган Җидебайга юнәлдек. Биредә Абайның музей-йорты урнашкан. Ул шагыйрьнең 150 еллыгына ачылган. Янә шунысын да искәртик: Абай – шактый бай, хәлле кеше булган. Музей-йорты, аның ихатасы да шуны күрсәтеп тора. Биредә дистәгә якын тематик зал бар: «Абай һәм аның чоры», «Җәйләү», «Абай иҗаты», «Шагыйрьнең иҗат даирәсе», «Абайтану» («Абаеведение»)... Музейда гаҗәеп күптөрле кыйммәтле экспонатлар тупланган. Җидебайдан бер-ике чакрым ераклыкта гына – Абайның төрбәсе. Ул да шагыйрьнең 150 еллыгына ачылган, ЮНЕСКО карары белән дөньякүләм кыйммәтле ядкярләр исемлегенә кертелгән.

Семейдәге өч көнем күз ачып йомганчы узды да китте. Бу вакыт вакыйгакичерешләргә шактый бай, тыгыз булды. Тугандаш казакъ халкының, Казакъстанның алга баруы, чын милли тормышын торгызуы мине сөендерде. Мондый сәфәрләр без татарларга гыйбрәт, сабак алу өчен дә бик файдалы, кирәк.

...Абай инде үзе күптәннән фаный дөньяда юк. Әмма аның җыр-үләңнәре бакый, алар миллионлаган укучыларны дулкынландыра, яшәеш-тереклеккә дәртләндерә.

Әдәбият

1. Журнал «Я люблю Семей». – 2015. – №5. – С.16-17.
2. Татары в Казахстане: энциклопедический словарь / Под редак. проф. Г.Т.Хайруллина. – Алматы: ИД «Мир», 2011. – 219 с.
3. Татарская энциклопедия. Т.5. – К., 2010. – 736 с.
4. Абай Кунанбаев. Шыгармалар. – Алматы: «Жазушы» басмасы, 1988. – II т. – 251 б.
7. Хатыйп Миңнегулов. Мохтар Әүезов һәм татар әдәбияты / «Дөньяда сүземез бар...» – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 281-295 б.
8. Абай. Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз. / Төзүчесе Л.Хәмидуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – 256 б.
9. Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр. 8 томда. V том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 625 б.
10. Габдулла Тукай. Әсәрләр. Дүрт томда. III том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 447 б.
11. Шәехзадә Бабич. Зәңгәр җырлар. Шигырьләр, поэмалар, мәкаләләр, хатлар / Төзүчесе Галимҗан Гыйльманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 544 б.
12. Әбрар Кәримуллин. Казакъ телендәге басмалар / Китап дөньясына сәяхәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 208 б.

«Кайчак күңел арынмак кайгы-хәсрәттән...»

Абай Кунанбаев

ӘЛИФБА ҖЫРЫ[1]

Әлиф – айдай йөзләреңне үрнәк иттем,
Би – бихисап сагышыма нисбәт иттем,
Ти – телемнән чыгарып мин төрле җырлар,
Си – сине мактадым, җаным, хөрмәт иттем.
Җим – җәмалең[2] нинди якты, кояш кебек,
Хә – хәләллек табалмадым сине күреп.
Ха – халыклар мактый сине, бер мин түгел,
Дәл – дәрига[3], мәхәббәттән янам көеп.
Зәл – зәлиллек[4] күрдең, инде сайра, телем.
Ра – ризалат ризалатсаң, асыл гөлем.
За – зәһәрдәй үтте җанга сөю уты,
Син – сәламәт калуларым мөшкел минем.
Шин – шикәрдәй иренең искә төшсә әгәр,
Сат – сабырлар калмый тәндә, юк бер әмәл.
Зат – заяга үтте гомер, бик кызганыч,
Та – таләп кыл, үткәрмә син көнне әрәм.
За – залимнар дәһшәт сала – кылыч ала:
Гайын – гакыл тетри, зиһен-уй тарала.
Гъаен – гарип башкаема килде бәла.
Фа – файдаң бер тиярме дип, җәзалама.
Каф – кабул ит, ал, сөеклем, язган хатым,
Кяф – камилдер акылың синең, асыл затым.
Ләм – ләбеңдә[5] тибрәтсәң, аһ, бер генә сүз,
Мим – миһербаның юк итә бар афәтем.
Нон – наләле[6] кылдың ягып утларга тик,
Вау – вәйлагә[7] салдың мине син болай ник?
Һа – һич чараң булмый икән, ил дип кайгыр,
Ләм – әлиф, ля иляһә илләлла, дип,
Йа – яргынам, керфекләрең тәштит төсле,
Кашларың мәт, нәкъ сәкендер[8] ике күзең.
Өтер дә бар, нокта да бар аслы-өсле,
Булыйк без дә аслы-өсле... күнсәң үзең!

***Нури Арслан** тәрҗемәсе*

[1] Шигырьнең һәр юлы гарәп алфавитындагы хәреф иселе белән башлана.

[2] Җәмалең – йөзең.

[3] Дәрига – ни үкенеч.

[4] Зәлиллек – кадерсезлек.

[5] Ләб – ирен.

[6] Наләле – яшьле күзле, газаплы.

[7] Ва вәйла! – Ни үкенеч!

[8] Тәштит, мәт, сәкен – гарәп сүзләрен дөрес укыр өчен куела торган билгеләр.

***

Ак көмештәй коеп куйган киң маңгае,
Кара күзләрнең йолдыздай нурланганы,
Кара кашлар кыйгач кына сызып куйган,
Хәтерләтә яңа туып килгән айны.
Маңгаеннан туры төшкән нәфис борын,
Аксыл чырай, ал-кызыл битләр алмалы,
Иренен ачса – тезеп куйган ак тешләре,
Күрү белән җанда дәртнең кайнаулары!
Сөйләр сүзе әдәпле дә, мәгънәле дә,
Көлүендә – сандугачның сайраулары.
Түп-түгәрәк ак ефәктәй ап-ак муен,
Йомшак ияк асты, – ала күз яуларын.
Калак сөякләре – канат, иңнәре төз,
Күкрәгендә пар алманың уйнаулары.
Буе-сыны озын түгел, кыска түгел,
Нечкә биле тал-чыбыктай сыгылмалы.
Беләкләре яшь баланың тәнедәй саф,
Бармаклары нәзек, төрле эшкә җайлы.
Таралып, дулкынланып иңгә төшкән
Кара чәче хәтерләтә ефәк талны.

Нури Арслан *тәрҗемәсе*

КӨЗ

Соры, салкын болытлар күккә аша,
Көз җитеп, дымлы томан җирне баса.
Белмим нигә, әллә туеп, әллә туңып
Елкы уйный: тай ярыша, бия кача?

Элеккедәй яшеллек юк, җәйләр үткән,
Шаулашмыйлар яшьләр: уен-көлке беткән.
Хәерче карчык кебек төсе китеп,
Агачлар яфракларын койган күптән.

Берәү ачыткы болгата, китереп иен,
Өстендә кеше биргән ертык кием.
Каенанага ияреп яшь хатыннар
Йон җеп белән ямыйлар ертык өен.

Каз-торна күтәрелә үзән-күлдән,
Юлдан ашлык төяп кайта дөя-кәрван,
Кай авылга карама – бик ямансу,
Уен-көлке юк, бөтен җир сүлпе-сүрән.

Бөрешкәннәр бала-чага, карт-корылар,
Күңелсез кара суык һәр урында;

Сөяк-санак, шулпа-фәлән эләкмәгәч,
Эт тә юк, тычкан аулап йөри кырда.

Көзләү[9] тузган, ут алмыйлар тирә-якта,
Тузан-туфрак купмый, томан җиргә яткан,
Ыстан куркып ягылмаган учаксыз өй, –
Казагым кайчан арыныр бу халәттән?!

[9] Көзләү – казакъ авылының кышлауга күчмәгән чагы.

***Нури Арслан** тәрҗемәсе*

***

Авыру йөрәк сугадыр бик әкрен, җай.
Йончып калган гәүдәне һич тота алмый.
Кайчак кайнар кан бәрәдер бөтен тәнгә,
Шомлы шундый төндә мине йокы алмый.

Кара кайгы хәзер минем уйны җиңгән,
Иркә хисне, дуслык хисен җиңәр тиздән.
Акылы юк, намусы юк буш куыклар...
Көн дә күреп, җык булганмын, җирәнелгән.

Терелтеп үткән көннәрне, шатлык эзләп,
Ул көннәрне, көн димичә, каргап-тиргәп,
Кайчак тели, эзли күңел тынычлыкны,
Кайчак яна, кайгы-газапларны күзләп.

Кайчак күңел арынмак кайгы-хәсрәттән,
Татымак ул татлы хыял, кайнар дәрттән,
Әмма теләген яшерә, ил-йорт сизәр,
Биткә кызыллык килер, дип гарьлекләрдән.

Авыру йөрәк сугадыр бик әкрен, җай,
Дәрт-дәрманын эчкә җыйган, әйтә алмый.
Кайчак кайнар кан бәрә дә бөтен тәнгә,
Курка йөрәк, тынып кала, өн чыгармый.

***Марс Шабаев** тәрҗемәсе*

***

Тел – сөяксез,
Ни сөйләмәс
Тыңлатып башкаларны.
Кыек сүзне
Туры итеп
Үзеңчә аңла бары.

Үкенмә һич
Ялгыштым, дип –
Уяу күңелең сер булсын.
Бу дөньяда
Тап шундый дус,
Уе-сүзе бер булсын.

***Әхмәт Рәшит** тәрҗемәсе*

***

УНБИШЕНЧЕ СҮЗ[10]

Акыллы кеше белән акылсыз кеше арасында, минем белүемчә, бер генә аерма бар. Адәм баласы, яратылганнан соң, дөньяда күп нәрсәгә ихлас бирә. Тик, нәрсә беләндер мавыгып, кызыгып яшәгән кеше генә соңыннан үкенеч кичермәячәк. Чөнки аның үткән гомеренең иң онытылмас, искә алырлык чоры булып шул эзләнгән, мавыгып яшәгән чоры булачак, ул шуны һаман саен күңеленнән кичереп, сөенеп яшәячәк.

Әгәр дә инде кеше тормышта үз урынын тапмый, теләсә кемгә ияреп, бер бәһасез юк нәрсәләр белән кызыгып, комарланып яшәсә, гомеренең иң кыйммәтле, гайрәтле чагын юк-барга әрәм-шәрәм итсә – калган көнен үкенечтә уздырасы билгеле. Тик аннан ни файда? Үткән гомерне үкенеп кенә төзәтеп булмый. Яшьлегендә кызык артыннан кызык эзләп йөргән, бер генә эш-шөгыльгә дә ныклап күңел бирмәгән, яшьлеге мәңге узмас, буыны мәңге тузмас-какшамас итеп яшәгәннәр тиз картаялар. Андыйларның буыны тиз сыгылучан, терәксез була.

Чиксез мавыгучанлык та кайчакта чиргә әверелергә мөмкин. Чама белән булганда гына һәр хирыслык файдага. Берәр нәрсә белән артык мавыгу, артык хирыска бирелү кешене исертү хәленә китерергә, белештермәс итәргә ихтимал. Исәрлеккә тиң исереклек дип була аны. Ә инде бу хәлатендә кеше башкаларга көлке күренә, аның уңышы башкаларны кызыктырмый башлый. Чөнки бу хәлендә мавыгучан кешенең акыл күзе бәйләнеп куелган, ә карап, күреп торучылар аек акылда булалар. Һичбервакыт акыл җуярлык булып мавыкмаска, сынатмаска, хурлыкка калмаска кирәк. Аек фикерле кешеләр бер вакытта да алай онытылып китмәс, үз алларына куйган максатка сынатмый, акылны кулдан ычкындырмый гына барыр һәм эзләнерләр.

Андый исәр кешене мин иярсез ат өстендә, аның да койрык төбендә үк утырып барган, кая чапканын да чамаламый, башын югары күтәреп, шашып, һаман да атын куалаган бер җан иясе итеп күз алдыма китерәм.

Әгәр дә син акыллы, аек фикерле кешеләр рәтендә булыйм, дисәң, көненә бер, һич югы атнага бер, инде алай да булдыра алмасаң, айга-елга бер мәртәбә булса да үзеңнең ни эшләгәнеңне, нинди максат белән яшәгәнеңне исәпләп, искә ала торган бул. Соңгы кат нәтиҗә ясаганнан соң узган гомереңне ничегрәк үткәрдең икән, нәрсәләргә ирешкәнсең, ни белем өстәгәнсең икән – шуны чамалап яңа нәтиҗә ясa. Ул дәвереңяхшы эшләр белән, дөньяга яраклы шөгыль белән узганмы? Заяга китмәгәнме? Шуларны аерырлык, танырлык булсаң гына, танып та, шуңа омтылырлык булсаң гына син акылсызлар сафына басмассың. ■

[10] «Кара сөз» («Хикмәтле сүз») тупламасыннан.

«Мирас», №2, 1999 ел

Галим, көрәшче, милләтпәрвәр

Мөсәгыйт Хәбибуллин,
язучы, шәрәфле академик,
Кол Гали исемендәге халыкара премия лауреаты

Татар милли әдәбиятының кай чорда дөнья мәйданына чыгуы хакында шактый мәгълүматлар бар. Хак тәгаләсе шулдыр, буш урында тумаган ул. Борынгырак китеп тәгаенләсәк, борынгы римлəннәр, гәрчә дөнья кендеге булып торсалар һәм мәшһүр галимнәре белән безгә кадәр килеп җиткән грекларны буйсындырган булсалар да, әүвәл башта грек графикасы белән грек телендә язганнар.

Флүн Мусин фәнгә юл тотучы шәкертләре – аспирантлары белән. 17 декабрь, 1995 ел

Әлбәттә инде этруск, исаврәй һәм башка бик күп халыклардан оешкан римлəннәрнең күбесе грек телен белмәгән, грек телендә укымаган, шуның өчен ошбу телдәге әдәбиятка да массакүләм игътибар итү булмаган. Шуннан, бары тик шуннан гына империя түрәләре белән гади халык арасында аңлашылмаучылык туган, шушы аерма үскәннән-үсә барып, ниһаять, гасырлар үтә-үтә, куәтле империяне тарка-

туга китергән. Җирле халыкның туган телендә, ягъни ана телендә язуы Ауропада нигездә XIII-XIV гасырларда француз телендә әсәрләр язудан башлана. Мисалга Марко Поло сәяхәтнамәләрен китерергә була. Соңрак француз телендәге әсәрләрнең тәрҗемәсе итальяннарга һәм испаннарга да ирешә. Ә менә бүген дөньяны шаулаткан инглиз һәм немец телендәге әдәби әсәрләр бары тик XVIII-XIX гасырларда гына латин графикасында дөнья укучысына тарала башлый. Русиядә исә әдәби әсәргә нигезне XVI гасырда Иван Грозный салган, дип расларга тырышалар. Әйтик, Русия югары уку йортлары өчен чыгарылган дәреслектә беренче булып Иван Грозный исеме тора, гәрчә ошбу адәми зат бер генә әдәби әсәр язмаса да. Хәер, Русиядә әдәбият һәр чорда да сәяси роль уйнады, моңа бер дә шаккатасы юк.

Ә менә татар әдәбияты Идел буе Болгарында Ауропа белән бер чорда аякланып китә диярлек. Моны үзенең «Тел – милләт сакчысы» дигән хезмәтендә академик, галим Әбрар Кәримуллин да раслый. *«Болгар китаплары сакланып калмасалар да,* – ди ул, – *ул чорда (ягъни XIII гасырда) иҗат ителгән әсәрләрнең кайбер күчермәләре әле дә исәннәр. «Кыйссаи Йосыф», «Кисекбаш», «Бәдәвам» кебек әсәрләр шул чордан калган».* (Казан, Тат. кит. нәшр., 1997 ел.) Алтын Урда чорында иҗат ителгән әсәрләрне дә болгар-татарныкы, дип әйтергә тулы хакыбыз бар. Чөнки Алтын Урда империясенең төп теле татар теле була. Әмма 1552 елда безнең күп кенә тарихи әсәрләребез баскынчылар тарафыннан «вандализм»га дучар ителә. Бу вәхшилектән татар халкы бик күп еллар аякланып китә алмый интегә. Нинди хикмәтле тәңгәллек: татар әдәбияты XVI гасырда Русия империясе канаты астында калса да нәкъ менә Ауропада инглиз һәм немец телләрендә туган әдәбият чорында янә бер яңарыш кичерә. Моңа мисал итеп Хисаметдин Мөслиминең XVII-XVIII гасырларда иҗат ителгән «Тәварихи Болгария» һәм Утыз Имәни әсәрләрен китерергә була.

Иллә дә мәгәр, миңа калса, татар әдәбияты үзенең тулы булмаса да асыл көченә XIX гасырда керә. Нәкъ менә бу чорда татар әдәбиятында янә бер яңарыш чоры башлана. Русь һәм Ауропа халыклары телләреннән, бигрәк тә революциядән соң, күренекле әдипләрнең әдәби әсәрләре татарчага тәрҗемә ителеп, берсе артыннан берсе басылып, татар укучысына җиткерелә. Бу хәрәкәткә хәтта кат-кат алфавит алыштырып тору да комачауламый. (Латин графикасына көчүдән котлары алынган татар зыялыларына искәртү өчен әйтәм мин моны.) Ә инде алтмышынчы, җитмешенче елларда чит телләрдәге әдәбиятны татар теленә тәрҗемә итеп укучыларга җиткерү үзенең апогеясенә җитә.

Нәкъ менә шул елларда татар әдәбиятына яңача фикер йөртүче тәнкыйтьче, әдәбият галиме Флүн Мусин килә. Татарстанның Мөслим районында туа ул. Күрше Күбәк авылы мәктәбендә ун классны тәмамлый. Шуннан соң Флүн Мослах улы татар телендә белем алган балаларга хас булмаган тәвәккәллек кыла. Әтисе Бөек Ватан сугышыннан кайтмыйча ятим калган һәм әнисе кул астында сугыш елларын ачлы-туклы үткәргән Флүн Мусин данлыклы М.В.Ломоносов исемендәге университетның филология факультетына керергә дип Мәскәүгә юнәлә. Әнисе аны барлы-юклы акчасы белән паспортсыз, кулындагы таныклыгы белән генә озатып кала. Хикмәт, әнә шул ипи-тозлык кына рус телен белгән татар малае 1957 елда университетны уңышлы тәмамлый һәм туптуры Казанга кайта, «Социалистик Татарстан» газетасына эшкә керә. Мин Флүн Мусинның изге адымын бүген балаларын татар телендәге мәктәпләргә бирергә курыккан, урыс телендә укы-

магач, надан калырлар – көтүчедән ары китә алмаслар, дип өннәре алынган ата-аналарга да мисал итеп күрсәтер идем. Тырышкан – табар, ташка кадак кагар, ди татар халкы. Флүн Мусин, урыс телендәге мәктәпләрне тәмамлап, урам себереп йөргән яшьтиләрен шаккатырып, 1970 елда филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсен алса, 1983 елда исә Мәскәүдәге А.М.Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институтында докторлык диссертациясен яклый. Ә 1995 елда Россия гуманитар фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана, профессор дәрәҗәсенә ирешә.

Шунысы гаҗәп, Флүн Мусин тәнкыйтьче буларак үзенең жанрына беркайчан да хыянәт итми. Ул нәкъ менә алтмышынчы елларда тәнкыйтькә килә, бу, әйтергә кирәк, татар әдәбиятының яшь тәнкыйтьчеләргә кытлык кичергән чагы. Башта ул чордашлары арасыннан аеруча аерылып торган әдипләрнең әсәрләренә бәһа бирә, тәнкыйтьче буларак теге йә бу әдипнең иҗатына укучы игътибарын юнәлтә. «Бүгенге әдәбиятыбыз турында» дигән коллектив хезмәт шушы эзләнүләрнең тәүгеседер, мөгаен. Ары таба Флүн Мусин инде мөстәкыйль рәвештә «Тормыш сынавы аша» дигән хезмәте белән сайлаган жанрына карата күңелен тагын да ныгыта, ә инде «Тарих һәм заман», «Тарих һәм заман чагылышы», «Чор белән аваздаш» кебек хезмәтләрен укучысына ирештергәч, дөрес юл сайлавына янә бер инана. Укучым, искәрсәң булса кирәк, Флүн Мусин үзенең хезмәтләрендә «тарих» сүзен шактый еш кабатлый. Бу тикмәгә генә түгел. Чөнки аны татар халкының борынгы әдәбияты язмышы борчый башлый. Егерменче еллар, совет чоры әдәбияты, төрки халкының ташка уелган бик борынгы әсәрләре күңел кылына кагылып-кагылып китә.

Ниһаять, ул үзенә конкрет тема сайлый, күңел кыйбласын ачыклый. Күңеле белән ул татар халкының революциягә кадәр үк патша империясе тарафыннан рәнҗетелгән, эзәрлекләнгән, зинданнарга ташланган, шуңа карамастан, бер генә мизгелгә дә милли хәрәкәт көрәшен ташламаган, ә революциядән соң чит илгә качып китәргә мәҗбүр булган мәшһүр язучы Гаяз Исхакый иҗатына туктала. Әйтергә кирәк, Гаяз Исхакый иҗатын вә мирасын Ватанга кайтару юлында соңгы сулышына кадәр эшләгән профессор Ибраһим Нуруллин хезмәтләрен дә искә алып, үзенә күрә авыр эшкә керешә. Берүзе генә түгел, дистәләрчә кеше эшли бу юнәлештә. Кемгә дә сер түгел, совет чорында, хәтта сиксәненче елларда да, әдипләрне бер идеологиягә – коммунизм төзүгә юнәлткәннәр иде. Һәм ниндидер бер мифик совет кешесен тудыру иде максатлары. Империя башында торган коммунистлар, бу юнәлештәге максатларын тормышка ашыру өчен бернәрсә дә кызганмадылар – акчаларын да, юха телләрен дә, атаклы исемнәрен дә, хәтта адәм баласы ахирәттә генә күрергә хаклы булган коммунизм гүзәллеген дә мулдан мактадылар, менә-менә була, менә-менә коммунизм таңы ата, дип көн-төн тукып тордылар. Ә ипекәйгә, майга-иткә, шикәргә чират бетмәде, өскә кияргә җүнле киемнәре булмады. Тик һәр чорда да ялган һәрчак ялган булып калды һәм шулай бәяләнде дә. Бары тик бер халыкка гына бөтен хокукны биреп, калганнарын «нацмен» дип атап, Русиядәге бар халыкны да урыс телендә генә сөйләшергә мәҗбүр иттеләр. Әмма сиксәненче елларда коммунистлар үзләре үк коммунизмның мәңге булмас бер хыял булып калуына инандылар. Алар, бигрәк тә түрәләр кисәк кенә үз мәнфәгатьләрен кайгырта башладылар.

Нәкъ шул елларда комсызлыкка багышланган әдәби әсәрләр туа башлады. Һәм әлеге әсәрләрне беренче булып тәнкыйтьче Флүн Мусин күреп алды,

дисәм, һич тә хата булмастыр. Ул гынамы, әсәрләре илгә кайткан Гаяз Исхакый мирасын чыгару, укучыга җиткерү башланды. Гаяз Исхакый, тарихи шәхес буларак, Ил-Ватанга үзе кайта алмады, әмма иҗаты кайтты. 58дән артык исемнән торган шактый күләмле әсәрләрне халыкка җиткерү кирәк иде. Шул ук вакытта тикшерүләр алып барырга да. Бу эшкә, башкалар белән бергә, галим Флүн Мусин да алына. Һәм 1998 елда, мәшһүр язучының әсәрләренә карата катгый фикерен әйтеп, Татарстан китап нәшриятында «Гаяз Исхакый (тормышы һәм эшчәнлеге)» дигән монографиясен бастырып чыгара. Хак, совет чорында милли зыялылардан бер Гаяз Исхакый гына корбан булмады, алар күп иде. Әмма нәкъ менә Гаяз Исхакый үзенең иҗатында татар халкының империя кулы астында иза чигүен, аның ачы вә авыр язмышын сурәтләүгә, бөтен иҗатын дияргә була, багышлый.

Филология гыйлеме өлкәсенә тәнкыйтьче булып килеп кергән Флүн Мусинга, тарихи әсәрләр язучы буларак, минем бер үтенеч вә теләгем бар. Хак, аңа инде алтмыш яшь. Ләкин, миңа калса, әле аның иң зирәк чагы, иң сәләтле вакыты. Тәнкыйтьче, галим кеше тәҗрибәле, шул ук вакытта зыялы, күп нәрсәдән хәбәрдар, сизгер һәм аек акылга ия кеше булырга тиеш. Ул иң әүвәл үзе тикшергән әдәби әсәрне рухи «азык» итеп, көмеш табакка салып, укучыга тапшыра. Укучы исә, аның әсәрен бәһаләве аша ул ризыкның тәмен тоеп, үзенең акылына кирәк «ризык» икәненә инана. Бер сүз белән әйткәндә, тәнкыйтьче укучыга теге йә бу әсәрнең йогынтысын, зарурилыгын ачыклый. Әлбәттә, укучы әсәргә үзе дә бик әйбәт бәһа бирә ала, чөнки адәми зат өчен тәм һәм ямьгә ишләр юк, диләр. Шуңа карамастан, тәнкыйтьче әсәрдәге әдип әйтергә теләгән фикерне укучыга ачыкларга ярдәм итә. Бит укучы укыган әсәргә субъектив бәһа бирә, тәнкыйтьче исә әсәрне аңа объектив яктан килеп аңлата һәм әсәрдәге хакыйкатьне ачып сала. Кыскасы, тәнкыйтьче укучының эстетик үсешенә уңай яктан тәэсир итә. Флүн Мусинда, тәнкыйтьче буларак, әнә шул сәләт бар иде. Иде, дим шуның өчен, чөнки ул соңгы елларда гыйльми эшләргә башыннан чумып, әдәби хәрәкәткә азрак игътибар итә башлады, гәрчә бу өлкәдә саллы гына мәкаләләре күренгәләсә дә. Минем фикеремчә, хакыйкатьне эзләгән кешегә бүгенге прозада да яңалыклар тулып ята, аны бары тик күрә белергә генә кирәк. Ә Флүн Мусинны бу сәләттән Ходабыз мәхрүм итмәгән, шөкер кыласы гына кала.

Безнең каһарман бабаларыбыз батырлыклары хакындагы әсәрләр шактый күренә башлады. Әмма җиңел куллы көндәлек матбугат, радио һәм телевидение, кайбер урыс язучылары, аеруча бары тик бер халык тарихын гына укып тәрбияләнгән журналистлар һәм галимнәр татарларны әле булса каһәрләүдән туктый алмыйлар. Ә аларның «явын» туктату өчен чын тарихның асыл йөзен ачып, бар булган әсәрләрне тәнкыйди күзлектән уздырырга кирәк. Бу эшкә галимнәребезнең дә, тәнкыйтьчеләребезнең дә әллә ни зурдан кубып керешкәннәре юк әле. Әллә тәүге куркудан арына алмыйлар, әллә үз көчләренә ышанып җитмиләр.

Ә менә бу миссиягә галим һәм тәнкыйтьче Флүн Мусин алына алыр иде. Чөнки аңа Хода барысын да биргән: сәләтне дә, исәнлекне дә, хатын-кызларның күзе төшәрлек кыяфәтне дә, иң мөһиме – аксакалларга хас акылны.

Ары таба зур уңышлар телим сиңа, чордаш. Кулыңнан алтын уклы каләмең төшмәсен. Ә мин синең кулыңдагы каләмнең нәрсәгә сәләтле икәнен беләм. Беләм, ышанам, көтәм һәм өмет итәм. ■

Бер рәсем тарихы

Дания Фәйзуллина

Быел сеңлемнең 1 нче сыйныфта укучы кызы Камилә, нәни кулларына Миңнегәрәй бабайның зурайтылган фотосурәтен күтәреп, Җиңү Парадында «Үлемсез полк»та катнашты. Бабамның һәм сугышта һәлак булган бик күпләрнең рухлары шат булгандыр. Миңа алар бар да исән, янә бер сафта, бердәм булып атлыйлар төсле тоелды. Күңелләр нечкәрде, күзләргә яшь тулды.

Бәйрәм узганга да инде 5 ай вакыт үтте. Сеңлемнең фатирына килгән саен, мин әнә шул фотосурәткә карыйм да әбием сөйләгән хатирәләрне барлыйм.

Бабам 1916 елның 11 сентябрендә Яшел Үзән районының Норлат авылында туа. Коточкыч сугыш афәте алар капкасын да шакый. Абыйлы-энеле Кәбир, Миңнегәрәй һәм Хәйдәр сугышка китә.

Шөкер, Хәйдәр сугыштан исән-сау әйләнеп кайта. Миңнегәрәй белән Кәбир исә яу кырында мәңгелеккә ятып кала.

Бабам 1941 елның 17 декабрендә Норлат (хәзерге Яшел Үзән) районы Хәрби комиссариатыннан 54 нче гвардия дивизиясенең өлкән лейтенанты буларак мобилизацияләнә.

Сугышның барлык авырлыкларын кичеп, җиңү сәгатьләре якынлашкан мәлдә, 1945 елның 5 маенда бабамның Берлин кырында хәбәрсез югалуы бик аяныч. Күңеле сизгәндер, күрәсең, юкса шундый каты сугышлар барганда соңгы хатын сөекле Зәйнәбенә юллый алыр идеме икән...

«Зәйнәп, исәнме! Ком бураны ничек оча, монда бар да шулай оча. Уң кулыма осколок керде, сул кулым белән язам. Соңгы дивизиямне алып чыгып киттем, күрешмәсәк, бәхил бул. Балаларны сакла. Миңнегәрәй. 1945 ел, 5 май». Кызганыч, бу хат бездә сакланмаган, әбиемнең хәтерендә, күңелендә аның эчтәлеге мәңгегә уелып калган. Ә менә бабамның берданбер фотосурәтен без кадерләп саклыйбыз. Ул безгә, үткәннәрдән кайтаваз булып, яулап алынган җиңүнең кадерен белергә, киләчәк буыннарны бабаларыбызның кылган батырлыкларын онытмаска, мәңге хәтердә сакларга өнди кебек.

РЕДАКЦИЯДӘН: *Хөрмәтле укучыбыз!* ***«Бер рәсем тарихы»н*** *конкурска әверелдерәбез. Ярты ел саен нәтиҗәсен чыгарып, җиңүчеләрне билгеләп барачакбыз. Шартлары: бер рәсем, аның тарихы язмача бер биттән артмаска тиеш, «Безнең мирас» журналына ярты елга язылганлыкка квитанция күчермәсе булу зарур.*

Милләт хадиме

Нәҗип Нәккаш*

Узган гасырның 80 нче еллар уртасында СССРда башланган үзгәрешләр, бу зур илнең шулвакыттагы җитәкчесе М.С.Горбачёвның «үзгәртеп кору» дип аталган идеология, сәясәт, икътисад һәм иҗтимагый тормыш өлкәләрендәге реформалары нәтиҗәсендә, демократия, хәбәрдарлык, сүз иреге җилләре исә башлау белән, татар милләтенә дә үзенең күп гасырлар тоткан ислам диненә кайтырга, гаҗәеп бай мәдәни мирасын өйрәнергә, дөньяга чыгарырга мөмкинлек туды.

90 нчы еллар башында бер-бер артлы яңа газеталар – «Татар иле», «Мәдәни җомга», «Татарстан хәбәрләре», «Шәһри Казан» кебекләр; «Идел», «Мирас», «Салават күпере», «Сәхнә», «Казан» кебек журналлар пәйда булды. Журналистларга, шагыйрь-әдип вә һәм галимнәргә, сәясәт әһелләренә хәлкадәри мөмкинлекләрен эшкә җигәргә, әсәрләрен, мәкалә-язмаларын мәйданга чыгарырга юл ачылды.

1991 елда, инде күптән зарыгып көтелгән «Мирас» журналының чыга башлавы белән, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Казан дәүләт университетының татар филологиясе факультеты галимнәренә, укытучыларына үзләренең гыйльми

РЕД: *Н.Нәккаш – борынгы татар әдәбияты белгече, рәссам-хаттат, быел Татарстан Республикасының олуг бүләгенә – Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. Журналыбызның актив авторын чын күңелдән котлыйбыз!*

Мәҗит Гафуриның тууына 100 ел тулуга багышланган фәнни конференция. Арткы рәттә (уртада) – Һәнүз Мәхмүтов. Казан, 16 июнь, 1980 ел

тикшеренүләре процессында җыелып килгән, әмма совет чорында төрле идеологик, сәяси басымнар аркасында дөнья күрми яткан хезмәтләрен бастырырга, халыкка җиткерергә җай чыкты.

Безнең Г.Ибраһимов исемендәге институтның кайбер галимнәре исә, мәсәлән, әдәбият белеме бүлеге хезмәткәре Әнвәр Хәйри, фольклор бүлегеннән Рәшит Ягъфәр, сәнгать бүлегеннән Һәнүз Мәхмүтов журналның гамәли хезмәткәрләре булып эшли башлады. Яңа журналны аякка бастыру, юлга салу, көчәйтү максатыннан, институтның шулвакыттагы директоры Мирфатих ага Зәкиев, аларның төп эшләренә зыян килер, дип куркып тормады, әлеге хезмәткәрләрнең иҗади кимәлләрен белеп, ике эштә берьюлы эшләргә мөмкинлек бирде.

Бу язмам – «Мирас» журналының беренче саннарыннан ук хезмәт куеп, аны югары дәрәҗәдәге сыйфатлы басма итү өчен күп көчен, бөтен сәләтен, тырышлыгын куйган Һәнүз абый Мәхмүтов турында.

Һәнүз абый белгечлеге буенча татар театры тарихын өйрәнүче, тикшерүче галим булса да, татарның бөтен мәдәнияте тарихын тирәнтен белүче, әдәбиятны, шигърияткне сөюче, үзе дә яшьрәк чагында шигырьләр иҗат иткән, сүзнең төмен, ямен, көен белгән югары эрудицияле шәхес иде. Редакциягә килеп кергән һәр мәкаләне, әсәрне җентекләп укып, кирәк булса – төзәтеп, тиешле дәрәҗәгә җиткереп, иренмичә эшли иде ул.

Һәнүз абый белән институтта эшли башлаган вакытымнан – 1979 елдан ук таныш идем. Мин институтта чыгып килә торган «Фәнни адым» исемле дивар газетасының бизәүче рәссамы сыйфатында катнашсам, Һәнүз абый шушы газетаның алыштыргысыз сәркатибе иде. Ә баш мөхәрриребез – гаҗәеп тирән акыллы, зыялы, нечкә юмор хисенә ия, сабыр-тыныч холыклы Равил әфәнде Әмирхан иде (кызга-

ныч ки, ул да ахирәткә вакытсыз күчте, гүр иясе булды...).

Һәнүз абый белгечлеге буенча татар театры тарихын өйрәнүче, тикшерүче галим булса да, татарның бөтен мәдәнияте тарихын тирәнтен белүче, әдәбиятны, шигъриятне сөюче, үзе дә яшьрәк чагында шигырьләр иҗат иткән, сүзнең тәмен, ямен, көен белгән югары эрудицияле шәхес иде. Редакциягә килеп кергән һәр мәкаләне, әсәрне җентекләп укып, кирәк булса – төзәтеп, тиешле дәрәҗәгә җиткереп, иренмичә эшли иде ул.

Һәнүз Котдус углы гомере буе китапханәләрдә, архивларда утырып, революциягә кадәр басылып чыккан гарәп шрифтындагы татар газеталарын, басма китапларын укып, өйрәнеп, күчереп алып, гаҗәеп зур мирас фонды булдырган иде.

Хәбәрдарлык, сүз ирегե заманнары килгәч, аның җыйган мәгълүматларына, материалларына юл ачылды. Ибраһим Нуруллин белән янәшәдә ул татарның совет чорында моңарчы тыелып килгән милли азатлык хәрәкәте идеологы, олуг әдип Гаяз Исхакыйны иң беренчеләрдән булып күтәреп чыгучылардан булды. «Мирас» журналының 2 нче санында (1992) Г.Исхакый турында Һәнүз абый болай язган: «...*Ялган тарихчылар, ялган философлар, әллә никадәр «акыллы башлар» мәтәлеп төштеләр, мәйданнан киттеләр, ә кыйбласы дөрес, иманы нык булган Исхакый, меңъяшәр карт имән кебек, үз урынында калды. 1916 нчы елда ук аны Фатих Әмирхан «сүнә белми торган ялкын» дип атаган иде. Милләткә хезмәт итү, аны азатлыкка чыгару идеясе белән көчәйтелеп торган әнә шул ялкын Исхакыйның бөтен гомеренә җитте. Нәтиҗәдә, ул «теге якта» да, туган илендә яшәгәндәге кебек үк, милләтебезгә файдалы, үлемсез эшләр башкарып, олы мирас калдырды*».

Бу сүзләрне Һәнүз абыйга карата да хаклы рәвештә әйтеп була. «Мирас»ның беренче санынннан ук, 1996 елның декабрендә кинәт кенә вафат булуына кадәр, ул анда әдәби мирас, әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып хезмәт куйды. Килеп кергән материалларны тиешле кимәлгә җиткәнче эшкәртеп, тәртипкә салып, авторлар белән тыгыз бәйләнештә торып, журналны кызыклы, файдалы, зәвыклы һәм укылышлы итү өчен бөтен көчен куйды. Үзенең дә театр тарихына кагылышлы өр-яңа мәкаләләре, ул әзерләгән Г.Исхакый һәм башка әдипләрнең, драматургларның әсәрләре басылып чыкты.

Эш аты иде ул. Хатыны Салиха ханым белән бер-берсен яратып, хөрмәт итешеп яшәделәр, әмма балалары булмады. Шуңадырмы, Һәнүз абый бөтен юанычын эштән тапкан, татар милләтенә хезмәт итү аның олы максаты булган.

Йомшак холыклы, кеше белән сүзгә килергә, бәхәсләшергә яратмый торган зат иде, шуңадырмы, аның тирәсендә йөрүчеләр, җитәкчеләр ул язган хезмәтләргә автордаш булалар иде. Бик күп җыелган әйберсе, тирән гыйлеме, яза белү сәләте булуга карамастан, шул тыйнаклыгы аркасында докторлык дәрәҗәсен дә якларга ашыкмады. Алга таба бәлки ул дәрәҗәләрне алу өчен талпыныш ясап караган да булыр иде, әмма аяусыз үлем аны якты дөньядан вакытсыз алып китте...

Бу көннәрдә – «Мирас»ның чирек гасырлык юбилее көннәрендә, аны юлга салучыларның берсе – Һәнүз абый Мәхмүтовны юксынып-сагынып, хөрмәт белән искә алабыз. ■

Энциклопедиягә тиң журнал

«Безнең мирас» журналының гыйбрәтле тарихы татар халкына мөстәкыйльлек китергән чордан, милли хәрәкәтнең көчәйгән көннәреннән башланды. «Мирас» исеме белән ачылган басманың беренче саны 1991 елның апрелендә дөнья күрде. Танырга кирәктер: егерме биш ел эчендә журнал Россиянең борынгыдан чыккан фәнни-популяр басмалары янәшәсенә басты. Аның бүгенгә кадәр туплаган архивы татар мөгаллимнәре, студентлары, галимнәре һәм белемгә омтылган меңләгән гаиләләр өчен бәһасез энциклопедия рәвешен алды. «Безнең мирас» журналын «иҗтимагый-тарихи, дини, фәлсәфи, педагогик, әдәби-сәнгати мирас сандыгы» дип атасак та ялгышмабыз.

Журнал яшь гыйльми эзләнүчеләр өчен дә кадерле: остазлары, танылган галимнәр янәшәсендә алар да биредә рецензияләр, фәнни мәкаләләр бастыра ала.

Аерата мөһиме: «Безнең мирас»та, гуманитар фәннәрнең тарихына, шул фәнгә гомерен багышлаган кешеләргә, төрки халыкларның, аерым алганда татарның милли гореф-гадәтләренә һәм күп гасырларга сузылган тарихына кагылышлы язмалар белән беррәттән, бүгенге фәнни ачышларны, заман технологияләрен, гуманитар фәннәрнең фундаменталь нигезләрен яктырткан актуаль яңгырашлы мәкаләләр белән дә танышырга мөмкин.

Табигый, «Безнең мирас» авторлары галимнәр даирәсе белән генә чикләнми: һәр шома каләмле, фикерле, белемле, белгәннәрен башкаларга җиткерергә теләгән гади укучыга да аның битләрендә урын бар. Җөмләдән, редакциянең милли йолаларны, матур гореф-гадәтләрне, җирле тарихны яктырткан, үзенчәлекле популяр сөйләмгә корылган язмаларга ихтыяҗы зур, дип уйлыйм.

«Безнең мирас» хезмәткәрләре, әйтелгәннәр янәшәсендә, журнал аудиториясенең яшь һәм һөнәри үзенчәлекләр белән генә билгеләнмәвен истә тота. Бу «Татар гаме», «Хәтер сандыгы», «Шаян мирас», «Йөз ел элек», «Тел күрке – сүз» кебек киң катлам укучыларны кызыксындыра алырлык сәхифәләр исеменнән дә ачык күренә. Шул ук вакытта журналның фәһемле һәм милли хисле укучыга атап чыгарылганлыгын да онытырга ярамый. «Безнең мирас» кешене тормышта актив позициядә торуга, теге яки бу проблемаларны чишүгә иҗади якын килүгә, уйларга, уйлатырга һәм каләм тотарга да кызыктыра, дип ышанам.

Журналның перспективасы зур, нигезе ныклы, ул инде калыплашкан традицияләргә ия. Димәк, «Безнең мирас»ка: «Моннан соң да төрле катлам укучыларының ихтыяҗын истә тоткан популяр басма рәвешендә яшә!» – дип теләргә генә кала.

Рифә РАХМАН,
язучы, филология фәннәре кандидаты

«Мирас», №8, 2004 ел

«Мирас»лы халык үлмәс!

Юныс Сафиуллин

Әйтәселәремне мирас дигән сүзгә мәдхия укудан башлыйм. Үткәннәрдән безгә күчеп килгән мирас төшенчәсе генә ятмый аңарда, киләчәк буыннарга бездән калачак мирас, ягъни безнең бүгенге талантлы галимнәребез һәм дә әдипләребез иҗат иткән һәм иҗат итәсе мирас турындагы мәгънәне дә сыйдыра ул затлы сүз. Милли журналларыбызның берсе аны үзенә исем итеп сайлап алып һич тә ялгышмаган. Чыга башлавына күп булмаса да (1991-2004), үткәннәрне бүгенгегә алып килүче һәм бүгенгене киләчәккә тоташтыручы рухи күпергә әверелә алды бу журнал. Бәхетебезгә, «Мирас» драматургия өлкәсендә дә кыю юл яра.

Татар милләтен мин, нишләптер, җитәр-җитмәс эш хакына яшәп ятучы бүгенге замана ирләренә охшатам. Нинди генә затлы, яхшы күңелле булмасын бу ирләр, аларның газиз балалары зур акчалар кулга төшерә алучы, иномаркаларда йөреп, матур коттеджларда яшәп яткан олигарх-күршеләреннән көнләшеп яшиләр. Көнләшеп кенә калсалар бер хәл, алар әти-әниләренең ярлы булуына кимсенеп, без дә баерга тиеш, дип, төрле юләрлекләр дә эшләп ташлыйлар... Шушы мисалдагыча, 452 ел элек үк дәүләтен, байлыгын югалткан татар милләтенең «балалары да» Франция, Англия, Алмания халкына, хәтта Россиябезнең баш халкы саналган русларга да кызыгып көн уздыралар. Бу хәл татар милләтен телсез, аз санлы итүдә төп бәлагә әверелә – кызларыбыз читләргә чыга, егетләребез читтән кыз ала, читкә китеп югала, алардан туган балалар исә һәммәсе диярлек чит милләт балаларына әверелә бара... Әгәр берничә меңьеллык рухи мирасыбыз булмаса, шуны җыеп, бергә туплап, һәрьяклап өйрәнеп, Тукайча итеп әйтсәк, раушан көзгеләредәй балкытып, халыкка бөтен зурлыгы белән кайтаручы халыкара академик «Мирас» журналы тумаса, без инде, Россиядәге күп дистә халыклар шикелле, бөтенләй юкка чыгуга юл тоткан булыр идек. Әмма, шөкер, башка журналлар янәшәсендә үк бик лаек урын тоткан, рухи мирасыбызны халыкка кайтару юлында елдан-ел ныгый, бай тәҗрибә туплый, эшчәнлеген бик күптармаклы

Ю.Сафиуллин «Идегәй». Туктамыш хан ролендә – Ә.Шакиров, Җаникә – А.Гайнуллина. 1994 ел

итә барган «Мирас»ыбыз бар. Халкыбыз мәдәнияте ихтыяҗыннан чыгып, бер генә жанрны дә үгисетми ул. Мин, театр кешесе буларак, «Мирас»ның сәхнә әсәрләренә күрсәткән игътибарын ассызыклап әйтергә телим. Аның иң беренче сынау санында ук (1991 елны булды ул) без Гаяз Исхакыйның «Олуг Мөхәммәд» тарихи драмасын кулларыбызга алдык. Онытыласы юк, безнең театрда артисттан артистка күчеп укылды бу пьеса. Әйе, Марсель Хәким улы Сәлимҗановның портфелендә «Җәмгыять» комедиясе янәшәсендә үк «Олуг Мөхәммәд»ле «Мирас» журналы да ятты. Ахырда Марсель Сәлимҗанов, Гаяз Исхакыйның «Җәмгыять» пьесасы камилрәк язылган, дип, өстенлекне «Җәмгыять»кә бирде. Инде бу чираттагысын куймый калуының сәбәбен дә әйтү кирәктер.

– Марсель Хәкимовичтан күпләр: «Нигә Гаяз Исхакый һаман сәхнәләштерелми?» – дип сорагач: *«Гаяз Исхакыйның драматургиясе прозасына караганда күпкә кайтышрак, бүгенге көн драматургиясе белән ярыша алмас... Менмәс борын сәхнәдән төшә икән, ул инде авторны да, театрны да бизәмәс, әйе, сәхнә барыбыз өчен дә шундый таләпчән судья – сәхнә әсәре үзенең меңъеллар буенча камилләшә килгән кануннарына таянып иҗат ителмәсә, үз чорында гына кала»*, – диде. Моңа өстәп шуны әйтү кирәк, һәр театрның үз йөзе бар. Үз тамашачылары һәм дөньяны үзенчә күрә торган артист һәм режиссёрлары бар. Кызганыч, әле бу мирас кайтканнан бирле, Г.Исхакыйның нибары дүрт кенә сәхнә әсәре дөнья күрде. Алар «Зөләйха» (Г.Камал театры белән Уфа «Нур» татар театры куйды), «Алдымбирдем» (Камал театрында), «Җан Баевич» (шулай ук Камалда) һәм «Өч хатын белән тормыш» (Түбән Кама театры сәхнәләштерүендә). Ә инде «Олуг Мөхәммәд» һәм башка пьесалар, журналларыбызда, китапларда урын алып, үз режиссёрлары туганны көтәләр. Татар укучысының пье-

саны да яратып укуын исәпкә алсак, әлеге пьесаларның, сәхнә күрмәсәләр дә, шул журнал-китапларда басылып чыккан килеш тә милләткә файда китерүләре мәгълүм, чөнки алар милли әсәрләр.

Шушы төп фикеремне аңлауда зарур булган мөкаддимәдән соң кулга каләм алырга мәҗбүр иткән проблемага күчәм. Татар театрлары ишәйде. Вакытлыча югалып торган үзешчән театрлар да кабат аякка баса башлады. Шулай итеп, татарларның Татарстанда һәм Россия шәһәрләрендә эшләп килүче унбер профессиональ һәм берничә ярымпрофессиональ театрыннан һәм берничә дистә үзешчән театрыннан да Казаныбызга, тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, нәкъ менә Г.Камал театрына вәкилләр агыла. «Башка театрларда безнең белән сөйләшеп тә тормыйлар, шуңа сезгә киләбез инде менә», – диләр. Безнең театр репертуарындагы яңа гына сәхнәгә менгән пьеса кирәк аларга, әлерәк кенә язылганына да бик риза буласылар... «Төрле сәбәпләр аркасында үзегез куймый калдырган пьесалар булса да ярар иде безгә, күрсәтә алмассызмы?» – дип ялыналар. Дөресен әйтим, бу минем өчен генә түгел, китапханә мөдиребез өчен дә бик мәшәкатьле, күп вакыт сорый торган эшкә әверелә. Пьесалар бик еш язылып, театрга күпләп килеп торса да, арада һәр ун пьесаның 7се өйрәнчек әйберләр генә була. Калган өчесе дә килүгә тотып куярлык түгел, кат-кат эшлисе бар. Килүчеләр хәтта шундыйларының да байтагын ксерокс аша чыгарып, театрларына алып кайтып китәләр. Эш өстенә эш булган, хәтта китапханәче «вакытым юк» дип кырт кискән чакларда да, үзешчән сәхнәдә спектакль уйнап йөргән яшь чагымны искә төшереп һәм милләтнең киләчәге минем дә киләчәгем бит дигән сентименталь уйларга бирелеп, һәммә кешегә булышуымны дәвам итәм. Әдәби бүлек һәм китапханә шкафларындагы пьесаларны актарган арада, элек гел чыгып килгән «Күңелле сәхнә», «Безнең сәхнә», «Клуб утлары», «Үсү юлы», «Үзешчән сәнгать түгәрәкләре өчен пьесалар» дигән дистәләрчә китапларны сагынып телгә алабыз. Тәҗрибәле мөхәррирләр кулыннан үтеп, кирәк икән авторларыннан кат-кат эшләтеп алынган әлеге пьесалар буенча үзешчән сәхнәләрдә күпме спектакль куела иде. Профессиональ театрлар да аларга бик теләп мөрәҗәгать итте. Сиксәненче һәм туксанынчы елларда без әнә шул бик мөһим чыганаклардан мәхрүм калдык. Шуны сизепмедер, «Мирас» шушы гаять изге дә, игелекле дә эшкә алынды. Аның тагы шул ягы да бар бит әле – яшерен-батырын түгел, бездә чын профессиональ югарылыкта язылган пьесалар юк дәрәҗәсендә икән бит. Мәскәүдән килгән белгечләр дә, әле башлап кына яза башлаган яшьләргә түгел, инде бик зур тәҗрибә туплаган, халык яратып карый торган дистәләрчә пьеса язган драматургларыбызның пьесалары белән танышкач та, шул ук сүзне әйтәләр: «Сезнең драматургларыгызның күпчелегенә драматург һөнәрен өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле!» – диләр. Әнә шуңа да, «Мирас» журналының авторлар китергән пьесаларга таләпчәнлекне елдан-ел арттыра баруы, кат-кат эшләткәч кенә дөньяга чыгаруы шушы юлда тагын бер зур казаныш. Әгәр «Мирас» журналы шушы юнәлештә тагы да тирәнгәрәк кереп китеп, хәтта пьеса язу нечкәлекләрен аңлаткан язмаларны да чыгара башласа, нур өстенә нур булыр иде! – дип өндәү һәм күп нокталар куям... ■

Садриевлар кавеме

Рәдиф Сәгъди

Атау Толымбаенда гына түгел, Буа, Казан, Татарстан киңлекләрендә, Россиянең татарлар күпләп яшәгән төбәкләрендә дә Садриевлар кавеменең берсен белмәсәләр дә, икенчесен беләләр. Толымбай авылында туып үскән ир-атлар, бу очракта Садриевлар нәсел-нәсәбе – талантлы затлар, хәлбуки җиң сызганып иҗат итмәсәләр, хезмәтләрендә зур көч куеп тырышмасалар, уйлап табуларын үсешкә кертмәсәләр, табигатьтән, Аллаһы Тәгаләдән бирелгән сәләтләре юл ярмас, яралгы килеш кенә калыр иде.

АТАУ ТОЛЫМБАЙ АВЫЛЫ

Ләкин Садриевлар кавеме ваемсызлардан түгел. Шуны да искәртеп китәсем килә: Толымбайдан чыккан күренекле кешеләр бик ишле, саный китсәң, ике-өч дистәләп алар. Егерме-утыз авылга җитәрлек танылган, күренекле шәхесләр биргән сала бит ул – Атау Толымбае. Нишләп шундый мул, нык үсентеләр биргән соң, бер карасаң, гади генә күренгән татар җирлеге?! Нинди феномен?! Кайчан башлап нигез салынган соң бу затлы кешеләрне мулдан биргән Атау Толымбае авылына? Кемнәр булган икән соң Садриевларның әби-бабалары?

1552 елның ахырында вәхшиләрчә яулап алынган Казан ханлыгында яшәүче татар, чуваш, мордва, мари, башкорт халыклары, коточкыч талану, мәсхәрә ителүләргә түзә алмыйча, баш күтәрә. Мамич-Бирдәй җитәкчелегендәге көрәш ялкыны, бер сүлпәнәеп, бер күтәрелеп, 1584 елларга кадәр дәвам итә. Халыкның каршылык күрсәтү көчен сындыру һәм аны тәмам руслаштыру нияте белән 1555 елдан башланган чукындыру эшләре бертуктаусыз бәрелешләргә китерә. Чукынсаң, җир, йорт салу, каралты кору өчен агач бирелә, 3 елдан алып 6 елга кадәр салым түләүдән, гаскәри хезмәттән азат ителәсең. Динеңнән язсаң, барлык җәмәгатеңә акча түләнә. Рус дәүләте моны үз казнасы хисабына эшләми, әлбәттә, чукынмаучылар җилкәсенә сала.

Инде, чукынучылар кире татарларга ияреп ислам диненә кайтсалар, каты җәзаларга тартылалар: төрмәләргә ябалар, имгәткәнче кыйныйлар, тимер яки агач казыкларга утырталар, хатыннарын рус бәндәләренә көчләп хатынлыкка бирәләр, балаларын тартып алып, монастырьларга озаталар. Мәчетләрне җимерәләр, яңаларын да салырга рөхсәт бирмиләр. Европада бетерелгән инквизиция Россиядә тагын да куркынычрак төсмер ала. Кыскасы, үз теленә, ата-бабалары мирасына тугрылыклы калган, теләсә нинди сынауларны да үтәргә әзер булган кешеләргә ул заманнарда әйтеп бетермәслек золымнар күрергә

Атау Толымбай авылының бер күренеше

туры килә. Туып үскән, кендек каннары тамган туган җирләрен ташлап китәргә, кайда буш, тыныч кебек күренгән җир бар – шунда оя корырга, йә булмаса качак хәлендә яшәргә мәҗбүр булалар. Бүгенге көндә Толымбай авылына нигез салучы зат шундыйларның берсе булган, дип фараз кылына. Толымбай атлы бу кеше, үзенең дусты Илбай белән, чукындырылудан котылып калу өчен, Кырлангы ягыннан Зөя буена – хәзерге көндә Чиялек исемен йөрткән җиргә килеп сыена. Балык тотып, җәнлек аулап, кош-корт асрап яши башлыйлар. Тормышлары өчен шул җитә, чөнки ясак түләргә кирәк түгел, салым юк. Беркайда да беркетелмәгәннәр, ягъни исәптә түгел! Аларны беркем дә белми... Ләкин көннәрдән беркөнне, ауда йөрүче оброк-салым җыючы Нәнеп Чураев атлы татар боларның эзләренә төшә. Аралашып, нык дуслашып китәләр. Чураев ауга чыкканда Толымбай белән Илбай ахириләре янына балык шулпасы ашарга тукталгалый. Шулай аралаша торгач, ул аларга үз карамагындагы оброк җиренә күчеп утырырга тәкъдим итә, Свияжск приказ йортына барып, утрак тормышларын рәсмиләштерергә вәгъдә бирә. Качак тормыш мәшәкатьләреннән гарык булган Толымбай белән Илбай ризалаша. «Яшь тә җитәрлек, законлы, ирекле тормыш та сагындыра», – дип уйлый алар.

Ниһаять, 1655 елда Толымбай белән Илбай, Зөя үзәнен ташлап, Нәнеп Чурай ярдәмендә хәзерге Толымбай авылы күле буена килеп төпләнә. Ярдәмчел дуслары аларга йорт салырга, Черкен авылы кызларын димләп, гаилә корып җибәрергә дә булыша. Шулай итеп, 1655 елда хәзерге Толымбай авылы барлыкка килә һәм шушы елдан аның тарихы башлана. Ерак киләчәктәге, ягъни бүгенге көндәге күренекле шәхесләр – Гомәр Толымбай, Равил Кукушкин, Җәләл Шәмиев, Шәрәф Әхмәдулла, СССРның атказанган тренеры, спорт остасы Сабирҗан Нәфыйков – барысы бергә 12 спорт остасы, шулай ук Россиянең атказанган табибы Сәйдәш Шәмсетдинов, Исмәгыйль, Ибраһим, Илдар, Фәрит, Раил Садриевлар һәм башкаларның нәсел үсешенә башлангыч бирелә – тернәкләнү-ишәю башлана.

САДРИЕВЛАРНЫҢ БҮГЕНГЕ БУЫНЫ

Садриевларның бүгенге буынына тукталыр алдыннан, үткән гасыр башында яшәгән Исмәгыйль вә Ибраһим бабайларны искә алып китмичә мөмкин түгел. Алар Буа профессиональ театрының нигез ташлары да булып торалар.

1915 елда, укытучы Әкрам Мифтахетдинов, татарча спектакль уйнарга телибез, дип янып йөри, шуны җирле

Театрның беренчел бинасы

хакимияткә дә җиткерә. Аңа рөхсәт бирмиләр. Сәбәбе – имеш, Буада татарча цензура юк. Революциядән соң гына бу алдынгы фикерле мөгаллимгә шәкертләре белән бергә спектакль уйнау насыйп була. Шуңа күрә 1917 елны Буа театрының туган елы дип санасак та, дөрес булыр. 1917 елның 4 маенда «Казанга сәяхәт» дигән әсәр уйнала. Спектакль барганда солдатлар кизү тора, чөнки консерватив фикерле бәндәләр каршылык күрсәтә. Алар тамашаны хатын-кызны аздыра, зина кыла торган урын дип саный. Театр бар көченә 1918 елда гына эшләп китә һәм «Буа шәһәр театры» исемен ала. 1918-1919 елгы сезонда бу труппада Камал I, Камал II, Камская, Айдаров, Газиз Айдарский кебек атаклы артистлар да уйный. 1924 елда Буага Татарстанның атказанган артисты Бари Тарханов җитәкче булып килә. Раил Садриевның бабалары Исмәгыйль һәм Ибраһим Садриевлар да театр тормышында актив катнаша, спектакльләрдә уйный. Ибраһим агага килгәндә, ул театр тормышы сүлпәнләнгәч тә кул кушырып ятмый, үзе пьесалар яза. Аның «Бикмуч карт», «Песи агай тормышы», «Ярлы хәйләсе» исемле әсәрләре авыл үзешчәннәре тарафыннан сәхнәгә куела. Әлеге драма әсәрләрендәге тематика үз чорына хас күренешне – күмәк хуҗалык булып яшәүнең уңайлыкларын күрсәтеп, бердәмлеккә өндәп язылган сюжетлардан тора. Автор шул заманның кискен, ачлы-туклы, фаҗигале тормышын җиткерә. Пьесаларны сәхнәләштерүдә Ибраһим Садриев үзе дә актив катнаша, башкалар белән беррәттән, төрле рольләрдә уйный. Бу инде, үзенә калса, Буа шәһәр театры ул чорда эшен туктаткан очракта, аның чаткысыннан кабынып киткән бер кечкенә генә учагын саклап калырга тырышулары була. И.Садриевның «Бикмуч карт» пьесасы 1,8 басма табакны тәшкил итә, бүгенге көнгә күчерсәк, бу 45-50 битлек язма дигән сүз! Пьеса 1932 елда Казанда 10000 данә тираж белән басылып чыга. Ибраһим аганың тагын 200ләп шигыре барлыгы да билгеле...

Садриевларның нәсел-нәсәбенә игътибар юнәлткәндә, Ибраһим аганың онысы Илдар абыйга тукталмыйча мөмкин түгел. Нәсел-нәсәпнең күпчелеге авыл хуҗалыгы белән мәдәният-сәнгатьтә хезмәттә булса, Илдар Исмәгыйль улы

көчле спорт төрләрендә Татарстан, Россия күләмендә призлы урыннар яулый. Марксизм-ленинизм университетын тәмамлаган Илдар ага вузда укыганда да көрәш алымнарын чарлый. Күпләр үз кесәләрен генә кайгыртыр өчен башка идеология-партияләргә күчеп бетсәләр дә, ул Коммунистлар партиясенә тугры калды. Бактың исә, Россия халкы өчен аның тарихында коммунизмнан да гаделрәк юнәлеш булмаган икән. Ни кызганыч, Кытай җитәкчелеге кебек, партияне саклап калып, илне дөрес юнәлешкә борырлык, аны икътисади үсешкә китерерлек зирәк акыллы шәхесләр табылмады СССР дип аталган илдә. Бар хөсетлекне Ленин бабайга сылтап калдырып, ил түрәләре халык байлыгын үзләштерүгә корылган мәгънәсез җәмгыять төзергә җиң сызганып алындылар. Илдар абый бу хәлләрне күреп борчылып яши. Кайда ул Буа төбәгендәге мал-мөлкәте ташып торган алдынгы миллионер колхозлар?! Фин-угырлар һәм төрки-татарларның борынгыдан килгән җирләренә кабат афәт китерделәр түгелме соң?! Моңа җирле халыкларның милли таркаулыгы да сәбәпче түгелме?! Илдар аганы әлеге мәсьәләләр бик нык борчый. Илне кабат упкын алдына китереп терәделәр, оныкларга, киләчәк буынга нәрсә калдырабыз соң без?! Заманында Илдар ага Буа районының милли көрәш буенча командасын җитәкләгән. Зур җиңүләр яулаганнар, хәтта М.Җәлил исемендәге призга ия булганнар. Инде менә Буа командасының Татарстанда 1966 елдан бирле беренче урынны күргәне юк! Ошбу хәлләргә борчылган аталы-уллы Илдар һәм Раил Садриевлар, бозны кузгатып, эретеп җибәрәләр – моннан сигез ел элек үзләренең Толымбай авылында көрәш турниры оештыра башлыйлар. Әйдаманнар – әйдәп баручы шәхесләр генә кирәк: татар – затлы милләт, ул кырда да җиң сызганып эшли, сәхнәдә дә бил бирми! Яуда исә юлбарыстай көрәшә дә.

Илдар Садриев турында улы:

Илдар ага Садриев. Келәмдә бил тоткан чорлары

– Балачагым ямьле, матур булды. Безнең әти – күренекле, якты кеше, әйдәп баручы, КВН, спорт, Югары партия оешмасының җитәкчесе булды, яшьләрнең лидеры иде: гармунда уйнау дисеңме, сәнгатьне яратуы, оештыру сәләте, көчле кыйбласы – кыскасы, гел бер юлдан барды ул. Хәзер дә үз юлыннан тайпылмый, күңеле чиста, әчкерсез, хөсетсез. Шул ук вакытта кызып китүчән кеше дә ул, тик минем күк, тиз әйләнеп кайта, кеше белән кешене аермый. Ятим үскән кеше булса да – үчсез кеше, рәнҗү-кимсенү юк, чөнки аның әтисе – минем бабам колхоз рәисе булган, бронь бирүләренә карамастан, үзе теләп сугышка киткән.

Ни кызганыч, 1941 елның 7 октябрендә Калинин фронтында – Тверь өлкәсендә һәлак була. Әткәй шулай итеп ятимлектә, мохтаҗлыкта үссә дә, безне дә, үзен дә мохтаҗлыкта яшәтмәде. Ул хәзер дә безнең өчен үрнәк: үзенекенә инана, кешенекенә кысылмый!

Илдар абыйның туганнан туган энесе Фәрит Садриевны Татарстан җитәкчеләре арасында белмәүчеләр юк

Кабат ачылган театрның сәнгать җитәкчесе Раил һәм директоры Фәрит Садриевлар. 2007 ел

дәрәҗәсендәдер. «Буаның каласының шәрәфле әгъзасы»: 2011 ел, «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре: 2009 ел, «Россия Федерациясенең атказанган фермеры»: 2009 ел, «Техник фәннәр кандидаты»: 2002 ел. Аның хезмәтләрен саный китсәң, калын китаплар язарлык. Орден-медальләргә, Россия Герое исеменә ия булырга лаек шәхес. Сәнгать юлыннан гына китсә дә зур уңышларга ирешкән булыр иде ул. Ижевск каласында авыл хуҗалыгы институтының механика факультетын тәмамлап, инженер-механик дипломы алып, 1975 елның июлендә туган авылына кайтып төшә Фәрит Садриев. Яшь-җилкенчәк өчен бердәнбер күңел ачу урыны аулак өйләр генә булган заманда клуб-эшчәнлегендә инкыйлаб-революция ясый Фәрит абый. Әле инженер булып эшкә урнашып та җитми, эчпошыргыч мәдәни сүлпәнлектән котылыр өчен, җиң сызганып иҗат итәргә керешә. Кечкенәдән җыр-моңга тартылып, әтисе Миргасыймның татар көйләренең гаҗәеп нечкәлекләрен тоеп гармунда уйнауларын тыңлап үскән углан беренче класстан ук үзе дә уен коралын кулына ала. Мәктәптә укыганда укытучысының бәйрәм-концертларда алыштыргысыз ярдәмчесе булып китә. Ижау авыл хуҗалыгы институтында белем эстәгәндә дә (1966-1971 еллар) 20ләп түгәрәктә (фәнни һәм мәдәни) осталыгын чарлый, бию буенча укытучы таныклыгына хәтле ала. Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәндә дә, бар сәләтен бию түгәрәге оештыруга биреп, иптәшләрен өйрәтә. Ә инде белемле белгеч булгач, иң башта Уфа шәһәренә барып, уен кораллары юнәтеп кайта. Салада күренмәгән, күтелмәгән, заманча уен кораллары – өч электрогитара, бер электроорган, бер тавыш көчәйткеч, сугып тавыш чыгару җайланмалары... Кыскасы, барлыгы 4 мең сумлык тауар, ул заман өчен бер җиңел машина алырлык зур сумма. Уен коралларын тәртипкә китергәч, Фәрит Садриев җитәкчелегендә репетицияләр башланып китә. 1975 елның Октябрь бәйрәмендә ансамбль, революциягә багышланган репертуар белән, колхозчылар алдында чыгыш ясый. Тамашачылар артистларны дәррәү алкышлый. Программа Килдураз, Күл-Черкен, Кырлангы һәм Карлы авылларында күрсәтелә. Ниһаять, шул ук елны тугыз кешедән торган агитбригада төзелә һәм ул, «Зөя иртәсе» исеме астында, алты районны җыйган үзешчәннәр смотрында катнаша. Агитбригадага лауреат исеме бирелә. 1976 елның 21 декабрендә Буа зонасында үткән смотрда «Советлар Союзы – тынычлык терәге» исемле программаны жюри югары бәяли: «25 ел буена күпме коллективларны күргән, менә бүген 45

минут эчендә Советлар Союзының тышкы һәм эчке сәясәтен шулай ачык һәм оста җиткерә алучыларны беренче күрәм, чын күңелдән соклανам», – дип, жюри рәисе җиңүчеләргә алтын медаль тапшыра. Инженер булып эшли башлагач та иҗаттан аерыла алмый Миргасыйм улы. Ансамбле, иҗатташ дуслары Фирдүс Котдусов, Рафаэль Латыйпов, Фәния Сәләхиева, Наил Мингалиев, Зиннур Вәлиев, Фазылҗан Борһановлар белән бәйрәм саен концертлар, төрле чаралар оештыралар. Алар авыл тормышына ямь өстенә ямь өстиләр. Фәрит абыйның, баянда уйнап, йомшак тенор белән җырлавын бүгенге көндә дә рәхәтләнеп тыңлыйсың, аның әдәпле иҗатына сокланасың! Ирексездән: «Нишләп профессиональ баянчы һәм җырчы булып эшләмәде икән?» – дигән сорау туа. Төзү-җитештерү эшчәнлеген кирәгрәк, җитдирәк итеп санагандыр, күрәсең, бу тынгысыз, талантлы зат. 1973 елдан алып, Буа төбәге Сабантуйларының берсе дә Фәрит аганың катнашыннан башка үтми. Сценариен язу, бизәү, оештыру эшләре дисеңме – барысы да аның куллары аша уза һәм ул шуның белән горурланып, тормыштан ямь табып яши белә. Хыялы – Буаны ак каеннарга төренгән, яшел чирәмгә күмелгән шәһәргә әйләндерү. Миңа калса, район җитәкчелеге белән бергәләп шушы юнәлештә эш алып барыла да, чөнки Тау ягының башкаласы елдан-ел матурлана бара. Без белгән язын-көзен сазлыкка баткан кала түгел ул бүген! Ә менә аның төп һөнәренә килгәндә, Буа каласы буенча гына да күпме игелекле гамәлләр кылынган.

Ул – «Икмәк – тиңсез хикмәт!» (Хлеб – всему голова) дип аталган монументаль композиция авторы. Әлеге композиция бирегә килүчеләрне 2008 елдан бирле Буа шәһәренә кергәндә каршы ала. 2009 елда Буинск дип русча язылган һәм Зөя елгасы буена куелган, Голливудны хәтерләткән, тугыз метр биеклектән төнлә утлары балкып торган язманың да авторы Фәрит ага – саный китсәң, очы-кырые юк! Буа Аланы мәдәни-спорт үзәгенең проекты, Карлы елгасы аша салынган, пионер лагерена үтүче юл буендагы утыз тонна күтәрелешле күперләр дә Фәрит аганың катнашында проектланган һәм төзелгән. Аңа хәтле район икътисадына кертелгән техник иҗаты да мең рәхмәтләргә лаек. 1981-1991 елларда бөтен шикәр заводы хуҗалыгы чәчелеп – тузып яткан, хәтта коймасы да калмаган чорда райкомның шулчактагы беренче секретаре Рафыйк Габдулла улы Фәезханов шикәр заводына яңа гына генераль директоры итеп билгеләнгән Кәпәчевкә: «Фәрит Садриев белән бергәләп аякка бастырыгыз», – дип тәкъдим ясый. Фәрит ага районның элекке җитәкчесе Рафыйк Габдулла улын: «Безнең Рафыйк абый каһарман, уникаль кеше иде, ил дилбегәсе андый кешеләр кулында булса, СССР дәүләте дә таркалмас иде, чөнки алар алгарыш булсын, дип яшәүче шәхесләр, яшьрәкләргә тәҗрибә, яшәеш гыйлемен җиткерүчеләр иде», – дип сагынып искә ала. Фәрит ага татлы тамыр эшкәртү заводына баш инженер итеп вакытлыча гына дип килсә дә, озак та үтми, баш инженер булып билгеләнә һәм бөтен завод проблемалары аның җилкәсенә кала. Ул, авыл хуҗалыгы белгече буларак, татлы тамыр заводы бөтенләй үзгә мохит икәнлеген аңлый, шикәр җитештерү өлкәсендәге нечкәлекләргә төптәнрәк төшенер өчен, Белоруссия, Украина кебек республикаларга, Краснодар өлкәсе заводларына кадәр барып, җитеп аларның эшчәнлеге белән таныша, тәҗрибә туплый. Озак та үтми, нибары дүрт елдан соң, Буа шикәр заводы 365 шикәр заводы арасында беренчелеккә чыга. Бу эшнең нәтиҗәсен хәтерләтеп, бүгенге көндә татлы тамыр эшкәртү предприятиесе музеенда зур кызыл йолдыз билгесе саклана. Үзе хезмәт куйган идарәнең тирә-юнен ямьләндерү, агачлар утырту, парк-бакчаларны матурлау, таганнар ясап урнаштыру, чыршылар белән бизәү, мәдәни-агарту эшләре дисеңме – дәртләнеп, иҗатыннан ләззәт табып, җиң сызганып эшли.

Хезмәт шартларын яхшыртып, нәтиҗәле эшчәнлек алып барыр өчен, эш

урыннарында да уңайлыклар тудырыла. Тау хәтле көч түгелә хезмәт шартларын төптән үзгәртер өчен!

1991 елгы Ельцин революциясеннән соң, Фәрит ага, үзен яңа яктан сынап карар өчен, фермерлык хезмәтенә алына. Кибетләр ачып, компьютер һәм электрон товарлар, азык-төлек сатып та яшәп булыр иде, югыйсә. Ләкин үсмер чагыннан ук илнең кырларын Европа дәрәҗәсенә күтәрергә хыялланган шәхес нәкъ менә крестьян хезмәтен сайлый. Данлыклы Краснодар шикәр заводына да баш инженер итеп чакырып карыйлар үзен, тик гүзәл, җылы кара диңгез буйларына китеп бармый ул! Үзенең Татарстанына, газиз Толымбай кырларына тугры кала. Биредә яңа эзләнүләр, яңа хыяллар белән янып яши һәм игенченең авыр хезмәтен җиңеләйтү, аның нәтиҗәлеген күтәрү өчен акыл белән кул хезмәтен кушып алып барырга тырыша. Аның уйлап тапкан җайланмалары – яңа культиваторлары һәм чәчкечләре, Толымбай авылында сынау үтеп, үзгәртеләсе үзгәртелеп, соңыннан заводларда җитештерелә башлый. Гаилә тормышына килгәндә, алар Венера Һади кызы белән 1979 елны таныша. Боерган авылына эшкә килгән белгеч-кыз Фәрит абыйның күңелен яулый. Шул ук елның 1 июнендә алар кавышалар да. Тагын шунысы кызыклы: Венера ханым да, Фәрит абыйның бабасы Ибраһим ага да дөньяга ошбу 1 июнь көнне аваз салган. Гаиләдә ике бала – Рөстәм белән Миләүшәләрен аякка бастырып, бүгенге көндә инде дүрт оныкларын тәрбия кылалар.

ТЕАТРЛЫ ШӘҺӘР – НУРЛЫ ШӘҺӘР!

Раил Илдар улы Садриев 1966 елның 14 октябрендә Атау Толымбае авылында дөньяга килә. Алдарак язып үтүемчә, алар кавемендә, төрле өлкәләрдә хезмәт кылсалар да, нәселдән килгән иҗатка, дөресрәге, сәнгатькә тартылу көчле. 1983 елны авылда урта мәктәпне тәмамлагач, Казан дәүләт университетына укырга керә. 1993 елдан башлап, Буаның 56 нчы профтехучилищесында үзе белем бирә башлый. Бераздан, заман шаукымына ияреп, эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә алына.

2004 елның яңгырлы көзге көнендә Татарстан Язучылары берлегенең мин эшләгән пропаганда бүлеге бүлмәсенә сакаллы бер адәм килеп керде. Очраклы кеше түгел иде ул бу бүлмәдә, чөнки моңа кадәр без аның белән ике-өч тапкыр Буа җирлегендә күрешкән идек. Соңгы очрашуыбыз исә район үзәгендә үткәрелгән төбәкара «Идел-йорт» конкурсында булган иде. Җирле халык театры Камил Саттаров белән миңа, ягъни жюри әгъзаларына Ә.Камалиевның «Әлепле артистлары»н күрсәтеп шаккатырган иде. Камил Саттаровка: «Бу үзешчәннәр бит, ә профессиональ труппаларны да уздырдылар, алардан яхшырак уйнадылар», – дим. «Самимиләр алар, маймылланмыйлар, рольләрен чын күңелдән бирелеп башкаралар», – диде ул чагында Мәдәният министрлыгында өлкән инспектор булып хезмәт куючы сәфәрдәшем. Үзе белән якыннан танышабыз: «Сәнгатькә, мәдәнияткә тартылу көчле инде безнең нәселдә, шул сәбәпле, 2002 елны, бер төркем талантлы район укытучыларын, китапханәчеләрен, мәдәният хезмәткәрләрен туплап, Туфан Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре»н сәхнәләштердек, үзешчән театрлар бәйгесендә җиңеп чыгып, Халык театры исеменә лаек булдык», – ди сакалбай. Өстәвенә, безнең уртак танышларыбыз барлыгы да билгеле булды һәм аның белән элегрәк елларда ике тапкыр чәй өстәле артында күрешкән булып чыктык. Ашыгып сөйләүче, янып, баскан җирендә биеп торган бу егет, ниһаять, исемә төште. Ул бит эшмәкәр чагында, театр сәнгатен яратучы егет буларак, эшләп тапкан акчасын 1992 елда Мансур Гыйләҗевнең яшьләргә багышланган «Казан егетләре» әсәрен куйдырырга биргән иде. Соңыннан ике составта иҗат итүче артистларның барысына да, рәхмәт йөзеннән, иганәче бу-

Мәдәният министры Айрат Миңнемулла улы Сибагатуллин белән. 2007 ел

ларак, конвертларга салып акча өләшеп чыкты. Хәтерем яңара, бу яшь кешегә хөрмәтем арта гына бара! Безнең әңгәмә спектакльдән соң чәй өстәле артында куерса, инде китәргә дип җыенып урамга чыккач, халык театры режиссеры Раил Садриев мине читкә чакырып алып: «Буада профессиональ театр булган, шуны кире торгызырга иде!», – ди. Мин аптырап калдым, үзем театрда ике дистә елдан артык эшләп алган тәҗрибәле шәхес буларак, ул көннәрдәге иҗат труппаларының хәлен яхшы беләм, хәтта кайбер иҗат-сәнгать йортларын ябу турында сүзләр дә йөргән мәнсез чор бу! Барысы да матди кыенлык кичерә. Кунакчыл хуҗамның да кәефен төшерәсем килми: «Белмим шул, барып чыгармы икән?» – дим. «Чыгар, миңа Камил Сатталов: Мин инде өлкән кеше, әнә Рәдиф Сәгъди белән сөйләшеп кара, ул Язучылар берлегендәге пропаганда бүлеге җитәкчесе, оештырса, ул гына оештыра алыр, өстәгеләр язучылар сүзенә генә колак салсалар, игътибар итсәләр инде, дип, сезгә җибәрде», – ди. Ярдәм сорап килгән кешеләрне гомеремдә дә кире борырга өйрәнмәгән адәм буларак, бу иптәшнең дә кәефен төшерәсем килмәгәнгә: «Язучылар берлегенә кил, дус-иш язучыларны җыеп, киңәшмә үткәрербез», – дим, хәлбуки ошбу изге эшнең барып чыгасына ышанмасам да. Егете талантлы бит! Нәрсә белән булса да юатырга кирәк, тора-бара, бу идеясеннән үзе дә арып-туеп, тукталып калыр, дим эчемнән генә.

Юк бит, әнә, килгән, күзге салкын яңгыр ява дип тә тормаган! Үзе белән Рифат дигән дус фермер егетен дә иярткән. Ул да түгел, икәүләшеп минем өстәлне сый-ниг ъмәтләргә дә күмеп өлгерделәр. «Әйдәгез әле, хөрмәтле язучылар, бер киңәшмә кебегрәк чара уздырып алыйк әле ошбу чәй өстәле янында, Буада элек театр булган, шуны кире торгызасы иде», – ди. Аның киләсен белгәнгә, Мансур Гыйләҗевне, Ләбиб Леронны, Ркаил Зәйдулланы, Искәндәр Сиражины да чакырган идем. Күбебез: «Бүгенге авыр, кризис чорында нинди театр ачып булсын, эшләп торганнарын саклап калырга кирәк», – дигән тискәре фикердә. Шулай да тынгысыз, кунакчыл, янып торган егет тә кызганыч. «Әйдәгез, – мин әйтәм, – ятып калганчы атып калырга кирәк, Минтимер Шәриповичка үтенечмөрәҗәгать хаты юллыйк». Иптәшләрем: «Кулын да куярбыз, юллавын да юлларбыз, театр ачарга ярдәм итүләренә генә ышанып булмый», – диләр. Егетебез кабат кызып китә: «Туганнар, шуны аңлагыз, Чулман арьягында Чаллы, Минзәлә, Әлмәт, Түбән Чулман театрлары бар, Башкортстанның Туймазы труппасын да шул төбәккә кертеп була. Казанның үзендә генә дә өч татар театры эшли, ә менә үз эченә Татарстанның җиде

Легендар сәнгатькярләр арасында

районын сыйдырган Ульян, Түбән Новгород һәм Пенза өлкәләренә, Чувашстан һәм Мари-Эль республикаларына күрше булган Идел аръягында бер генә театр да юк! Ул төбәкләрдә йөз меңләгән татар яши бит! Соңгы елларда бармы ул якларга барып җитеп, спектакль куеп кайткан берәр профессиональ театр?! Юк! Чөнки финанслары сай, хәлләреннән килми. Барсалар да үзләренә зыянга гына эшләп кайтачаклар! Буада театр ачылса, ут күршеләргә барып кайту безгә бик җиңелгә туры киләчәк, кечкенә генә мобиль труппа булачак, ул төбәкләрдә татарлыклары сүлпәнләнә барган халыкны кабат уятачакбыз. Менә күрерсез», – дип дәлилләр китерә. Аңлавын бик яхшы аңлыйбыз да, татарларның әйдәманы Шәймиевкә төшендереп кара син шуны! Раилнең Буа театрының якты киләчәгенә ышанып сөйләве безне дә кузгатып, өмет уятып җибәрә. «Бу егет тукталып кала торганнардан түгел, ничек булса да аңа терәк булырга кирәк», – дигән фикергә киләбез. «Тик безнең татар түрәләре, җитәкче даирәләр аңлармы икән соң, сүзебезгә колак салырлармы икән?!» – дигән борчулы сорау гына баш миебезне һаман бораулый. Тик, өмет дигән нәрсә генә иң соңыннан үлә, диләр. Әле, безнең зур өметебез исән бит! Марсель Галиев кенә, гадәттәгечә кәефне төшереп: «Егетләр, мин кулын да куямын, бөтен күңелем белән дә сезнең яклы, тик театр ачтыруларына гына ышанмыйм, үпкәләмәгез, буш идеяләр белән янып йөрисез», – дип, безнең кәефне кыра. Ләкин без – Тау яклары алай тиз генә бирелә, туктала торганнардан түгел. Өстәвенә, Буа ягына Аллаһы Тәгалә, уңдырышлы җирләре белән беррәттән, булдыклы егет-кызларын да биргән. Менә бүген шуларның берсе – Раил Садриев атлысы минем кабинетта безне агартып утыра, Буа театрының мөмкинлегенә көчле дәлилләр китерә. Нәтиҗәдә, үз-үзенә ышанганлыгы, тәвәккәллеге безнең халәтебезгә дә күчә!

Иң беренче эш итеп, район җитәкчелеге белән киңәшләшергә булдык. Мин, язучылар һәм журналистлардан торган бер ныклы төркем туплап, район үзәгенә кайтып төштем. Ул елларда җитәкче булып эшләгән Әгъләм Кыям улы Садретдинов аның янына кайтачагыбыздан хәбәрдар иде. Аңа Буа хәтле Буада театр кирәклеген бик озак аңлатып торырга кирәкмәде. Ул үзе дә

Татарстан Республикасы Президенты – театр ачу тантанасында. 2007 ел, 30 март

якын көннәрдә президент белән очрашырга тиешлеген әйтте һәм безнең теләкләрне аңа да җиткерәчәген белдерде. Район җитәкчесенең дә бу савaплы эшкә хәерхаһ булуы, хәтта театр өчен бина да табып бирергә вәгъдә итүе безнең күңелгә ышаныч, ныклык өстәде. Казанга кире кайткач, утыздан артык сәнгать әһеленә кул куйдырган хатыбызны Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә юлладык. Рәхмәт, җитәкчебезгә, сүзебезгә, төпле дәлилләребезгә игътибар бирде. Озак та үтмәде, труппа муниципаль театр студиясе дигән исемгә лаек булды. «Кирәкле урында кирәкле кешеләрнең утыруы» безнең теләкләрне тормышка ашыра башлады. Ашлы, икмәкле Буа каласының мәдәният-сәнгать тарихына яңа бүлекләр өстәлде. Тау ягы башкаласындагы дини илаһи нурга илһами яктылык та өстәлде. Театрлы кала – нурлы кала ул! Озак та үтмәде, труппага элеккеге театр бинасы кире кайтарылып, төзелеш эшләре башланды. Ул чактагы премьер-министрыбыз, бүгенге көндәге Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнеханов, егерме миллион сумга тарткан төзелешкә үзе күзколак булып, кызыксынып, эш бары-

Спектакльдән бер күренеш

Театрның яңартылган бинасы

шын күзәтеп торды. Раил Садриевның тырышлыгы, үҗәтлеге, район, республика җитәкчелегенең хәерхаһлыгы аркасында, бүгенге көндә үзәкнең иң матур җиренә урнашкан гүзәл сәнгать сараебыз бар!

Театр бинасының ачылышына 2007 елның 30 мартында Республика җитәкчелеге дә килде. Президентны сәхнәгә илнең киләчәге булган балалар җитәкләп алып менде. «Театрны барлыкка китерүчеләргә ихлас рәхмәтемне җиткерәм, уңышлар, чәчәк атуларын телим!» – дип, Минтимер Шәрип улы бүләккә алып килгән автобусның ачкычын театрның директоры Фәрит ага Садриевка тапшырды. Шулай итеп, 2007 елның 30 марты Буа театрының кабат ачылган көне булып санала. Әлбәттә, театрларга юл ярып атлап китүе беркайчан да җиңелләрдән булмаган. Артистларга, акчага, профессиональ хезмәткәрләргә кытлык кичерү шундук үзен сиздерә. Иҗат төркемнәренең һәрберсе дә үз мөмкинлекләреннән чыгып кына хәрәкәт итә ала. Раил Илдар улы ошбу халәттән чыгып эш итә башлады, шул ук вакытта театрның үз юлын, юнәлешен дә табарга кереште. Аңа хәтле Раил, КВН командасы белән сатира-кәмитләр уйнап, Грант яулаган иде. Театр репертуары да, аның җитәкчелегендә яңа юнәлеш алып, сатира-юмор бизәлешендә кузгалып китте. Аманулланың «Кырыкта да кытыклый», Илфак Шиһаповның «Исерек айныса, хәерче баеса» кебек көлкеле әсәрләре, Данил Салиховның «Киллер», Ләбиб Леронның «Бәхеткә биш минут калгач», «Кычыткан чыпчыгы» һәм Рәдиф Сәгъдинең «Алсу томан», «Утын пүләне» кебек җитди драмалары да ошбу сәхнәдә дөнья күрде. Азат Зарипов, Исламия Мәхмүтова һәм Раил Садриевлар тарафыннан сәхнәләштерелгән, халыкның үзе кебек җор телле, үткен сатиралы тамашалар Ульяновск, Чувашстан һәм Пенза якларына барып җитеп, олы татар сәнгатеннән онытып барган татарларга милли әсәрләр тәкъдим итә башлады. Шул ук вакытта театр училищесына, Сәнгать академиясенә конкурслар үткәреп, бер төркем талантлы яшьләр укырга җибәрелде. Бүгенге көндә алар да инде җитлегеп барган театр актерлары. Раилнең тагын бер зур таланты бар. Ул – менә дигән рәссам! Аның Буадагы фатирын дистәләгән үзенчәлекле, фәлсәфи-субъектив картиналар бизи. Раил Садриевның югары сәнгатькә гашыйклыгы театр диварларында да ярылып ята. Ул яңалык тудырырга тырышып иҗат итә, ялгыша, төзәтә, тырыша, омтыла, ләкин халыкка хезмәт итүен тыелгысыз ыргым белән дәвам итә! ■

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

РӨШДИ, РӨШДИЯ *г.* – 1917 елгы инкыйлабка кадәрге Россиядә урта мәктәп. Элекке мәдрәсәләрдә «рөшди сыйныф» шәкертләрен үз араларында «касмак» дип йөрткәннәр. *//Ибтидаи вә рөшди мәктәпләр гыйлемгә түгел, бәлки гамәлгә, тормышка хезмәт итәләр.* Җамал Вәлиди.

Кара: Рөшед, 2.

РУБРУК, ГИЛЬОМ яки ВИЛЬҺЕЛЬМ/ВИЛЛЕМ (латинлаштырылган формасы: Рубруквис) – Франция короле Людовик IX 1253 елда Монголиягә җибәргән миссия җитәкчесе, алтынчы тәре явына катнашкан монах. 1215-1220 еллар арасында Фламандиядә туган – 1270 ел тирәсендә вафат булган. (М.Глуховның «Казань. Ретролексикон»ында Рубрукның вафат булган елы итеп 1290 ел күрсәтелә.) Рубрук 1253-1255 елларда ясаган сәяхәте турында зур хезмәт язып калдыра, анда болгарлар, кыпчаклар турында да мәгълүматлар бар. «Көнчыгыш илләренә сәяхәт» дигән китабында ул Бөек Болгариянең Ислам иле булуын белгәч: «Шуңа шаккатам, монда Мөхәммәд канунын кайсы иблис алып килде икән?» – дип яза һәм болгарларның «иң яман сарациннар» икәнлеген, Мөхәммәд канунына башкаларның барысыннан да ныграк «тотынган» булуларын әйтеп китә.

Монголларның Каракорым шәһәрен без фәкать Рубрук язмаларыннан гына күз алдына китерәбез. Рубрук Каракорымда чагында монда Мункә хан хозурына төрле дин миссионерлары вәгазьләргә килгән. Чыганакларга караганда, христианнарның вәгазе уңышка ирешмәгән, ә буддизм өстенлек алган, дип уйларга туры килә.

Сәяхәтеннән кайткач, Рубрук озак еллар Сүриядә яши, аннары, рөхсәт алып, Парижга кайта.

РУМ – Византия, Кече Азия, поэзиядә – барлык көнбатыш илләре. *Румистан* да дигәннәр. Фарсы әдәбиятында румлылар, ак раса вәкилләре буларак, ак төс, көн символы, ә эфиоплар – кара төс һәм төн символы булган. Татарда очрый торган *Румил-Румилә* исеме, ахыргы исәптә, Борынгы Рим шәһәренә нигез салучы Ромул исеменә барып тоташа. Ә гомумән *Руми* сүзе борынгы Грециягә һәм Византиягә баглы.

РУМИ, ҖӘЛӘЛЕТДИН (1207-1273) – Мәүләвиләр яки башкача «Әйләнчек суфилар» («Әйләнчек дәрвишләр») мәзһәбенә нигез салучы. Нәсел шәҗәрәсе Әбүбәкер хәзрәткә барып тоташа. Әтисе *Баһаветдин дивана* кушаматын йөрткән («Бакырган китабы», Казан, 2000). Хәзерге Төркиядәге Конья шәһәрендә (аны Идрис Шаһ Икониум/Рум шәһәре дип атый) яшәгән. «Руми» дигән псевдонимны ул

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

Руми, Җәләлетдин

бу сүздәге хәрефләрнең санлы эквиваләнтлары суммасы 256га тигез булып, «Нур» сүзенә туры килгәнгә алган, диләр. *Мәулана* («Әфәндебез») кушаматы белән дә билгеле.

1244 елда Тәбриздән килгән бер серле дәрвишне – Мәһмәд Шәмсетдин Тәбризине ул үзенең остазы дип саный. Бу дәрвиш аны өч ел буе өйрәткәннән соң гаип була, ахырда аның үле гәүдәсен Мәүлана өеннән ерак түгел бер коедан табып алалар. Руми аны суфиларның серле җитәкчесе Хозыр пәйгамбәрнең үзе булган, дип уйлый. Хәзер мәгълүм булганча, Тәбризинең Җәләлетдин Румига көчле йогынты ясавын күргән Конья халкы дәрвишкә кырын карый башлый һәм аны үтерүдә Җәләлетдин Руминың икенче улы Галәветдин дә катнашкан була. Моны күңеле белән сизгән Руми гомере буе Галәветдин турында ишетергә дә теләми.

Шушы вакытларда Руми шагыйрь осталыгына ирешә, ләкин шигъриятне ул фикерне чагылдыру чарасы дип кенә карый.

Руми үзенең алты җилдле «Мәснәви-и мәгънәви» («Яшерен мәгънәле мәснәвиләр») поэмасы белән дан казана. Ил монголлар тарафыннан басып алынгач, Руми, халыкның чит ил баскыннарына каршы булуын аңлату өчен, шигырьләрен төрки телдә яза башлый. Дөрес, аның бу шигырьләре форма һәм тел ягыннан элгәргеләреннән кайтыш, аларда хәтта грамматик ялгышлар да еш очрый. Руминың мәснәвиләре һәм лирик шигырьләре *Һибәтулла Салихов, Утыз Имәни, Шәмсетдин Зәки* кебек татар шагыйрьләренең иҗатына да сизелерлек йогынты ясаган.

Җәләлетдин Руминың улы Солтан Вәләд тә (1226-1312) төрки телнең антала-огуз шивәсендә шигырьләр язган.

Руми бер әсәрендә Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) тарафыннан әйтелгән сүзләрне китерә: *«Хәкимнәрнең яманы хакимнәр катына барыр, хакимнәрнең асылы хәкимнәр хозурына килер»*.

Җәләлетдин Руми Коръән аятьләре аллегорик эчтәлекле, ә Коръән үзе җиде төрле мәгънәгә ия, дип санаган. Аның фарсы телендә язылган әсәрләрен, шигъриятле һәм мистик эчтәлеге өчен, «Пәһләви телендәге Коръән» дип тә атаганнар. Ләкин Руми үзе Иранда өстенлек иткән шигыйчылыкка тискәре мөнәсәбәттә була.

Түбәндәге тәрҗемәдә Руминың төрле диннәргә карашын чагылдырган фикерләре бер ноктага тупланган: *«Мин хачны да, нәсариларны да кямилән тикшердем. Хачта Ул юк иде. Мин һиндуси гыйбадәтханәдә һәм борынгы пагодада булдым, тик анда да Аның эзләре юк иде. Мин Һиратка һәм Кандаһарга тикле бардым. Мин эзләдем. Астта да, өсттә дә юк иде Ул. Тәвәккәлләп, Каф тавына барып җиттем, әмма анда да Ганка кошын гына таптым. Кәгъбәгә киттем. Анда да Ул юк иде. Мин Аның турында Әбугалисинадан белештем, әмма Ул Әбү Гали ибн Сина*

фәлсәфәсеннән югарырак иде... Шуннан мин үз кальбемә күз салдым. Мин Аны шунда күрдем, ә башка бер генә җирдә дә Ул юк иде...» Монда оригиналдагы «Ул» дигән сүзне хакыйкый чынбарлык, асылда Аллаһ дип аңлау тиеш.

Руминың мистик гыйлемгә мөнәсәбәте аның әсрләреннән алынган түбәндәге өзекләрдә ачык чагыла:

– *«Күренмеш әйтер: менә ул мин, башка берни дә эзләмә, – дияр; яшерен өйрәтер: әйбәтләбрәк кара һәм игътибар белән күзәт! – дияр. Күренмеш моны инкяр итәр: әчкәредә берни дә юк, – дияр. Яшерен әйтер: түзем бул, мин сиңа барын да күрсәтермен, – дияр».*

– *«Көне-төне Диңгез күбекләнеп тора. Ни кызганыч, син күбекне күрәсең, әмма Диңгезнең үзен күрмисең».*

– *«Шуны бел, рух – океан ул, ә тән – аның күбеге генә».*

– *«Канун чырак кебидер. Чыраксыз син алга бара алмыйсың. Әгәр юлга чыккансың икән, синең хәрәкәтең Юлың булыр. Ә инде максудыңа барып җиткәч, Хакыйкать тә шул булыр. Канун – белем ул, Юл – гамәлләрең, ә хакыйкать – Аллаһка ирешү».*

– «Аллаһ сиңа ифрат якындыр. Уйларың яки күзаллавың нинди генә булмасын, аның артында ук Аллаһ үзе тора. Әмма Ул шулкадәр якын. Һәм син Аны күрә алмыйсың. Монда гаҗәпләнер урын бармыни?.. Син акылны күрә алмыйсың. Аның тәэсиренең нәтиҗәләре күз алдында булса да, син аның асылын күрә алмыйсың» .

Аңлаешсыз вакыйгаларның чын мәгънәсенә төшенү суфи үсешенең бер нәтиҗәсе булып тора. Мәс., ни өчен мистик хәзерлекнең аерым фазалары берәүләрдән шактый вакыт сорый, ә икенче берәүләр, кагыйдәләрне җентекләп үтәп җиткермәсәләр дә, моңа тизрәк ирешәләр? Моны аңлату өчен Руми түбәндәге мисалны китерә: *«Ике хәерче бер өйнең ишек катына килә. Боларның берсенә шундук ипи сыныгы чыгарып бирәләр һәм ул китеп бара. Икенчесен исә шактый көттерәләр. Ни өченме? Хәерчеләрнең беренчесе хуҗаларга бик үк ошамый һәм аңа каткан ипи тоттыралар. Икенчесенә исә аның өчен яңа ипи пешергәнне көтәргә туры килә».* Бу хикәйят тә һәр вакыйгада безгә билгесез берәр нәрсә булганлыгын сурәтли.

Суфилар теләсә кайсы дин остазының иманы һәм бигрәк тә аның тормыш юлы суфичылык юлларының бер аспекты дип карыйлар. Руми Иисусның (Гайсәнең) юлы ялгызлык белән көрәш һәм бәдәни нәфес омтылышларын җиңү юлы дигән. Ә менә Мөхәммәднең юлы гадәти кешеләр арасында яшәүне таләп иткән. *«Мөхәммәд юлы белән бар, ә инде булдыра алмыйсың икән – нәсарилар юлына басарсың»*, – дип яза Руми.

Ул кешеләр өч стадия үтәләр, дип саный. Беренче стадиядә алар теләсә кемгә яки теләсә нәрсәгә – ир кешегә, хатын-кызга, акчага, балаларга, җиргә яки ташларга табыналар. Беркадәр үсешкә ирешкәч, алар Аллаһка табына башлыйлар. Ниһаять, кешеләр инде: «Без Аллаһка табынабыз» яки «Без Аллаһка табынмыйбыз», – димиләр. Алар ахыргы стадиягә килеп ирешкәннәр. Моны камиллекнең соңгы баскычында кеше Аллаһ белән кушылышкан була, дип аңларга кирәк.

Руми вафат булгач, аны соңгы юлга озата килүчеләр арасында төрле диндәге кешеләр була. Шунда бер нәсаридан: *«Син нигә мөселман остаз җеназасында бу кадәр җылыйсың?»* – дип сорагач, ул: *«Без аны заманыбызның Моисейы, Давиды һәм Иисусы кебек хөрмәт итәбез. Без барчабыз да аның тарафдарлары һәм аның шәкертләре»*, – дигән.

Җәләлетдин Руминың төрбәсе Конья шәһәрендә. Төрбәнең гөмбәзе очлы чатыр рәвешендә. Төрбәдә Руминың кульязмалары һәм шәхси әйберләре, суфилар кулланган музыка кораллары, тәсбихләр һ.б. саклана. Аның шәкертләренең каберләре дә шушында ук. Һәр кабер өстендә дәрвишләрнең биек чалмасы тора. ■

«Мирас», № 7-8, 1995 ел

Милли яңарыш һәм телдәге яңа сүзләр

Малик Хәйруллин

Хәзерге болгавыр заманда милләтара, телара мәсьәләләр катлаулы проблемага әйләнде. Милли мәсьәләләрне, телара проблемаларны хәл иткәндә демократик принциплардан чыгып эш ителми. Бу уңайдан Россиядә, якын һәм ерак чит илләрдә милли үзаңның үсеше, икътисади мөстәкыйльлеккә омтылыш исәпкә алынмый.

Хәзерге икътисади тотрыксызлык, тормышыбызның сәясиләшүе чорында, икътисади базисның үзгәрүе дәверендә телебездә яңа сүзләр һәм терминнар барлыкка килә, иске сүзләргә яңа мәгънә төсмере өстәлә, яңа алынмалар телгә кертелә.

Аерым алганда, татар, башкорт һәм башка төрки телләрдә, кайбер башка системадагы телләрдә дә «мәҗлес», «корылтай», «хосусыйлаштыру» («приватизация»), «базар икътисады», «сәяси кискенлек» («политическая конфронтация»), «социаль шартлау» («социальный взрыв»), «партократия», «авторитарлык» («авторитарность»), «күренеш» («феномен»), «килешү» («консенсус»), «инфляция», «репатриация», «экстремист», «компенсация», «берлек» («союз»), «хастаханә», «сырхауханә», «шифаханә», «ваучер», «менеджер», «кәсәбәче» һ.б.ш. сүзләр активлашып китте.

Терминология үсешендә, камилләшүендә телнең потенциаль мөмкинлекләреннән чыгып эш итәргә кирәк. Шул җәһәттән, лексик системага ятышып торган милли вариантлар телгә яңадан әйләнеп кайтты: «Верховный Совет» урынына «Югары Совет», «съезд» урынына «корылтай», «интеллигент» урынына «зыялы», аерым очракта исеме, атасының исеме белән дәшү урынына «ханым», «әфәнде», «туташ» сүзләре куллану, «иптәшләр» урынына «ханымнар», «әфәнделәр» дип мөрәҗәгать итү һ.б.ш.

Ләкин хәзерге этапта да телдә бөтенләй алынмалардан башка эш итеп булмый. Бу табигый халәт милләтләр, халыклар, зур булмаган этник төркемнәр арасында гасырлар дәвамында яшәп килә торган икътисади, сәяси, дипломатик, мәдәни, рухи, дини багланышлар белән аңлатыла, дәлилләнә.

Урыс сүзе, интернациональ сүз генә булмасын дип, телдә гарәп-фарсы, төрек сүзләрен дөрес кулланмау, яки тиешсез урында куллану максатка ярашлы түгел: «могтәбәр» («информатор») сүзен «мөхтәрәм» («хөрмәтле») мәгънәсендә, «тәгъбир» сүзен «тәкбир» («Аллаһны данлау») урынында, «хач» («тәре») сүзен «хаҗ» («паломничество») урынында, «шәһит» сүзен «шаһит» урынында яки киресенчә.

Халыклар арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең киңәюе һәм тирәнәюе телләрнең бер-берсен баетышуына китерә, бер үк системадагы һәм төрле системадагы телләрдә дә охшаш лексик-терминологик фонд барлыкка килә. Бу объектив күренеш тормышның төрле өлкәләрендә бара торган интеграция процессы белән, телләрнең функциональ һәм структур үсеше закончалыклары белән бәйләнгән.

Фән һәм техника казанышлары телләр үсеше һәм камилләшүенә уңай тәэсир итә. Әмма биредә экстралингвистик һәм лингвистик факторларның органик, диалектик бөтенлегенә ирешергә кирәк.

Суверен дәүләтләрнең хәзерге икътисади, сәяси мөстәкыйльлеккә омтылышы чорында, милли үзаңның үсеше, милли тел традицияләренең саклануы чорында телгә яңа сүзләр, терминнар кабул иткәндә мәдәни-этник, икътисади, сәяси һәм демократик факторларны күздә тотып эш итәргә кирәк.

Хәзерге вакытта тормышның иҗтимагый-социаль, милли тел һәм фәнни-техник өлкәләрендә зур үсеш, зур үзгәреш процессы бара. Үзгәрешләр Берләшкән Дәүләтләр Берлеге илләрендәге, Көнчыгыш Европа һәм дөньяның башка регионнарында иҗтимагый-икътисади хуҗалык уклады, милләт һәм тел мөнәсәбәтләре белән бәйләнгән. Әлеге үзгәрешләр, деформацияләр, бигрәк тә БДБ илләрендә, үткәндәге социализм лагере илләрендә милли мәсьәләләр югарылыгында калку чагылыш таба. Бер яктан, икътисад өлкәсендә дәүләт монополизмыннан баш тарту, базар мөнәсәбәтләренә күчү хәзерге яңарыш чорында мәдәниятнең, фәннең, шул җөмләдән милли телләр үсеше мәсьәләләрен дә кыен финанс хәленә куйса, икенче яктан, фәнни-техник потенциал үсеше зарурияты (чөнки фән-техника үсешеннән башка икътисадның, җәмгыятьнең алга таба үсеше мөмкин түгел) төрле милләттәге, төрле телдәге халыклар арасында бәйләнешләр урнаштыру кирәклеген көн тәртибенә китереп куя. Ә бу хәл, үз чиратында, телләрнең бер-берсен баетышуына, аларда акрынлап күпмедер дәрәҗәдә гомум лексик-фәнни терминологик фонд хасил булуга китерә.

Фән һичкайчан да изоляциядә үсмәгән, хәзер дә үсми һәм ул региональ масштабларда гына да үсә алмый. Фәннең үсешенә, гомумән, интернациональлек хас, ягъни биредә төрле төбәкләрдәге, ареаллардагы фәнни-техник казанышлар берләштерелә, төрле структурадагы телләрдә иҗтимагый-социаль һәм лингвистик законнар хәрәкәткә килә. Бу хәл лингвистика фәнендә дә, телләр үсеше өлкәсендә дә шулай тора. Шуңа да, әлеге җәһәттән, телдә интернациональ фәнни-техник терминология дә үзенең лаеклы урынын ала.

Фәнни-техник инкыйлаб, бер яктан, кардәш булмаган, төрле системадагы телләрнең үзара тәэсир итешүенә китерсә, икенчедән, информацион шартлау чорында телләрдәге фәнни терминологиянең чагыштырмача стандартлаштыруына китерә.

Әгәр телдәге яңа фәнни-техник терминнар бары тик бер тел җирлегендә генә ясалса, бу хәл тел үсешендә, фәнни терминология үсешендә торгынлыкка, төрле телләрдәге терминнарның төрлечә кулланылышына зур зарар китерер иде. Шуңа күрә терминология өлкәсендә диалектик законнардан чыгып эш итәргә, аларны файдалануда чын милли һәм чын алынма сүзләрнең диалектик бөтенлегенә ирешергә кирәк. Химия, физика фәннәрендә генә дә берничә дистә мең алынма фәнни-техник терминнар актив кулланылышта йөри.

Бик күп яңа терминнар биологиядә, кибернетикада, астрофизикада, генетикада, механикада, кыскасы, бик күп гуманитар, иҗтимагый, техник, табигать фәннәре өлкәсендә барлыкка килә, үзгәрә, камилләшә. Бу терминнар арасында, нигездә, уңышлы ясалган, төрле системадагы, төрле структурадагы телләр тарафыннан кабул ителгән, үзләштерелгән терминнар зур урын алып тора. Уңышсыз, төгәл булмаган фәнни-техник терминнар да очраштыргалый. Андый терминнар бер телдән икенчесенә, өченчесенә тәрҗемә иткәндә зур буталчыклар, аңлашылмаучанлыклар китереп чыгара. Яңа фәнни-техник, иҗтимагый-социаль терминнарны пуристик нигездә генә ясарга омтылу, алынмалардан бөтенләй файдаланмау үзизоляциягә алып бара, ә ул фәнни интеграция процессына каршы килә.

Д.С.Лотте бик хаклы рәвештә билгеләп киткәнчә, фәнни-техник терминнарның дөреслеген ачыклаганда

аларның фонетик, морфологик, лексик-семантик үзләштерелүе, фәнни төгәллеге (ә аларның генетикасы түгел) төп критерий булып санала ала.

Һәрбер милли телдә саф милли һәм алынма фәнни-техник терминнар да гамәлдә йөри. Алынма терминнар һәм милли, һәм гомум милли лексик байлык булып санала. Чөнки аларның нигезләре гомум, ә ялганган кушымчалар милли тел спецификасыннан килеп чыга: «компенсация-лән-гән-лек-тән», «ватан-дар-лы-гы-быз-га», «пессимист-лык-тан» һ.б.ш.

Халыкара сүзләрнең парадигматикасы, синтагматикасы, шул исәптән гомум лексик фәнни интернационализмнарның үзләштерелүе дә социаль-лингвистик факторлар, аерым милли телләрнең структур үзенчәлекләре белән аңлатыла. Мәсәлән, «робот», «компьютер», «компьютерлаштыру», «реконструкция», «модернизация», «стабиль», «психотерапия», «микроклимат», «дискомфорт», «реалия», «унитар», «партократия» кебек сүзләр бик күптөрле системадагы телләрдә лексик-семантик, фонетик планда охшаш, ә аларның структур-грамматик элементлары аерым милли телләрдә морфологик планда миллиләшә. Мондый лексик берәмлекләрнең морфологик үзләштерелү дәрәҗәсе тышкы һәм эчке, иҗтимагый-социаль һәм тел факторларына бәйле.

«Робот», «компьютер», «транзистор», «регистр», «хәбәрдарлык», «факс», «телекс» кебек терминнар бик күп сандагы төрле структурадагы телләргә үтеп керде. Кайчандыр «атом», «газ», «йод» сүзләре һәм алардан ясалган сүзләр бик күп телләргә үтеп кергән иде.

Телнең лексик системасында тулысынча яки өлешчә интернациональ терминнардан аерылып тора торган омоник полилексемалар да бар: «коммутатор», «дивизия», «мотор», «идеаль», «нормаль» һәм башкалар. «Концепция», «феномен», «инфляция», «конверсия» сүзләренең дә төрле телләрдәге чагылышы төрлечә булырга мөмкин. «Нормаль» сыйфаты математик текстларда «нормаль», ә кайбер вакытларда «перпендикуляр» мәгънәсенә туры килә. Ә «коммутатор» сүзенең алман, инглиз, урыс телләреннән татарчага тәрҗемәсе «коммутатор», «коллектор», «күчереп ялгагыч», «күчергеч», «переключатель» мәгънәләреннән гыйбарәт булачак.

Фәнни-техник әдәбиятны тәрҗемә итүне яхшырту йөзеннән, чын интернациональ һәм псевдоинтернациональ сүзләрне бутамаска, сүзләрнең күп мәгънәлелеге, төрле стильләрдә төрлечә кулланыла алу мөмкинлекләреннән чыгып эш итәргә кирәк.

Тулаем алганда, халыкара фәнни-техник төшенчәләр телләрдә уңышлы алынмалар, аларга ялганган морфемалар, префикслар, суффикслар ярдәмендә белдерелә. Алар фәнни әдәбиятта, дәреслекләрдә, сүзлекләрдә зур урын ала. Мәсәлән, алманча-урысча химия терминнары сүзлегендә халыкара фәнни терминнар – 39%, инглизчә-урысча физика терминнары сүзлегендә – 37%, урысча-татарча биология терминнары сүзлегендә – 45%, урысча-башкортча математика терминнары сүзлегендә – 34%, инглизчә-урысча сүзлектә – 39,5%, алманча-урысча сүзлектә 37,8% тәшкил итәләр.

Төрле структурадагы телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, тел тарафыннан үзләштерелгән, уңышлы, фәнни төгәл, дөрес терминнар белән беррәттән, уңышсыз сүзләр дә күренеп китә. «Газ кертү», «дегазация», «диспропорция», «симметрия», «ассимметрия», «контракт», «антитеза», «аргументлаштырылган», «компенсация», «компенсацияләнгән» кебек уңышлы яңгырашка ия терминнар белән беррәттән «индуктивлык», «мотор» тибындагы сүзләр дә йөри. «Коэффициент самоиндукции» алман, инглиз, урыс телләреннән тәрҗемә иткәндә йә «индуктивлык», йә «үзиндукция коэффициенты» дип тәрҗемә ителә. Биредә барлык телләрдә дә «үзиндукция коэффициенты» төшенчәсен калдыру максатка ярашлы булачактыр. «Мотор» сүзе кайбер текстларда – «мотор», ә кайберләрендә – «двигатель»гә туры килә. Кайбер очракларда биологик терминнардан «рацион», «режим» сүзләрендә аныксызлыклар

киткәли. Фәнни-техник, иҗтимагый-сәяси терминнарның барлыкка килүендәге, таралуындагы төгәлсезлекләр телнең потенциаль мөмкинлекләреннән файдаланып бетермәү белән аңлатыла.

Яңа фәнни терминнарны ясауда, куллануда түбәндәге моментлардан чыгып эш итәргә кирәк:

1) терминнарның гомум мәгънәгә ия булуын, халыкара әйләнештә йөрүеннән чыгып, чагыштырмача реаль унификациягә омтылу зарури;

2) фәнни-техник халыкара сүзләр «машина тәрҗемәсе»н («машинный перевод»), табигый һәм ясалма халыкара телләрне интенсив үзләштерүгә ярдәм итәчәк;

3) фәнни терминнарны дифференцияциялəүдә гомум интернациональ үзәкне калдырсаң яхшы, аларның телләр тарафыннан үзләштерелүе морфологик категорияләр бирелешенә кайтып кала.

Элеккеге социализм лагере илләре, БДБ дәүләтләре, Россиянең милли республикалары урынында суверен җөмһүриятләр барлыкка килү процессы милли мөнәсәбәтләргә, тел мәсьәләләренә, аның лексикасының баюына, яңаруына, миллиләшә төшүенә уңай йогынты ясый. Шулай да, хәзерге милли яңарыш чорында бер яктан икенче якка ташлану да сизелә. Бер яктан, телебездә «корылтай», «мәҗлес», «фирка», «вәкаләт», «рәис», «вазгыять», «җөмһүрият», «мөхәррир», «мәдәният», «сәясәт», «икътисад», «тәрәккый», «инкыйлаб», «зыялы», «хакимият», «берлек», «намаз», «Рамазан», «Коръән», «хәдис», «вәгазь», «мәдрәсә», «шәкерт», «ишан», «сәдака», «хәйрия», «җәмгыяте хәйрия» кебек сүзләр актив кулланыла башлады, телне баетуга, аның лексикасын төрле стильләргә яраклаштыруга зур өлеш кертте. Әмма моңа карап кына әлегә кадәр кулланылышта йөргән сүзләрне дә төшереп калдырырга ярамый. Мәсәлән, «республика», «редактор», «экономика», «врач», «медсестра» сүзләреннән бөтенләй баш тартып, «җөмһүрият», «мөхәррир», «икътисад», «табиб», «имче», «шәфкать туташы» дип кенә калдырып булмый. Мондый типтагы сүзләр, стиленә карап, янәшә кулланылышта йөрергә тиеш.

Әйтик, «мәдәният министры», «мәдәният институты», «мәдәният йорты» дип әйтеп булса да, «үз-үзеңне тоту мәдәнияте» («үз-үзеңне тоту культурасы»), «ашау мәдәнияте» («ашау культурасы» урынына), текстны «мөхәррирләү» («редакцияләү» урынына) дип әйтеп булмый.

Урыс теленнән, Көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләрдән качып, барысы да гарәп-фарсы, татар-төрки сүзләре булсын, дигән караш та тормыш хакыйкатенә каршы килә, чөнки халык кабул иткән, тел төзелеше тарафыннан үзләштерелгән сүзләр телдә сакланып калырга тиеш.

Иҗтимагый-сәяси, икътисади, мәдәни-рухи вакыйгалар тел үсешенә, андагы сүзләр даирәсенә йогынты ясамый калмый. Милли уяну, милли яңарыш чорында яңа иҗтимагый, сәяси, икътисади, мәдәни, дини төшенчәләр барлыкка килә, мәдәни-рухи тормышка караган үзгә мәгънәләр дөнья күрә.

Иҗтимагый-сәяси тормышта үзгәртеп кору чорында шактый яңа төшенчәләр туды: деполитизация, десоветизация, деидеологизация күренешләре үзгә сүзтезмәләрдә чагылыш тапты. Мәсәлән, республика, ил исемнәрендәге «совет», «социалистик» сүзләре төшеп калды һәм сүзтезмәләр икенчерәк мәгънә төсмере алды: Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе, Украина, Беларусь, Казакъстан республикалары, Берләшкән Дәүләтләр Берлеге һ.б.

«Республика» сүзе ике синонимик вариантта кулланыла башлады: «республика» һәм «җөмһүрият». Икесе дә алынма сүз. «Республика» сүзе латин теленнән кереп, башка телләргә таралган. Бу сүзнең латин теленә борынгы төрки этруск теленнән үтеп керүенә ышансак, аның төрки-татар теленнән кысрыкланып чыгарылырга тиешлеге фәнни дөреслеккә һич туры килмәячәк. «Җөмһүрият» сүзе гарәп теленнән төрки телләргә дини-мәдәни бәйләнешләр җирлегенә үтеп кергән. Рәсми стильдәге әдәбиятта, Конституциядә,

публицистик телерадиотапшыруларда «республика»ны калдыру фәнни дөреслеккә туры килсә, «җөмһүрият» поэзиягә, сөйләмгә, әдәбиятка ятышлырак кебек күренә. Терминнарны бу рәвешле куллану сүзләрне функциональ-стилистик һәм этимологик-генетик законнар тәңгәллеге җирлегендә куллану белән аңлатыла.

«Политика» сүзен «сәясәт» алыштырды. Монда да «политика» сүзеннән тулысынча баш тартмаска кирәктер, кайбер очракларда, стиленә туры китереп, латин теленнән кергән «политика»ны куллану да хәерле. Дөрес, гарәп теленнән алынган «сәясәт» сүзе, «җөмһүрият»тән аермалы буларак, тел тарафыннан шулкадәр нык үзләштерелгән ки (ул татар теленең үз сүзе кебек үк лексик-семантик мәгънә бөтенлегенә, яңгырашка ия, телнең морфологик хосусиятенә хас кушымчалар ала, сингармонизм законына буйсына), аны рәсми документларда, Татарстан Конституциясе текстында да калдырырга кирәк. Инде кабатлаудан котылу өчен, термин буларак түгел, ә гомумән сүз варианты буларак, сөйләмдә «политика»ны да кулланырга ярый.

Икътисад өлкәсендә дә яңа сүзләр күренә башлады. Гарәп теленнән алынган «икътисад» сүзе инглиз теленнән кергән «экономика» урынына кулланыла башлады. «Икътисад» сүзе кулланылу ешлыгы ягыннан «экономика»ны әллә кайда калдырып узып китте: икътисад яңалыклары, икътисади читенлекләр, икътисад фәннәре докторы һ.б. Кабатланулардан котылу өчен, сүз буларак «экономика»дан да баш тартмаска кирәктер. Ә термин буларак рәсми документларда, Татарстан Конституциясе текстында «сәясәт», «икътисад» тарихи терминнарын калдырырга кирәк, чөнки алар элек тә татар телендә актив кулланылышта йөргәннәр, бары вульгар социологизм заманында гына телдән төшереп калдырылганнар. Тагын да икътисади тормышка нисбәтән «базар икътисады», «хосусыйлаштыру», «керем», «кертем» («вклад») сүзләре телдә активлашып китте. Базар икътисады шартларында мондый сүзләрнең активлашуы үзеннән-үзе аңлашыла.

Сүзләрнең милли вариантлары телнең лексикасына бик тиз үтеп керә, нәтиҗәдә яңачарак төшенчәләрне белдерүче яңа сүзтезмәләр һәм сүзләр хасил була: «туңдырма кибете», «сәүдәгәр кереме», «эшмәкәр кертеме», «җинаятьле вазгыять», «шартнамә», «рөхсәтнамә» («виза»).

Мәдәни-рухи үзгәрешләр дә, һичшиксез, телнең сүзлек хәзинәсе баюына уңай йогынты ясый. Бу җәһәттән туган яисә телгә әйләнеп кайткан сүзләр, төшенчәләр мәдәниятка яңача караш, дингә, гореф-гадәтләргә, традицияләргә яңа мөнәсәбәт белән бәйләнә: «мәдәният хезмәткәре», «зыялы», «милләтпәрвәр», «милләтче» һ.б. Әйтелгәнчә, «мәдәният» сүзенең кулланылу ешлыгы бик нык артып китте, ул хәтта заманында борынгы этруск теленнән латин теленә, аннан Европа телләренә, урыс теленә, урыс теленнән төрки телләргә (шул җөмләдән татар теленә дә) күчкән һәм уңышлы кулланылып килгән «культура» сүзен кысрыклап чыгару дәрәҗәсенә җитте. Бу сүзнең һәрберсе стиленә карап кулланырга тиеш: «борынгы мәдәният», «мәдәният йорты», «мәдәният хезмәткәре»; ләкин: «авыл хуҗалыгы культуралары», «бодай культурасы», «язу культурасы».

Ислам диненә нисбәтән күп кенә сүзләр телдә актив кулланыла башлады: «хәзрәт», «мөдәррис», «иман», «мәдрәсә», «Рамазан», «намаз», «хаҗ», «иманыбызга кайту», «иман яңарту», «аять», «сүрә», «дин тарихы», «мөфти», «Диния нәзарәте» һ.б.

Дингә уңай мөнәсәбәт җирлегендә телгә дини-әхлакый сүзләр дә чагыштырмача күпләп үтеп керде: «дини тәрбия», «гөнаһлардан тәүбә итү», «пакьләнү», «арулану», «гамәл кылу», «хәрәмнән тыелу», «ураза тоту», «корбан чалу», «сәдака өләшү», «калеб (йөрәк) сафлыгы», «иманына (ышанычына) тугрылыклы булып калу» һ.б.

Җәмгыятьтә бара торган милли хәрәкәт үсеше хәзерге милли яңарыш чорында шулай ук телдә чагылыш тап-

ты: «милли мәнфәгатьләр», «милли бәйсезлек партиясе», «Азатлык» яшьләр берлеге» һ.б.

Мәгариф системасында да яңарыш үзен сиздермичә калмады, яңа сүзләр, сүзтезмәләр, төшенчәләр, яңачарак фикерләү пәйда булды: «милли мәктәп концепциясе», «милли мәгариф ассоциациясе», «дәресханә», «мәдрәсә», «сыйныф» («уку классы» мәгънәсендә). Әмма телебездәге барлык сүзләр дә милли, яңача булсын дип, төрки телләрдән, татар теленнән булмаган гарәп-фарсы алынмаларын чиктән тыш куллану (чит тел, урыс сүзләрен кысрыклау бәрабәренә) шулай ук файдага түгел.

Хәлбуки, без хәзер һичничек «геометрия»не – «һәндәсә», «математика»ны – «риязият», «авыл хуҗалыгы»н – «зираат», «начальник»ны – «түрә», «башлык», «совет»ны – «шура» дип сөйләшүгә күчә алмыйбыз.

Хәзерге милли яңарыш, милли хәрәкәтнең үсеше сизелерлек дәрәҗәдә күтәрелеп килгән, милли үзаң үсә төшкән, милли психология уңай якка үзгәргән, милли телләр, аларның сүз байлыгы баеган, яңарган чорда 1) телдә яңа сүзләр, яңа төшенчәләр, яңа терминнар пәйда була, иске сүзләр яңа мәгънә ала; 2) фәннитехник терминнар, халыкара сүзләр дә киңрәк позициядән чыгып карала: татар теленең, төрки телләрнең үз сүзләре дә бүтән телләргә үтеп кереп интернациональ функция башкара башлый: «корылтай», «мәҗлес», «җыен», «берлек», «шартнамә», «канун»; 3) татар теленең үз сүзләре белән беррәттән төрки сүзләр, гарәп-фарсы сүзләре дә телдә активрак кулланыла башлый, чөнки илдә идеологик, сәяси, рухи, дини кыйммәтләр үзгәрә («очкыч», «ватандар», «милләтпәрвәр», «хакимият», «хосусыйлаштыру», «тәрәккыят»); 4) шуңа да карамастан, тел хәзинәсендә гарәп, фарсы, төрки сүзләргә дә, Көнбатыш Европа телләреннән, урыс теленнән кереп, уңышлы үзләштерелгән сүзләргә дә бер үк дәрәҗәдә гадел, лаеклы урын бирелергә тиеш. Биредә бер чиктән икенче чиккә ташланырга ярамый. Кайчандыр көнчыгыштан көнбатышка ыргылган кебек, хәзерге этапта көнбатыштан абсолют көнчыгышка ыргылу шулай ук тормыш хакыйкатенә туры килми, тел үсешенә, терминологиясе баюына зур зарар китерә.

Татар телендәге, аның фәнни-техник, публицистик әдәбиятындагы, сөйләмендәге лексик-терминологик системаның күпмедер яңарыш кичерүен күзәтеп, телгә үтеп кергән, телдә ясалган, активлашып киткән сүзләрне күпмедер дәрәҗәдә этимологик-генетик, лексик-семантик, структур-грамматик, функциональстилистик һәм тематик аспектларда анализлап чыкканнан соң (тикшеренү нәтиҗәләре эксперименталь планда 500 сүзне эченә алган сүзләргә, терминнарга нигезләнә) аерым нәтиҗәләргә килергә мөмкин.

1. Хәзерге этапта телнең сүз хәзинәсе өлкәсендәге яңарыш түбәндәге факторларга бәйле:

а) милли яңарыш чоры, милли үзаңның, милли психологиянең беркадәр уңай якка үзгәрүе;

б) халыклар, милләтләр арасындагы икътисади, сәяси, мәдәни-рухи багланышларның җәйләнә төшүе.

2. Лексика өлкәсендәге яңарышның чагылышы түбәндәге күрсәткечләрдә гәүдәләнә:

а) сүз мәгънәсенең конкретлашуы, яңа мәгънәле сүзләр ясалу, элеккеге кайбер сүзләрнең активлашуы;

б) сүзләр үзләштерүнең телнең эчке мөмкинлекләренә бәйле булуы;

в) сүзләрнең, терминнарның функциональ кулланылышы киңәюе.

3. Лексика өлкәсендәге яңарыш күбесенчә татар теленең үз сүзләренә кайтып кала, ә яңа алынмалар, беренче чиратта, инглиз теле аша урыс һәм татар телләрендә тарала; элеккеге гарәп-фарсы сүзләре, аларның исем, сыйфат ясау модельләре дә янәдән күпмедер дәрәҗәдә активлашып китә.

4. Тематик яктан хәзерге этаптагы яңа сүзләр, терминнар, беренче чиратта, икътисад, сәясәт, мәдәният, мәгърифәт, фән, сәүдә, юриспруденция кебек өлкәләргә карый. ■

«Мирас», №11-12, 1994 ел

Тыйбб китабы

Мөхәммәд Хәсән бине Хөсәен

СИН (С) ХӘРЕФЕНӘ БАШЛАНГАН ДӘВАЛАР

Сәрсам *(симсим-көнҗет орлыгы)* – кичен ашасан, аш сеңдерүне яхшыртыр. Авызга тәм кертер. Утка пешкән җиргә сөртсәләр, файдалыдыр. Куырып ашасалар, үт куыгы авыруыннан файда бирер. Ашказаны авырткан кешегә зарарлыдыр, ярамас.

Синҗаб *(тиен)* – егетләргә һәм чәчәк чыгарган хасталарга файдалыдыр.

Сәммүр *(кеш)* – кызу холыклы кешеләргә яз көне кияргә кирәк түгелдер. Чөнки, кыздырып, канны агызыр. Әмма җиңел һәм салкын холыклы кешеләргә кыш көннәрендә кию – файдалыдыр. Аякта булган авыруларны бетерер. Юешлектән сәламәтлекләре бозылган кешеләргә файдалыдыр. Җимагъны, ягъни җенси мөнәсәбәткә керүне куәтле итәр.

ШИН (Ш) ХӘРЕФЕНӘ БАШЛАНГАН ДӘВАЛАР

Шәлгам *(шалкан)* – мәнине, ягъни аталык орлыгын күбәйтер. Кичен ашасаң, аш сеңдерүне яхшыртыр. Эчтә җилләр барлыкка китерер. Үзен ак әнис белән кушып ашыйлар. Ашыйсы килүне булдырыр. Кайнатып, суы белән суыктан ярылган җирләргә сөртсәләр, файда бирер. Чама белән генә ашасаң, җимагъка бик нык куәт бирер.

Шаһтәрә *(дымянка – әче дару үләне)* – тычканнарны куадыр. Томау төшеп борын тыгылуны ачар. Сары авыруын бәвел, ягъни сидек юлыннан куар. Бавыры авыру булганнарга файдалыдыр. Үт куыклары авыртучыларга бик файдалы. Ашыйсы килүне булдырыр. Канны сафландырыр. Тозлы какырыктан вә кан азлыктан вә сары авыруыннан булган баш әйләнүдән файдалыдыр. Кына суы белән катнаштырып мунчада сөртсәләр, баш әйләнүне һәм тән салынуны – гәүдә авыраюны бетерер. Төеп, сыгып, суын һинд тамыры белән кушып эчсәләр, баш әйләнүдән вә гәүдә авыраюдан бик файдалыдыр. Ашказанына бик файдалыдыр.

Шәфталу *(персик)* – ризыктан соң ашамыйлар, бозар. Яфрагын төеп, сыгып, суын колакка тамызсалар, кортларын кырыр. Сабыйларның эченә шәфталуның күбеген сөртсәләр, эчләрендәге суалчаннарны бетерер. Чәчәгеннән ширбәт ясап эчсәләр, йоклау бик җиңел буладыр.

Шикәр – бугаз һәм тамакны йомшартыр. Томауларны ачар. Ашказанына килешә. Какырыкны йомшартыр. Йөрәкне йомшартыр. Үтне куып чыгарыр. Әгәр ашаганда, эчкәндә шикәр кулланса, көч артыр, сеңерләре куәтле булыр. Эссе су белән эчсәләр, ютәлгә файдалыдыр, бетерер. Томау төшкән кешегә яндырып, төтенен иснәтсәң, томауны ачар. Үсемлек шикәрен авызга куеп, суын йотсаң, тавышка ачыклык бирер.

Шәкаикъ *(тюльпан – лалә чәчәге)* – кызыл төстәге чәчәк. Чәйнәсәләр, ютәлне бетерер, какырыкны кузгатыр, үпкә сүрүе шешүдән (плеврит) аеруча файда итәр. Хатыннар тотынсалар, күремнәрен агызыр. Чәчәген яшь әстерхан чикләвеге кабыгы белән төеп чәчкә сөртсәләр, чәчне каралтыр. Тимерәүгә сөртсәләр, бетерер. Чәчәген төеп, суын сыгып күзгә тамызсалар, күздәге акны (бельмо) бетерер. Хосусан, сабыйларның күзенә ак төшүчән була.

САД (КАЛЫН С) ХӘРЕФЕНӘ БАШЛАНГАН ДӘВАЛАР

Сагътәр *(чокырда үсә торган бер үсемлек – тимьян)* – бал белән изеп ашасалар, юешлектән булган ютәлне бетерер. Кайнатып куллансалар, баш әйләнүдән һәм гәүдә авыраюдан, сары авыруыннан файдалыдыр. Ашказанында ризык эшкәртелмичә бозылып авырган яки тавык күзе булган, ягъни караңгы төшкәч начар күрә торган кеше кулланса, файдасы булыр. Ризыкны эшкәртер, ашыйсыны китерер. Ашказанындагы начар лайлаларны куып чыгарыр. Эчтәге җилләрне чыгарыр. Әгәр кайнатып, суын бал белән эчерсәләр, эчтәге суалчаннарны бетерер. Инҗир белән бергә ашасалар, йөзнең төсен гүзәл итәр. Ике мыскал кадәрен тоз вә серкә белән эчерсәләр, үтне һәм какырыкны куып чыгарыр. Бал белән ашатсалар, чаян чакканга файда бирер. Зиһенне пакь итеп, эч авыртуны вә йөрәк авыруын бетерер.

Сыер – ите тупас, үтне арттырыр. Үт белән бәйле булган авыруларны бетерә. Шәһвәтне, ягъни җенси дәртне арттырыр. Җимагъка куәт бирер. Үтен бугаз авыртканда тыштан сөртсәләр, файдалыдыр. Истисканы, ягъни сары су авыруын бетерер. Әгәр канын киптереп, төеп, каны күп китүче яраларга сипсәләр, шунда ук канны туктатыр. Борын канавын да шулай ук туктатып була.

Сагыз – ашказанына файдалыдыр, ризыкны эшкәртергә ярдәм итәр. Бавырга куәт бирә. Эчтәге җилләрне

куып чыгарыр. Косасы килүне бетерер. Чәйнәсәләр, баштагы какырыкларны чыгарыр, йөзне күркәм, гүзәл итәр. Канны туктатырга ярдәм итәр.

Сандал *(бәкам агачы)* – эссе һәм нык холыклы кешегә килешә. Сары авыруыннан булган кан тамыры тыгылуны бетерер, эчеп һәм тыштан сөртеп. Эссе сугып баш авыртканнан сөртсәләр, баш авыртуны бетерер.

Самыгъ *(агач сагызы)* – ютәлне туктатыр. Ак бавыр яраларына файдалыдыр. Тавышны сафландырыр. Ашказанына куәт бирер. Гөл мае белән куырып ашасалар, ак бавырдан килгән канны туктатыр. Гөләб белән кушып күзгә сөртсәләр, авыруын бетерер. Күзнең күрүен яхшыртыр.

Сасфрас – бу – бер изге агачтыр, тәме – әнис тәменә охшаган. Яңа дөньяда «флорида» диләр. Европалылар Истанбулга китергәннәр. Бу агачта төрле авыруларга файда табып була. Бик хуш исле агач. Әнис исенә охшаган. Дарчин агач исенә дә охшаган. Кабыгы бик көчле ис чыгара. Томауны ачар. Тупас катнашмаларны йомшартыр. Эчтәге әгъзаларга куәт бирер. Суыктан вә баштан булган һәр авыруга файдалыдыр. Сулыш юлларын ачар. Бөер авыруларына файдалы, бөердәге ташларны ватып чыгарыр. Эчтәге җилләрне куар. Аналыкны яхшыртыр, күремне агызыр. Ашказанына куәт бирер, кыздырыр. Ашыйсыны китерер. Косасы килүне бетерер. Ваба, үләт авырулары таралган көннәрдә бер кисәген авызда тотсаң, сасы исне бетерер. Әмма моннан файдалану – холкы эссе вә коры булганнарга гына ярыйдыр. Ак тәнлеләргә зарарлыдыр. Бер кисәген авызда тотсалар, теш сызлавын басар.

ТА (КАЛЫН Т) ХӘРЕФЕНӘ БАШЛАНГАН ДӘВАЛАР

Таушан *(куян)* – ак төстәгесе – карасыннан яхшырактыр. Бер ел ата, бер ел ана куяннар булыр. Баш миен пешереп ашасалар, хасталыктан таралган кулаяк тетрәүләренә файдалыдыр. Йомыркасын пешереп, изеп, серкә белән кушып, зыяндаш (эпилепсия) белән авыручы кешегә эчерсәләр, файдасы булыр. Үтерүче даруларга, зәһәрләргәагуларга хосусан, елан чакканга файдалыдыр. Йомыркасын, хатыннар күремнән пакьләнгәч, өч көнгә кадәр, һәркөнне иртә белән яртышар дирһәм авырлыгында эчсәләр, йөккә узмыйлар. Әгәр башын бөтенләй яндырып, көлен аюның эч мае һәм серкә белән катнаштырып, чәче, сакалы коелган кешегә сөртсәләр, ул авыруны бетерер. Бөтен куянны яндырып, көленнән өч мыскал кадәресен бөерләрендә таш булган кеше эчсә, ташларын ватып чыгарыр. Әгәр куянны пешереп, тоз утыру авыруы (подагра) һәм барлык буыннары авыру кеше шуның суына кереп утырса, гаять файдалыдыр. Канын кыздырып, төеп, агулы ук ярасына сөртсәләр, зәһәрен бетерер, уңайлатыр. Итен ашагач, тупас кан барлыкка килер, алай булмасын өчен майларда кыздырып пешерергә кирәк. Холкы кызу булган кеше ашаганнан соң, әчкелтем-төчкелтем анар, ягъни гранат суын эчәр.

Тыйн мәхтүм *(мөһерләнгән ләм)* – барлык агуларга каршы торучы дарудыр. Йөрәккә куәт бирер, күңелне күтәрер. Йөрәккә куәт бирсен өчен гөләб белән кулланалар. Зәһәрләрне бетерер өчен эссе су белән кулланалар. Котырган эт тешләгән җиргә сөртсәләр, файдасы тияр. Төзәлмәс яраларга бал белән катнаштырып сөртсәләр, иске, ябылмый торган яраларга файдалыдыр.

РЕДАКЦИЯДӘН: *Хөрмәтле укучылар! Сез «Халык медицинасы» рубрикасында бирелә торган киңәшләрне табиблар күрсәтмәсеннән башка кулланырга ашыкмасагыз иде. Алар биредә фәкать борынгы бабаларыбыз мирасы буларак кына тәкъдим ителә.* ■

Ук очы. XVII гасыр

Дротик очы.
XIV гасырның II яртысы



Кылыч. XIV гасыр

Сугыш кораллары

(ТР Милли музее фондларыннан)

Музейдагы сугыш кораллары якынча 1000 саклау берәмлеген тәшкин итә. Шулардан 34 салкын һәм утлы корал А.Ф.Лихачев коллекциясеннән.

Чакма ук, дротик очлары, б.э.к IV-I йөзләргә караган бронза балталар – иң борынгы сугыш коралларыннан. А.Ф.Лихачевның коллекциясендә болгарлардан калган кылыч, пычак, балта, кистән, чукмар, сөңге һәм ук очлары, көбә һәм башка хәрби киемнәр дә саклана.

1552 елда Явыз Иван гаскәриләре Казанны яулап алгач, халык баш күтәрүләрен булдырмас өчен, татар халкыннан сугыш кораллары җыеп алына. Соңрак тимер эшкәртү дә тыела. Музей фондларында XVI йөз татар сугыш коралларының юклыгы да шуның белән аңлатыла.

Кылыч.
XV-XVI гасыр башы

Битлек. XIII гасыр

Дротик очы.
XIV гасырның II яртысы

Кистән. XI-XII гасыр

Пищаль һәм көбеләр. XVI йөзнең II яртысы

Утлы кораллардан XVI йөзнең II яртысында эшләнгән пищаль аерым игътибарга лаек. Аның озынлыгы 135 см, калибры – 23 мм. Сигезпочмаклы пищальның тышкы ягы чүкеп, тупас итеп эшләнгән. Бу коралны 1552 елда ике як тараф сугышчылар да кулланган. Музейга ул 1898 елда бүләк ителә.

Ленар Нәгыймов *әзерләде.* ■

Көбә

«Кояш» газетасында **«Казан хәбәрләре»: 1916 елның октябрь ае**

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Яңа елны каршы алу

Үткән җомга көн «Сәйяр» труппа 1335 нче сәнәи һиҗриядән истикъбаль шәрәфенә[1] кичә ясады. Бу кичәдә «Тормыш юлында» исемле 3 пәрдәле драманы (яңа әсәр) тамашага куйганның соңында, концерт вә музыка кыйсеме вә яңа ел каршылау мәрасиме ижра итте. Бу кичәгә килүчеләр фәүкылгадә [гадәттән тыш] күп булды ки, билетлар сатылып беткәннән соң, урам тулы халык керә алмыйча кайтып китте.

«Тормыш юлында» дигән драма – программада Е.А. әсәре дип ишарәләнгән вә басылып чыкмаган әсәрдер. Әсәрнең рухы вә бәгъзы гыйбарәләре русчадан икътибас ителгән [алынган] яки истифадә кылынган [файдаланылган] икәнлеге аңлашыла, ләкин һәрхәлдә куәтле мәзмунга [эчтәлеккә] малик [ия]. Уйнаучылар рольләрен гомумән гүзәл ижра иттеләр [башкардылар]. Концерт вә музыка кыйсеменең [өлешенең] иң яхшы кыйсеме Гали әфәнде Зайпинның скрипкада уйнавыннан гыйбарәт булды.

Кояш. – 1916. – №1032. – 18 октябрь.

Нәҗип Думави

Шагыйрь Нәҗип әфәнде Думави моннан берничә вакытлар элек гаскәри хидмәткә алынган иде. Нәҗип әфәнде үткән көн үз полкы белән берлектә сугыш мәйданына озатылды. Хода сәламәт кайтырга насыйп итсен.

Кояш. – 1916. – №1033. – 20 октябрь.

Фатиха ханым Аитова гимназиясен ачу мәрасиме

29 нчы октябрьдә, көндез сәгать бердә Фатиха ханым Аитова гимназиясен ачу мәрасиме гимназиянең үз бинасында ижра ителде. Мәҗлестә Казан валисе [губернаторы] Боярский, шәһәр башлыгы Баронин, шәһәр думасының әгъзасы М.Пинегин, мәктәп комиссиясе әгъзаларыннан Захариевский, халык мәктәпләре инспекторы вә директоры һәм башкалар хазир [бар]. Мөселманнардан: голәмәдән Кәшшаф хәзрәт Тәрҗемани, дәгъвә вәкилләре [адвокатлар] Сәедгәрәй Алкин һәм Вәлидхан әфәнде Таначев, матбугат вәкилләре хазир. Шулай ук мәхәлли [җирле] рус гәзитәләреннән «Телеграф» вә «Речь» гәзитәләренең дә вәкилләре бар. Гимназиянең мөтәвәлли, мөгаллимә вә талибәләре һәйәтеннән башка, килгән кунакларның мәҗмугы [барлыгы] 35-40ка ирешә.

Дәгъвәтлеләр [чакырылганнар] килеп тәмам булганнан соң, Кәшшаф хәзрәт Тәрҗемани мәктәпнең ачылуын алкышлап вә мәктәпнең мөтәвәллиясе Фатиха ханым һәм рәфикы [ире] Сөләйман әфәнде вә аларга мөкаддәс эшләрендә ярдәмдә булучыларны муәффәкыятьләре [уңышлары] белән тәбрик итә вә

* Даталар иске стиль белән бирелә.
[1] Истикъбаль шәрәфенә – яңа елны каршы алу хөрмәтенә.

аларга рәхмәт укый. Соңрак Коръән укып, Фатиха хыным җәнапларының ата-бабалары вә башка якыннары рухына багышлый. Хазирун [шунда булучылар] амин дип догада булына.

Аяк үзрә торып падишаһ әгъзам хәзрәтләре вә ханадан галиләренә [нәселнәсәбенә] сәламәтлек, хәерле гомер, сәгадәт вә икъбальләрен [эшләренең алга баруларын] теләп дога әйтә. Җәмәгать амин укый.

Моның соңында округ попечителе Казанда беренче мөселман гимназиясе ачылу мөнәсәбәте белән мөселманнарны тәбрик итә вә алар өчен моннан зуррак гыйлем йортлары вөҗүдкә килүне теләгәнлеген, вә моңа бик ышанганлыгын бәян кыйла. Попечитель җәнапларының нотыгы мөселманнар өчен гаять ягымлы вә җылы иде.

Попечитель округ җәнапларының нотыгы тәмам булгач, мәктәпнең талибәләре падишаһ хәзрәтләре, гаиләи шаһанәләре [гаиләсе] вә ханадан галиләренең сәламәт, бәхет, сәгадәт вә шәүкәтләренең дәвамын теләп, хор белән мөнәҗәт укыйлар. Хазирун аяк үзрә торып тыңлыйлар вә соңгыннан кул чабып алкышлыйлар. Мөнәҗәтнең русчага тәрҗемәсе вали, округ попечителе вә гомумән рус кунакларына тәкъдим ителә. Алар үзләре белән алып китәләр.

Узган сәнә шәһәремезнең галиҗәнаплар курсын тәмам иткән гимназиянең мөдирәсе Мәрьям туташ Акимбитова яңа гимназиянең эчке хәле хакында доклад укый. Хазирун дикъкать белән тыңлый.

Нотык сөйләүдән имтинаг иткән [баш тарткан] әфәнделәр нотык сөйләүне нигъмәттән соңа калдыралар. Хазирунга нигъмәт тәкъдим ителә. Нигъмәт тәмамында Фатиха ханым Аитова имзасы илә падишаһымыз хәзрәтләренә сәдакать [тугрылык] телеграммы вә мәгариф вәзире җәнапларына тәшәккер [рәхмәт] телеграммы бирелә. Мәрасим шуның белән тәмам була. Кунаклар сәгать дүрттә тарала башлый. Мәҗлес бик самими вә рухлы булып үтә.

Мөгаллимнәргә мөһләт [срокны кичектерү] хакында

Г.Думаның әгъзасы хөрмәтле Гәйсә мирза Еникиев җәнапларының мөгаллимнәргә мөһләт бирелү хакындагы телеграммы Казанда биш кемсәнең вә шул җөмләдән фәкыйрьнең адресы илә килгәнен ишеткән мөгаллим әфәнделәр вә бәгъзе мәдрәсәләрнең мөдирләре, шул хакта бәгъзе сөальләр илә миңа мөрәҗәгать иттекләреннән, түбәндәге сәтырларны [юлларны] язып, гомуми бер җавап бирүне тиеш күрдем. Мәзкүр телеграммны алганнан соң, Галимҗан хәзрәт[2] өйдә булмаганыннан, ярдәмчесе Габдерахман хәзрәт Галиев илә воинский начальникның генерал-майоры Н.В.Комаровский җәнапларына мөрәҗәгать кылып, аларга бу тугрыда главный штабтан хәбәр булып булмау һәм гомумән бу эшне тәртип хакында сораштык. Комаровский җәнаплары хәбәренә күрә, главный штаб хәбәре аның үзенә ирешкән һәм башка воинский начальникларга да ирешкән булуы мәэмүл [ихтимал] икән. Бу мөһләттән файдалану өчен имамнар, каралырга тиешле булган мәхәлләләрдәге мәктәп яки мәдрәсә мөгаллимнәренең кулларына кайвакыттан бирле мөгаллимлек кылганлыкларын бәян итеп, шәһадәтнамә бирергә тиеш. Мөгаллимнәр шул шәһадәтнамәне воинский начальникларга тәкъдим итеп мөһләт алырлар.

Кояш. – 1916. – №1036. – 30 октябрь. ■

[2] Газетаның 1033 санында: «Мөселман фракциясе сәркатибе Исмәгыйль әфәнде, Лиманов дамелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләренә биргән телеграммында, мәдрәсә мөгаллимнәренә гаскәри хидмәттән мөһләт бирелү эшенең адымнар белән алга киткәнлеге хакында хәбәр итә», – дип язылган.

Көлке куа килә...

Хабра. «Чаян», 1934 ел

ЯЗУЧЫЛАР ФОЛЬКЛОРЫ

Ак та кия Ф.Сәйфи,
Күк тә кия Ф.Сәйфи.
Өч көндә бер повесть язып,
Рекорд бирә Ф.Сәйфи.

Самовар капкачын ачсаң,
Бүселә-бүселә бу чыга.
Qrъjm шигырьләрен сыксаң,
Мичкә-мичкә су чыга.

Эшлә тырышып, бул ударник,
Вәт булдырасың син, егет.
Язма тәнкыйть, бул тәнкыйтьче,
Вәт булырсың Мөсәгыйт.

Телеграмм баганасы
Яфрак ярган чагында,
Мәхмүт Максут яңа әсәр
Бирәчәк, ди тагын да.

Фатыйх Хөсни юкка кыза,
Тәнкыйть итсәң пыр туза.
Әле шигырь, әле проза...
Гомерләр шулай уза.

Туктар, «Сукмаклар»ың белән
Башларны «адаштырдың».
«Талаш» хикәясен язып,
Күпләрне талаштырдың.

Бу ел кояш нык кыздыра,
Үләннәрне көйрәтә.
Туфан элек үзе язды,
Инде яшьләрне «өйрәтә».

Мирсәй Әмир, каешыңны
Кысып бәйлә билеңә.
Кирле-морлы җөмләләрдән
Әрем үсте телеңә.

Иртә торды Ерикәй,
Битен юды Ерикәй.
Көйле мәкаләләр язып,
Шагыйрь булды Ерикәй.

Алмаз Хәмзин әзерләде.

Мөхәммәт Мәһдиев

МИН ДӘ БУЛДЫМ СУГЫШТА

Фронттан кайткан берәү сөйли:

– Мин снайпер идем, мине фашистлар әллә каян белә иде. Бервакыт камышлыкка барып кердем, кычкырып җибәрдем. «Ханди хох... майть!» – дип. Тегеләр куркышып калдылар, әйтәләр: «Яруллин, ата күрмә...»

Шулвакыт хатыны сорый: «Алар татарча белә иде мени соң?» Ире әйтә: «Тик кенә тор, ирләр сүзенә катышма», – ди.

***

Икенче берәү сөйли:

– Мин, – ди, – бер эшелон немесне берүзем пленга алдым, сигез йөз кеше иде, шуларга чөгендер чүбе утаттым. Бервакыт маршал Жуков килде. Строй алдыннан узганда мине танып елмайды, молодец, Сибагатов, диде...

Хатыны сорый:

– Кием-салымы нинди иде?

– Нинди булсын, яхшы инде. Кара кәчтүм-чалбар, аягында ялтыравыклы ботинкалар... (Биектау ягы фольклоры).

МИНЗӘЛӘДӘН ИКЕ МӘЗӘК

БЕР ГЕНӘ КРҮШКӘ

Минзәлә артистлары, спектакльдән соң, Казанның «Заря» кунакханәсендә чәй эчәргә җыена. Вахтер өч литр су сыешлы чәйнек белән чәй кайнаткан. Ә коллективта кырыклап кеше. Олы кеше буларак, Хәдичә апага юл бирәләр. Үзе белән йөртә торган бер литрлы кружкасын тоткан Хәдичә апа: «Сез үзегез иркенләп эчәрсез, миңа күп кирәкми, бер генә крүшкә җитә», – ди.

БЕЛГӘЧ, НИГӘ СОРЫЙСЫҢ?

Минзәлә артистлары бригадасы, күз ачкысыз буранда көне буе адашып йөреп, ниһаять, бер авылга килеп җитә. Аларны көтеп гаҗиз булган яшь клуб мөдире, ни әйтергә белмәүдән, иң беренче килеп кергән Әхмәдиша Җиһаншиннан:

– Килдегезме? – дип сорый.

– Юк әле, килмәдек, – дип җавап бирә артист.

Мөдир кыз, аптырап:

– Килгәнсез ич! – ди.

– Белгәч, нигә сорыйсың, – ди арыган Әхмәдиша абый.

Илусә Бәдриева,
Татарстанның халык артисткасы

Наил Дунаев

«450 ЕЛ ЭЛЕК ҮЛДЕ...»

Театрда эшләүче Рафаэль исемле рәссам белдерү язып элә: «Мөштегемне югалттым, табучы булса, рәссам Рафаэльга кайтаруыгызны үтенәм».

Режиссер Празат Исәнбәт белдерү астына: «Рәссам Рафаэль моннан 450 ел элек үлде шул инде», – дип язып куя. ■

«Кызыл мәчет». Җаек. 2000 нче еллар

«Безнең мирас»

елъязмасы / октябрь

• 465 ел элек (1551)

Зөя кальгасы төзелә.

• 125 ел элек (1891)

28 октябрьдә татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе, күренекле актриса Гөлсем Болгарская (1891-1968) дөньяга килә.

• 95 ел элек (1921)

Габдулла Тукайның «Өзелгән өмет» («Разбитая надежда») исемле шигырьләр җыентыгы П.Радимов тәрҗемәсендә рус телендә басылып чыга.

• 85 ел элек (1931)

Урта Идел өлкәсендә беренче күчмә татар театры һәм Уралда күчмә татар-башкорт эшче театры оештырыла.

• 75 ел элек (1941)

12 октябрьдә Абдулла Алиш, чолганышта калып, фашистлар кулына әсирлеккә эләгә.

Октябрь-декабрь айларында Муса Җәлил Минзәләдә Марьинодан күчеп килгән хәрби-политик курсларда укый.

• 60 ел элек (1956)

20 октябрьдә Болгариянең башкаласы София шәһәрендә «Шүрәле» балетының премьерасы була.

• 45 ел элек (1971)

«Казан утлары» журналында Гариф Ахуновның «Чикләвек төше» повесте дөнья күрә.

• 15 ел элек (2001)

28-30 октябрьдә Татарстанның халык депутатлары Фоат Галимуллин һәм Ренат Харис катнашындагы Татарстан Республикасы делегациясе Казакъстанның Җаек (Уральск) шәһәрендә була. Биредә яшәүче профессор Разак Әбүзәров белән бергә алар шәһәрнең татар зиратында Мотыйгулла хәзрәт каберен зыярәт кылалар. Г.Тукай белән бәйле урыннарны: ул торган йортны, шагыйрь укыган мәктәпне, Кызыл мәчетне карыйлар. Балалар китапханәсендә булалар, татар җәмгыяте вәкилләре белән очраштылар. «Евразия» университетында чыгыш ясыйлар, Әбҗәлил Нурпеисов җитәкчелегендәге Казакъстан язучылары төркеме белән очрашалар. 30 октябрьдә Җаек каласында Г.Тукайга һәйкәл ачыла. ■

Мирасворд

Мәхмүт, Гарәфи, Нурислам

1991-1995 елларда «Мирас» журналында эшләгән галим

Одиссей Ватаны

«Сәһәйл ... Гөлдерсен» дастаны

Перу каласы

XX йөз башы әзербайҗан шагыйре һәм сатиригы

... - баба йоласы

Кайбер Шәрык илләрендә монарх титулы

Чуашстандагы шәһәр

Бүлмә эте

Язучы Мин ...

Гогольнең тәхәллүсе

Г.Тукайның 1909 елда язган шигыре

XIX йөз рус рәссамы

Конфуций Ватаны

Әзербайҗанның халык язучысы

«Сак - ...» бәете

Шагыйрь ... Фидаи

Яуга чакыру авазы

Фирдәүси поэмасы

Нечкә йонлы сарык токымы

Г.Бәширов повесте

Франциядә борынгы алтын таңкә

Дүртенче буын ир яки кыз кардәш (диал.)

... Колыйй

XIX йөз испан әдибе

Урта гасыр хәзәр кальгасе

Борынгы грекларда исәпләү тактасы

«... вә Димнә» ядкәре

Яңа туган ай, айның чиреге (иск.)

Эре сөякле, зур (диал.)

Кытайда мәйдан үлчәү берәмлеге

Чуашстанның халык шагыйре

Драматург ... Гыйззәт

Башкорт халык биюе

Борынгы Грециядәге шәһәр

Гектар

Композитор ... Мөлеков

Сугышта кулга төшкән ганимәт, трофей (иск.)

... - Петри (Кырымдагы тау)

... Твен

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: каба, ни, чыгтай, купы, Еврипид, Афон, Юныс, рад, рәт, иравыл, итака, Риан, кән, «Вакыт», Сак, дәшт, тумак, какы, кистән, Рим, келә, Әхәт, Фукс.

Өстән аска: Кариев, уфар, Аспарух, подаука, ки, «Качкын», ыктымат, фырт, Бигиев, ли, «Ант», ардак, Рюмин, Әки, Туйкин, скиф, пырак, тәте, исәкәй, әләк, тан, сәнә.

***Рәис Габдулла** төзеде.*

СОДЕРЖАНИЕ

«Нашему наследию» – 25: Слова поздравления Президента Республики Татарстан Р.Н. Минниханова; статья первого Президента РТ М.Ш.Шаймиева; И.Тагиров, Ф.Ислаев, Г.Баширов, Р.Амирхан, М.Валиев, Р.Рахман, Н.Наккаш о журнале «Наше наследие».

Историческое наследие: «Булгар. Белая палата»; «Зулейха» А. Мухаммадиев; «Гаухаршад» Ф.Зариф; «Сказ о Казанском ханстве»; «Следы Тукая в Балтасинском районе» Г. Мухаметшин; «История сибирских татар» М.Ахметзянов.

Религиозное наследие: «Сказание об Ишмухаммет хаджи» Г.Гатауллин.

Литературное наследие: «Кутадгу билик». («Благодатное знание») Ю.Баласагуни; «Белое облако Чингизхана» Ч.Айтматов; «Главный акын казахов» Х.Миннегулов; «Учёный, борец, патриот» М.Хабибуллин.

Художественное наследие: «Потомство Садриевых» Р.Сагди.

В глубине памяти: Оружие военных лет (из фонда Национального музея РТ)

100 лет назад: «Казанские вести» в газете «Кояш»: октябрь 1916 года».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT

«Our heritage» celebrates – 25: The congratulation words of the President of the Republic of Tatarstan R.Minnikhanov; the letter of the first President of the Republic of Tatarstan M.Shaimiev; I.Tagirov, F.Islaev, G.Bashirov, R.Amirkhan, M.Valiev, R.Rakhman, N.Nakkash about the «Our heritage» magazine.

Historic heritage: «Bulgar. The white chamber»; «Zuleikha» by A. Mukhammadiev; «Gaukharshad» by F.Zarif; «The story of the Kazan khanate»; «Tukay's memoirs are at Baltasy region» by G.Mukhametshin; «History of Siberian Tatars» by M.Akhmetzyanov.

Religious heritage: The legend about Ishmukhammat hadji by G. Gataullin.

Literary heritage: «Kutadgu bilik» («The blessed knowledge») by U. Balasaguni; «The white cloud of Genghis Khan» by Ch. Aytmatov; «The main akyn of the Kazakhs» by Kh. Minnegulov; «Scientist, fighter, patriot» by M.Khabibullin.

Creative heritage: «Breed of the Sadrievs» by R. Sagdi.

From the depth of memory: The weapon of the war period (from the National museum of RT's fund)

100 years ago…: «Kazan news» is in the «Koyash» newspaper: October of 1916.

THE MAGAZINE CONSTANTLY BRINGS TO LIGHT ALL THE MOST IMPORTANT EVENTS OF OUR NATION LIFE.

И.Фәйзуллин
«Ханбикәнең
күзгә сагышы».
2008 ел.
Киндер,
майлы буяу

ХӘТЕР КӨНЕ – ФАҖИГАИ МИРАС...

Ф.Халиков
«1552 ел
вакыйгасы».
2002 ел.
Киндер, майлы буяу

4 612750 670172